№ 2 2019

ТУГАРАК УЕНЫ

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

Сөлгеләр тотыла, һәр авыл
Батырын күзәтә, билгеле...
Мәйдан күк кысыла йөрәкләр:
– Бирмә билеңне!
– Бирмә-ә-ә...

Мөдәррис Әгъләм

Габдулла ТУКАЙ

Бәйрәм вә сабыйлык вакыты

Сабый вактын сагынмакта һәр шагыйрь дә,
Ачы-тәмле хыялдыр бу һәр шагыйрьгә;
Бәйрәм житсә, минем дә исемә төшә:
Уйнамакчы булам сыйбъян берлән бергә.

Төшә искә гарәфә кич яткан чагым,
Уйлап: «Кайчан таң?» – дип, ул атмаган таңым;
Тәти читек, тәти күлмәк-ыштаннарны
Баш астыма өеп куеп яткан чагым;

Таң алдыннан яңлыш йоклап киткән чагым,
Төшемдә дә нурлы бәйрәм көткән чагым;
Әнкәемнең тавышлары колагымда:
«Гает житте, тор, аппагым! Тор, аппагым!»

Таң аткачдин урам буе чапкан чагым,
Мәгъсуманә ләззәт, хозур тапкан чагым;
Корбан ите, төрле тәмле аш өстенә,
Гает укып, көлә-көлә кайткан чагым. –

Уйласаң ул якты көнне, килә күз яшь;
Хозур ла соң! Инсан өчен бу хәл, бу яшь!
Бәйрәм көнне күктән жиргә нурлар ага,
Әйтерсең лә чыккан бу көн ике кояш!

Сыйбъян - балалар.
Мәгъсуманә - гөнаһсыз, пакь килеш.
Инсан - кеше.

№ 2 2019

ТУГӘРӘК УЕН

Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

*«Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,
моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул»*

16+

Гамәлгә куючылар:

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

Редколлегия:

Әхмәтҗанов М.И.
Бакиров М.Х.
Вәлиева З.Р.
Вәлиев Р.И.
Гайсин И.З. (Мари Эл)
Заһидуллина Д.Ф.
Нәгыймова З.Ш.
Тукаев М.Р.
Шәрәфиева Р.Г.
Юсупов Ф.Ю.

Директор: **Алсу Мифтахова**

Баш мөхәррир: **Илсөяр Иксанова**

Альманахның иҗат төркеме:

Гөлсинә Хәмидуллина
Сөмбел Толпегина
Зөһрә Фәсхиева
Мөнирә Кузиева

Альманах 2014 елның 5 августында элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77-58939. Өч айга бер чыга.

Бу санны бизәүдә Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фондындагы, Р. Мөхәммәтҗанов, Р. Хәялиева һәм авторларның шәхси архивларындагы фотолар файдаланылды. Тышлыкның 1, 2 битләрендә Р. Мөхәммәтҗанов фотолары

Кәгазь форматы $60x90^1/_8$. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды 6.05.2019 ел. Заказ О-1160.
Тираж 1000 экз.

Редакциянең адресы: 420021, Казан, Тукай урамы, 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин урамы 66/33 йорт.
Телефон: 293-27-99. E-mail: tugarakuen@mail.ru

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар ур., 2.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен»нан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

КАЗЫНГАН – КАЗНА ТАБАР

4
26 апрель – Габдулла Тукайның туган көне
Тукай дөньясына сәяхәт
Г.Төхвәтова белән әңгәмә

10 **Йолаларыбыз**
Гөлнара Мансурова
Татарларда Боз озату йоласы

13 *Олег Хисамов*
Туганнарның төбе бер

16 **Малның җаен баккан белер**
Алсу Батталова
Сыер алсаң, танып ал...

© «Түгәрәк уен», 2019

20 Милли бәйрәмнәребез
Фәнзилә Җәүһәрева
Сабан туе нинди туй?

27 Шәхес
Айдар Гайнетдинов
Милләтне фән белән күтәрүче галим

30 Борынгы ышануларыбыз
Марсель Әхмәтҗанов
Татарлардагы кайбер көрәзә ысуллары

32 Язмыш
Фәрит Юсупов
Төш күрү. Төш юрау

38 Һөнәрле үлмәс...
Зөлфия Дадашова, Миңнур Зольникова
Һөнәр алды – кызыл тел

41 *Раилә Хәялиева*
Чигү чигәм алтын җепләр белән...

44 Хәтер-хатирә
Гөлсинә Хәмидуллина
Бистәнең татар учагы

КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

52 *Мәдинә Маликова*
Кар сулары
Хикәя

56 Хәтер-хатирә
Шәриф Каюмов
Җыр ачадыр күңелне...

УЕНДА ҖИҢГӘН – ҖЫЕНДА ҖИҢӘР

60 Без, без, без идек...

64 Өй күрке – аш
Сәвия Галиева
Менә безнең талкыш-кәләвә!

ТУКАЙ ДӨНЬЯСЫНА СӘЯХӘТ

Редакциябез Г. Тукай әдәби музее белән янәшә генә. Тәрәзәләребез дә музейга карый. Эш урыныбызның Иске татар бистәсендә, Шамил йорты артында булуына чын күңелдән шатланабыз без. Беренчедән, Иске татар бистәсе – татар Казаны, икенчедән, Г. Тукай әдәби музее безнең өчен бик кадерле, изге урын. Тукай исән вакытында бу бинада булганмы, юкмы, анысы төгәл ачыкланмаган. Әмма, ничек кенә булмасын, бүген монда Тукай рухы яши. Чөнки бирегә Тукайның һәм якыннарының шәхси әйберләре, аның тормышы белән бәйле истәлек-хатирәләр, шагыйрьнең вафатыннан соң алынган гипс битлек саклана. Шуңа да без аны Тукай йорты дип кабул итәбез. Сабый чагында ук туган нигезеннән аерылган, үзенең кыска гына гомерендә, әле бер, әле икенче кешенең түбәсе астына сыенырга, гомеренең күп өлешен кунакханәләрнең шыксыз «казенный» бүлмәләрендә үткәрергә мәҗбүр булган шагыйрьнең, вафатыннан соң булса да, үз йорты булырга тиеш бит!

2016 елда музейда төзекләндерү эшләре башлануга сөенсәк тә, ничектер моңсу булып калды. Тукаебыз Казаннан чыгып киткән кебек булды. Бик кадерле, якын кешең каядыр китеп барса, шулай була бит: бөтен дөнья бушап, төссезләнеп кала. Һәм аның яңадан әйләнеп кайту шатлыгы да шундый ук зур, дулкынландыргыч була.

Ниһаять, төзекләндерү эшләре тәмам булды. Тукаебыз үз йортына кайтып урнашты. Сөенә-сөенә музейны карап чыктык. Сокланып, дулкынланып, хисләнеп. Музейның үз эшенә җаны-тәне белән бирелгән директоры ***Гүзәл Фәрдин кызы ТӨХВӘТОВА****, һәр почмакны җентекләп күрсәтеп, яңа табылдыклар белән таныштырып, безгә чын мәгънәсендә Тукайның күпкырлы дөньясын ачты. Без ул дөньяга сезне дә чакырабыз...*

– Бүгенгә кадәр «Шамил йорты» дип йөртелә торган бу бинаның тарихы бик кызыклы. Фәнни эзләнүләр нәтиҗәсендә дә, халык хәтере белән бәйле рәвештә дә аның серләре әле һаман ачылып тора. Мәгълүм булганча, әлеге йортны 1865 елда Казанның иң бай сәүдәгәрләреннән берсе Ибраһим Апаков төзетә. Бердәнбер кызы Бибимәрьямбану кияүгә чыкканда, бинаны аңа туй бүләге – бирнә итеп бирә. Бибимәрьямбану Кавказ халыкларының милли азатлык өчен көрәшкән каһарманы имам Шамилнең уртанчы улы, отставкадагы генерал-майор Мөхәммәдшәфи Шамилгә кияүгә чыга.

Йортка кагылышлы бөтен документлар «Госпожа Шамил» исемендә. Кызганыч, Казан шәһәре буенча төзелгән һәм соңгы елларда нәшер ителгән кайбер юлкүрсәткечләрдә шактый төгәлсезлекләр бар. Кайберләрендә

бу йортны Шамил төзеткән дип бирелә, кайберләрендә «Бибимәрьямбану имам Шамилгә кияүгә чыккан» дип күрсәтелә.

Казанда булган зур янгыннан соң, 1903 елда Бибимәрьямбану йортны үзгәртеп төзетә. Кызганыч, кайсы җирләре ничек үзгәртелгәне билгесез. Монда алар 1906 елга кадәр яшиләр, ике кызлары туа. Мөхәммәдшәфи 1906 елда Кисловодскига ялга киткән җирендә вафат була, аның кабере дә шул якларда. Иренең вафатыннан соң Бибимәрьямбану, йортны сатып, Петербургка китә. Кызлары шунда белем алалар. Берсе шунда тимер юл институты студенты, кавказлы Махачка кияүгә чыга. Хәзерге Махачкала шәһәре шул Махач хөрмәтенә аталган.

Бу йортның икенче хуҗасы яшь сәүдәгәр, замандашлары теле белән әйтсәк, «Конфет короле» Вәлиулла Ибраһимов була. Ул биредә 1917 елга кадәр яши. Соңгы елларда гына билгеле булган истәлекләргә караганда, Вәлиулланың кызлары Тукайны соңгы юлга озату мәрәсимен шушы йортның Юнысовлар мәйданы ягындагы балконына чыгып карап торганнар.

Узган ел нәсел дәвамчыларыннан Вәлиулла Ибраһимовның фотосурәтен табуга ирештек. Яңа экспозициябездә, шулай ук, йортның беренче хуҗалары Бибимәрьямбану һәм Мөхәммәдшәфиләрнең дә фотолары урын алды.

Инкыйлабтан соң биредә коммуналь фатирлар оештырыла. Хәзер безгә шушы бинада туып-үскән кешеләр (инде алар олы яшьтәге әби-бабайлар) килә. «Безнең бүлмә бу урында иде, без менә монда тордык, күршеләребез шул иде», – дип, балачак, яшьлек хатирәләре белән уртаклашалар. Подвалда да кешеләр яшәгән, чормада керләр киптергәннәр.

Төзекләндерү эшләре вакытында бу аралашулар бик ярдәм итте. Мич урыннары, төтен юллары кайда булган, шуларны ачыкладык. Каплап куелган гранит плиткаларны алып, беренче хуҗаларның аяк эзләрен саклаган борынгы баскыч яңадан торгызылды. Штукатурканы куптаргач, күп серләр ачылды: кайда ишекләр булган, кайда яңадан кирпечләр куелган – барысы да күренеп тора. Кирпеч белән каплап куелган диварлар эченнән колонналар килеп чыкты. Тәрәзәләр бик кызыклы. Җитмештән артык тәрәзә, һәм алар орнаментлары, зурлыклары буенча берсен-берсе кабатламый. Хәтта бер үк бүлмәдә икешәр-өчәр төрле тәрәзәләр бар.

Әлбәттә, музейны төзекләндерү инде күптәннән сорала иде. 2015 елда Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов килде, музейны бик җентекләп карады. 2016 елда инде ремонт эшләре башланды. Авыр да, кызыклы да булган әлеге эшләр Тукай иҗатына багышланган яңа экспозиция төзү өчен яңа идеяләр, яңа этәргечләр бирде.

Шамил йортының беренче хуҗалары Мөхәммәдшәфи һәм Бибимәрьямбану.

Өр-яңа экспозиция булдырылды, ул ун өлештән тора. Экспозицияне төзү Татарстан Республикасы Милли музее җитәкчелегендә барды. Бу эштә Милли музейның директоры Г.Р. Нәҗипова, С.Ю. Измайлова, Т.В. Матвеев һ.б. бик күп көч куйды. Музейның концепциясен, электрон терминалларның текстларын әзерләү, экспонатлар сайлау һәм башка эшләр Г. Тукай әдәби музееның әдәби хезмәткәрләре Р. Нәгыймуллина, Л. Тябина, Л. Медведева тарафыннан әзерләнде. Алар бик күп гыйльми эзләнүләр алып барды, экспозициядә Тукай тормышын һәм иҗатын тулырак чагылдырырга тырышты. Безнең шулай ук музейның элеккеге директорлары Фәрит Яхинга, Рәмис Аймәткә рәхмәтләребез зур. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Илһам Гомәрев, Әлфәт Закирҗанов, КФУда белем бирүче

галимнәр Хатыйп Миңнегулов, Фоат Галимуллиннарга берөзлексез дигәндәй мөрәҗәгать итеп тордык. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә, ТР Милли китапханәсе, Милли архивы бик нык ярдәм итте. Аннары, Тукай тормышы-иҗаты буенча гына түгел, Шамил йорты, Иске татар бистәсе, Тукай белән аралашкан шәхесләр белән бәйле күп кенә материаллар тупланды.

Уртак хезмәт нәтиҗәсендә, музейда «Тукай үзәге» оештырылды. Алга таба без аны тулы фәнни үзәк итеп күзаллыйбыз. Фәнни эш язган кеше бездәге чыганаклардан файдалана ала, китапларны алып укырга мөмкин. Электрон китапханәбез дә бик бай. Тукайның бөтен әсәрләрен татарча, русча, инглизчә укырга була. Аннары, теләгән кеше Тукайның бөтен һәйкәлләре, аңа багышлап оештырылган бәйрәмнәр, Тукай урыннары турында тулы мәгълүмат таба ала.

Ә инде иң зур залыбызда – Тукайның иҗатка килүе, иҗат баскычлары. Иң беренче – аның туган ягы. Туган ягы турындагы мәгълүматны төп нөсхә экспонатлар белән дә баетабыз. Бабасының Коръәне, үги әтисе, Сасна авылы мулласының таягы, әнисенең комганы...

Җаек чорында исә Тукайның беренче гонорарына сатып алынган кәрәч тартмачыгы күрсәтелә. Камил Мотыйгый, Мотыйгулла Төхфәтуллиннар белән бәйле мәгълүматлар бирелә. Белгәнебезчә, ул чордагы җәдид мәдрәсәләре университетлар белән бер дәрәҗәдә торган. «Мотыйгия» мәдрәсәсендә Тукай берничә тел өйрәнгән, Көнчыгыш һәм рус әдәбиятлары, музыка дөньясы белән танышкан. Дөньяга карашының нигезе шунда формалашкан.

Казан чоры турында сөйләгәндә, Г. Тукайның шагыйрь генә түгел, ә күренекле журналист, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе буларак танылуын ассызыклыйбыз. Г. Тукайның сакланып калган шәхси әйберләре кыйммәтле ядкарь булып тора. Биредә аның түбәтәе, юл кәрҗине, кара савыты, көмеш җиң каптырмалары, карандаш савыты, сөлгесе тәкъдим ителә. Үзе исән чагында басылган китапларын таптык.

1911-12 елларга караган, жандармерия архивыннан алынган документлар шагыйрьнең шәхесен ачуда шулай ук үзенә бер тема булып тора. Ул документлар җыелмасы ТР Милли архивында саклана. Тукайны үлгәннән соң күмү белән бәйле документлар, китапларына арест салулар, аерым шигырьләрен сәяси яктан тикшерү... Миңа Тукайның С.-Петербургка китеп бару сәбәбе дә жандармерия белән бәйле кебек... Бу теманы алга таба киңәйтәсе иде.

Тукайның вафатыннан соң алынган гипс битлеге аерым урында саклана. Без аны балаларга күрсәтмибез. Күрәсе килгән кешеләр карый ала.

Театр залы бар. Ул, гомумән алганда, татар театры тарихына багышланган. Аның һәрбер өлешендә Тукай рухы яши. Чыннан да, «Сәйяр» труппасына исем табучы да Тукай бит. Биредә Тукайның «Театр» шигыренең язылу тарихы, Г. Камал, С. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Кариев белән аралашулары чагыла. Тамашачыга С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның шәле, Г. Кариевның кара савыты, Г. Камалның «Беренче театр» әсәренең кульъязмасы тәкъдим ителә. Биредә аерым тематик экскурсияләр дә, махсус лекцияләр дә оештырыла.

XX гасыр башы – татар әдәбияты-мәдәнияте яңарыш кичергән чор. Беренче композиторлар, беренче музыкантлар, беренче кыллы оркестр, беренче театр – музейда барысы турында да мәгълүмат бирелә.

Тагын бер үзенчәлекле залыбызны «Шагыйрь йолдызлыгы» дип атадык. Анда – XX гасыр башында милләтнең йолдызына әйләнгән күренекле татар уллары-кызлары. Эшләгән эшләре, аралашу даирәләре буенча бер цикл ясау хыялыбыз да бар. Бу залда бүгенге көнгә 41 шәхес турында мәгълүмат тупланган. Шәхси әйберләре күрсәтелә. Тукай белән танышу-аралашулары чагыла. Бертуган Шәрәфләр, Риза Фәхретдинов, Садри Максуди, Әхмәтгәрәй һәм Зәйнәб Хәсәниләрдән калган әйберләр – савыт-саба, җиһазлар, визитка савытлары – болар барысы да хуҗаларының кул җылысын саклаган... Бәлки, кайберләрендә Тукайның да – аның Әхмәтгәрәй һәм Зәйнәб Хәсәниләрдә булганлыгы төгәл билгеле.

Тагын бер тема – Тукай премиясе лауреатлары. Без аларны иҗатларында Тукайны үзләренә маяк иткән шәхесләр дип атыйбыз. Алар турындагы бай материал электрон тупланмаларда да тәкъдим ителә. Премияне алу турындагы документларның төрле чордагылары төрле формада, төрле зурлыкта, төрле бизәлештә – алар шуның белән дә кызыклы.

Әлбәттә инде, «Тукайның мәхәббәте» дип тарихка кереп киткән Зәйтүнә Мәүлүдова... Бу бәхәсле тема. Яңа документлар, истәлекләр өстәлеп тора, һәрберсен чагыштырырга кирәк.

Фәндә бер чыганакка гына нигезләнеп булмый, ул башка чыганаклар белән кисешергә тиеш. Хәзерге вакытта без Зәйтүнәнең Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлау турындагы таныклыгын тәкъдим итәбез. Тукай белән беренче күрешүе хакындагы истәлекләре саклана. Кириллица белән язылган. Блокнотлары бар. Аларда Тукай шигырьләре һәм шул чордагы башка шагыйрьләрнең әсәрләре. Блокнотлар бизәкле, аларга киптерелгән чәчәкләр урнаштырылган. Тукай шигырьләре язылган аерым дәфтәре дә бар. Гомумән, Тукай тирәсендәге һәрбер шәхес — бер йолдызчык.

«Йолдызлы экскурсия» дигән бик кызыклы проектыбыз бар: төрле шәхесләр – рәссамнар, шагыйрьләр, дәүләт эшлеклеләре безгә килеп экскурсияләр уздыралар. Әлеге экскурсияләрнең аерым бер тамашачысы да барлыкка килде. Бер тыңлагач, тагын килү нигә инде дип тә уйларга мөмкин. Ләкин экскурсияне алып баручы һәр кеше Тукайны үзенчә ача. Рөстәм Абзов Тукайның беренче гонорарына сатып алынган шкатулкасы янына килеп җиткәч, туктады да калды... Шылт иткән тавыш та юк. Шактый торганнан соң: «Мин, моңа карап, Тукайны аңладым...» – диде. Шкатулка агач төбе формасында. «Шүрәле» әсәрендә сурәтләнгән төс-бизәкләр, «аллы-гөлле гөлләр-гөнҗәләр» дә бар. Җаекта яшәгән чагында шагыйрь, мөгаен, Кырлай урманнарын, чәчәкле болыннарны сагынгандыр.

Урман хуҗалыгы министры урынбасары Тукайның Шүрәлесен үз биләмәсен сакларга чыккан чын урман хуҗасы итеп ачты. Кемдер, «Казан» шигыренә бәйләп, шагыйрьне эшче кешеләрне яклаучы буларак аңлатты; Төркиядән килгәннәрнең шагыйре тагын үзгә иде...

Гомумән, хәзерге вакытта да экскурсияләрнең ниндие генә юк: таныштыру экскурсияләре, аерым темага багышланганнары, робот-экскурсовод алып бара торганнары бар. Ул өч телдә: татарча, русча, инглизчә сөйли ала. Шулай ук аудиоэкскурсияләр тәкъдим итәбез, интернет челтәрләрендә дә безнең экспонатлар белән танышырга мөмкин. Экскурсиягә алдан заказ бирергә була. Исемлектә күрсәтелгән темалар арасыннан үзең теләгәнен сайлап алу мөмкинлеге дә бар.

Бездә хәзер яңа программалар эшли: балалар өчен аерым, туристлар өчен аерым... Аларны гамәлгә ашыру өчен, әлбәттә, музей коллективының белемле, тәҗрибәле булуы зарур. Бу уңайдан музейда озак еллардан бирле эшләүче тәҗрибәле хезмәткәрләрне атап

Тукайның шәхси әйберләре:
түбәтәй;
Әхмәтгәрәй Хәсәни бүләк иткән көмеш җиң каптырмалары;
юл кәрҗине һәм сөлгесе;
кара савыты (шагыйрьгә Санкт-Петербургның икенче мөселман мәхәлләсе татар мәктәбе укучылары 1912 елның язында бүләк иткән);

Санкт-Петербург күренешләре сурәтләнгән савыт. Шагыйрь аны 1912 елда сатып ала.

Уен залында балалар Тукай геройлары белән «яшәп» ала.

китәсем килә: Нәгыймуллина Резеда, Тябина Лена, Медведева Ләйсән. Шулай ук залларны караучылар да бик тырышып хезмәт итә: Зыятова Равия, Камалеева Айсә, Вахитова Ляля, Кондратюк Анастасия, Армянская Надежда, Гәрәева Дания, Хисмәтуллина Фазилә, Равилова Миләүшә, Сабирова Наилә.

Тукай белән аралашкан кешеләргә багышланган махсус экскурсияләр, әдәби-музыкаль кичәләр дә оештырабыз. Шулай ук фәнни эш белән дә шөгыльләнәбез. Ф. Әмирханның «Хәят» әсәренең бездә саклана торган икенче өлешен гарәп графикасыннан кириллицага күчереп, әсәрне уку кичәсе оештырдык. Аннары аны Тарих, тел һәм сәнгать институты белән берлектә бастырып чыгаруга ирештек. Мәхмүт Галәү, Фатих Әмирханнарның иҗатларын өйрәнү буенча да зур эш башкарыла.

Быел 1 апрель көнне Тукайның «Печән базары» әсәренә багышланган экскурсия тәкъдим иттек. Эмиль Җәләлетдинов килеп әсәрне укыды, әдәби экскурсия узды.

Башлангыч сыйныф укучыларын һәм кечкенә балаларны күздә тотып эшләнгән Уен залыбыз бар. Ул Шүрәледән башланды. Балалар анда Тукай әсәрләре буенча мультфильмнар карыйлар, һәркайсы үзе яраткан персонажны кисеп ясап, мультфильм ясый ала. Тукайның балалар өчен язылган әсәрләрен уку, рәсемнәрне төсле буяулар белән буяу шулай ук кечкенәләр өчен бик мавыктыргыч. Иң кызыклысы: безнең ул залда Шүрәле, Су анасы, Кәҗә, Бәрән, Авыл егете, Авыл кызы яши. Яши, дим, чөнки алар чыннан да тере кебек, балалар хәтта алар белән «үз телләрендә» килеп-килеп сөйләшеп тә алалар.

Һәр якшәмбедә, сәгать көндезге икедә «Гаилә белән музейда» акциясе уздырыла. Бу көнне, бары тик керү билетлары хисабыннан гына, экскурсия өчен өстәмә түләмичә, музей белән дә танышырга була. Алга таба балаларны берничә сәгатькә музейда калдырып китү мөмкинлеге дә булачак. Экспонатларны җанландырып, Тукай иҗаты, Тукай персонажлары турында мәгълүмат бирә торган уеннар оештырабыз. Шүрәлене бөтен балалар да белә, ә менә Тукайның Мияубикәсе белән барысы да таныш түгел. Март аенда, Халыкара песиләр көне уңаеннан, бездә Мияубикәгә багышланган күп чаралар үтә. Бу чаралар уеннар аша алып барыла.

Музеебызда уза торган «Әлифба бәйрәме» инде бер матур традициягә әверелде. Хәзер аңа Казан шәһәре мәктәпләре генә түгел, якын-тирә районнар да кушылып китте. Балаларны белем дөньясына алып кергән беренче дәреслекне зурлау кичәсе бу. Беренче өлешендә балалар Әлифба турында сөйлиләр, Тукайның шигырьләрен укыйлар, икенче өлештә уеннар уйныйбыз, Тукай музее, Әлифба белән бәйле кроссвордлар чишәбез.

Хәзерге вакытта бездә абонемент эшли башлады. Аны шәһәребезнең 16нчы гимназиясе белән бергәләп башладык. Укучылар шимбә көнне безгә килеп, Тукай иҗаты белән бәйле темаларга белемнәрен арттыралар.

Музейны тамашачы өчен кызыклы, мавыктыргыч итү максатында яңадан-яңа идеяләр уйлап табарга тырышабыз. Әлегә балалар

өчен робот, ишек төбендә урнаштырылган телефон бик кызыклы булды. Ул телефоннан Тукай белән бәйле төрле тарихи йортларга («Болгар номерлары», «Шәрекъ клубы» һ.б.) «шылтыратып сөйләшеп алырга» мөмкин.

Төзекләндерүгә кадәр һәр елны «Карга боткасы» үткәрә идек. Башта балалар экспонатлар белән танышып чыгалар. Һәр залда андагы экспонатлар белән бәйле аерым биремнәр әзерләнгән була. Аны үтәгәч, балаларның капчыкларына ярма салабыз. Аннан соң бакчада театральләштерелгән тамаша күрсәтелә, «җыелган ярмалардан» Карга боткасы пешерелә. Анда инде Яз да килә, билгеле инде, Шүрәле дә катнашмый калмый.

Җәйгә таба бездә Сабантуйлар башлана. Без аларны Тукайда сурәтләнгәнчә алып барабыз. («Исемдә калганнар»да бу милли бәйрәм бик матур тасвирлана.)

Быел җәен, пәнҗешәмбе көннәрендә, балалар өчен ачык музей оештырырга ниятебез бар. Сабантуйлар, бию буенча мастер-класслар, Казан халкы һәм башкалабыз кунаклары өчен әдәби-музыкаль кичәләр оештырырга уйлыйбыз.

Тукай музееның эше бу бина белән генә чикләнми. Иске Татар бистәсе буенча да экскурсияләр оештырыла. Быел беренче тапкыр, Иске шәһәр Префектурасы белән берлектә, 18 май көнне «Тукай урамы бәйрәме» уздырачакбыз. Һәм бу проектыбыз дәвамлы булыр дип уйлыйбыз.

«Казанда Тукай урыннары» дигән махсус экскурсиябез бар. Анда инде Иске бистә генә түгел, шәһәребездәге Тукай белән бәйле бөтен биналар, шагыйрьнең һәйкәлләре дә керә. «Шагыйрь бишеге» дигән 8 сәгатьлек экскурсиябез Казан, Әтнә, Кушлавыч, Кырлай авыллары буйлап уза. Бик әчтәлекле сәяхәт, юлда да, Тукайның истәлекләренә нигезләнеп (истәлекләрендә, шул авыл аша уздым, шуны күрдем, дип язган бит), мәгълүмат бирү бара.

Әлбәттә, безгә эшләргә зуррак мәйдан кирәк. Тукай иҗатына багышланган картиналар, рәсемнәр, әсәрләренә иллюстрацияләр күп. Урыныбыз булса, аларны күрсәтер идек. Шундый проект белән чыккан да идек инде. Безгә яшь дизайнер, архитекторлар төркеме «Музей урамнары» проекты да тәкъдим иткән иде. Берничә бинадан торган музей мәйданы, музей урамнары. Безгә шундый өлешләр кирәк. Балалар залы ул нәниләр өчен, безгә бит зуррак балалар белән дә эшләргә кирәк. Районнардан да укучылар күп килә. Аеруча Арча, Саба, Апас, Яшел Үзән, Әтнә, Биектау районнары актив. Соңгы елларда Мәскәү, С.-Петербург балалары да килә. Алар Тукайның кем икәнен белеп киләләр, хәтта бер-ике шигырен дә сөйләп бирә алалар. Бу бик күңелле күренеш.

Татар телле экскурсияләр саны күбәйде. Катнаш төркем булса, экскурсия рус телендә барса да, Тукай шигырьләрен татарча укуны үтенәләр, татар теле аһәңен ишетәсебез килә, диләр. Электрон җайланмалар өч телдә.

Кыскасы, Тукай һәрвакыт актуаль. Тукайны һәр буын үзенчә кабул итә: балачакта бер Тукай, үсмер чакта – икенче. Безнең музей галимнәр белән тамашачы арасындагы бер лаборатория кебек: алар хезмәтләр яза, без экспонатларны туплыйбыз, өйрәнәбез һәм мәгълүматны халыкка тапшыра барабыз.

Музейга килгән кешеләр тарафыннан да төрле мәгълүматлар килеп ирешә. Әлбәттә, без аларга бик сак карыйбыз. Мәсәлән, «Минем әбием Тукайның сөйгәне булган», – дип килүчеләр бик күп. Нишлисең, бөекләр тирәсендә легендалар күп була бит инде...

Радиога беренче тапкыр туры эфирга баруым истә. Чаллыдан берәү шалтырата: «Бездә трамвайлар соңгы тукталышка кадәр барып җитмиләр, моны Тукай исеме белән хәл итеп булмас микән?» – ди... Күрәсез, Тукайның бакыйлыкка кучүенә инде гасырдан артык вакыт узган, ә халык әле дә аннан яклау көтә!..

Хәзер инде без тәрәзәбездән музей тәрәзәләренә карап андагы хәрәкәтне барлап торабыз. Музейда экскурсияләр бара, халык йөри, димәк. Шуңа куанабыз.

Редакциябезгә килергә җыенган кешеләрнең «Кайда утырасыз?» дигән соравына да, маяк итеп: «Тукай музее артында!» – дибез. Һәм... Казан шәһәрендә туган, яшәгән күп кенә татар кешеләренең дә Тукай музееның кайда урнашканлыгын белмәвенә, әлеге музейны бер тапкыр да килеп күрмәвенә чын күңелдән аптырыйбыз. Алай гына да түгел, кәефсезләнәбез.

Бүгенге көндә әлеге йортта шундый мәгънәле, кызыклы, мавыктыргыч тормыш кайный. Тукай һаман да халкыбызны тәрбияли, уянырга, уйланырга, милләтебез-өммәтебез белән горурланырга чакыра.

Татарларда Боз озату йоласы

Кешенең яшәеше-көнкүреше табигатькә бәйле. Табигатьнең торышы, ягъни кояш, туфрак, кар, боз, яңгыр, җилнең кешегә карата никадәр миһербанлы булуы кеше тормышының сыйфатын турыдан-туры билгели. Татар халкы элгәре вакытлардан ук табигатьне олылап, аның рәхим-шәфкатенә таянып, үз гомерен көйләгән. Табигатьтәге үзгәрешләргә зур игътибар биргән. Татарларның табигатькә булган сизгер мөнәсәбәте, аны җан белән тоюы аеруча сынамышларда чагылыш тапкан, мәсәлән: *Кояш чыккан вакыт һава кызарса, шул көнне яңгыр булыр; Кыш көнендә кояш тирәсендә нур түгәрәге күренсә, буран булыр. Әгәр дә бу түгәрәк кояшка якын булса, аяз булыр; Болытлар бергә өелеп бик югары күтәрелсә, җылы яңгыр булыр; Җәй көнендә башта җылы җил булып, соңыннан җилле яңгыр булса, боз явар; Әгәр кар дулкын сыман булып кат-кат күренсә, ашлык бик яхшы булыр; Беренче күк күкрәве кыйбла ягыннан булса, ел яхшы булыр. Әгәр көнбатыштан ишетелсә, яхшылыкка түгел. Әгәр көнчыгыштан ишетелсә, бик яхшы ел булыр; Бодайны томанлы көнне чәчсәң, яхшы булыр*[1] *һ.б.*

Табыннар мул, күңелләр иркен, тормышлар бәрәкәтле булсын өчен, татар халкы табигатьтән көч-ярдәм сораган, яшәргә уңайлы шартларны галәм кануннары белән килештереп тудырган. Изге көчләрне ризалату, алар белән уртак тел табу, яшәү барышында очраган авырлыкларны җиңү өчен, татарлар теләкләр теләп, махсус йолалар үткәргәннәр, бәйрәмнәр уздырганнар.

Татарлар, гадәттә, яшәү урыны итеп су буйларын сайларга тырышканнар, шуңа күрә су белән бәйле үзгәрешләргә карата гаять уяу булганнар. Елганың бозланып катуы, язга авышкач, «йокыдан уянуы» һ.б. – барысы да исәпкә алынган. Елгада боз китү күренеше исә күңелләрдә бәйрәм хисе кабыза торган аерым бер вакыйга булган. Татар халкының сынамышларында боз китүгә бәйле кызыклы күзәтүләр табарга мөмкин. Күренә ки, татарлар, боз китүгә карап, чәчү эшләрен, гаилә тормышын җайлау серләрен фаразлаганнар: *Елгаларда боз төнлә китсә, ашлык булыр; Елгаларда яз көне боз тиз әрчелсә, ашлык уңар; Яз көне елга кырыйларында боз калса, ашлык уңмас; Боз утырып калган елны авырлык булыр; Елга бозлары кай көнне киткән булса, ашлыкны шул көнгә*

туры китереп чәч[2]*; 6-сында*[3] *тулы ай — Язгы ташу суга бай*[4].

Татарларда боз китүгә нисбәтле аерым йола уздырылган. 2018 елда Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге тарафыннан Татарстанның Нурлат һәм Чистай районы авылларына оештырылган комплекслы фольклор-этнографик экспедицияләр барышында без әлеге йоланың төрле атамаларына тап булдык: *боз озату, бозлар акканны карау, боз карау, ташу карау* (чистай сөйләше). Фәндә йоланың түбәндәге атамалары мәгълүм: *боз карарга бару, боз озату* (тау ягы тархан сөйләше, казан арты лаеш сөйләше), *йазгы суны озату* (нократ сөйләше), *ташкын бакма бару* (бастан сөйләше. Рязань), *су озату* (хвалын сөйләше), *пос озату* (себер татарлары сөйләше)[5], *зин киту* (Пермь губерниясенең Көңгер, Оса, Пермь, Красноуфим өязләре)[6] һ.б.

«Боз озату» бәйрәмен уздыру бозның кузгалу вакытына бәйле. Авыл өчен бу зур вакыйга булган. Йола иртә дә, көндез дә, кич тә, төнлә дә үткәрелә алган.

Боз кузгалганда, үзенчәлекле шаулау ишетелгән. Балалар «Боз китә, боз китә!» дип, хәбәрне авыл буйлап таратканнар. Шул ук минутта яңалык елгадан читтәрәк урнашкан авылларга да барып җиткән. Елга буена бозның агуын карарга барлык халык чыккан, ерак авыллардан ат иярләп тә килгәннәр. Яшьләр иң матур киемнәрен кигән, апалар иң яхшы шәлләрен япкан. Авылның һәр тыкрыгында, һәр урамында көлү, җыр, гармун тавышлары ишетелгән. Урамы белән халык су буена төшкәндә, алгы рәттә гармунчы барган. Халык елганың бер урынында гына җыелмаган, яр буйлап төрле җиргә килеп баскан. Нурлат шәһәрендә яшәүче Ислам Кәрим улы Бәхтияров (1928) әйтүенчә, яшьләр күперләр янында җыела торган булган.

Төрки халыклар су авырудан, бәхет-сезлектән арындыра, елгалардагы бозлар белән бәла-казалар агып китә дип уйлаган, шайтаннар боздан курка дигәнгә ышанганнар. Шуңа бәйле, авырулардан котылу өчен, суга корбан китергәннәр. Татарлар «Боз озату» йоласында бозга салам салып, ут төрткәннәр һәм аны агызып җибәргәннәр. Саламны балалар өй-ызба башларыннан җыеп китергән. Балалар алып килгән саламны гадәттә егетләр яндырган. Күпердән-күпергә саламның бозда ничек януын караганнар, сүнмәсен өчен, саламны өстәп куйганнар. Кызлар бу вакытта күпердә тыпыр-тыпыр биеп торган (Нурлатта Ислам Кәрим улы Бәхтияровтан (1928) язып алынды). Нурлат районы Иске Әмзә авылында гомер итүче Фәимә Нәзим кызы Гатина (1930) искә төшерә: Иске Әмзә авылының Гәрәй елгасында боз акканда, егетләр генә ут сала иде, ди; кыюраклары бозга утырып та китәләр, бер боз кисәгеннән икенчесенә сикерәләр, аннары ярга сикереп төшәләр.

Нурлат районы Якты күл авылында яшәүче Мәрьям Зариф кызы Гайнуллина (1934) белән Фәридә Мәҗит кызы Фәйзуллина (1961) искәртүенчә, малайлар яр буенда учаклар ягып, учак аркылы да сикерә торган булганнар. Ут яндыру борынгыдан ук чистарыну, кайгыдан котылу дигәнне аңлата. Татарларда саламнан кала башка әйберләрне дә яндырып агызганнар. Мәсәлән, Татарстанның Азнакай районында «Боз озату» йоласын үткәргәндә, чүпрәктән, таяктан, саламнан ясалган тамгалы карачкыны бозга бастырганнар һәм яндырып җибәргәннәр, шул карачкы артыннан карап барганнар[7]. Себер татарларында исә курчак ясау ырымы сакланган. Каен тузыннан «тусайак» ясаганнар, аңа курчакны куйганнар, аннары бозга утыртып җибәргәннәр. Авыру-сырхаулар, хәвеф-хәтәрне агызып алып кит, дип теләгәннәр[8].

Татарларда шулай ук, авыру чирләр китсен, «Чирем-чырым коелсын, боз белән агып китсен» дип, иске әйберләрне суга агызып җибәрү гадәте дә булган (Апас районы Урта Балтай авылында яшәүче Нурия Хәлиуллина, 1953)[9]. Язгы ташу сулары авыруларны алып китсен өчен, тәңкәләр ыргытканнар, кулларны бозлы су белән юганнар[10]. Дәвасы булсын дип, халык бәйрәмдә хәтта боз ялаган.

«Боз озату» йоласын үткәргәндә, суга бәхет, уңыш, игелек теләкләре теләп тә төрле әйберләр агызганнар. Мәсәлән, Татарстанның Чүпрәле районында өлкән яшьтәгеләр ташу суына төенчеккә әзерләнгән ырым бөтиен, ә кызлар кульяулыкларын агызып җибәргәннәр[11]. Кайбер авылларда авылның аксакалы күпердән елгага ашлык бөртекләре сибә торган булган һәм мондый теләкләр әйткән: «Илләребез, җирләребез имин булсын, гаиләләрегезгә кайгы ишек какмасын, булган борчу-хәсрәтләрегез шушы язгы сулар белән агып китсен! Балалар сәламәт, имин, игелекле булып үссен!»[12].

«Боз озату» бәйрәмендә яшьләр бозга теләкләр, гаилә бәхетен теләп, хатлар да язарга өлгергән. Татар халкында боз китүгә бәйле шундый әйтем дә бар: «Бозлар калмасын. Бозлар калса – кызлар кала», ягъни кызлар,

кияүгә вакытында чыкмыйча, бәхетсезлеккә дучар була дип фаразлаганнар. Шуңа нисбәтле «Боз озату» йоласында яшьләр бозларны ярдан этеп җибәрә торган булган, картлар моны нык игътибарда тоткан.

«Боз озату» бәйрәмендә яшьләр, балалар кичкә кадәр уйнаганнар, җырлаганнар, биегәннәр. Нурлат районы Кизләү авылында гомер итүче Зәйтүнә Сәмигулла кызы Әхмәтова (1932), йоланы искә төшереп, болай диде: «Чирмешән буе. Тур саен, тур саен төшәләр иде. «Өзелеш» уйный идек. Өзелеп китәләр парлап. Куалар бер-берен. Көтүче кеше куып тотарга тиеш».

Гармунчылар гадәттә авыл көйләрен, урам көйләрен өздереп уйнаган. Халык бию такмакларын такмаклап та биегән. Су буенда кардан арчылган корырак урыннарда качышлы, куышлы, «Күпер сугу», «Йомырка тәгәрәтү», «Талчыбык», «Назалы», «Кул җибәреш», «Кул өзеш», «Чума үрдәк, чума каз» һ.б. әйләнбәйлән, түгәрәк уеннары, хәрәкәтле уеннар уйналган. Яшьләр бигрәк тә каршы сафка тезелеп һәм парлашып уйнала торганнарын яраткан. Кызлар һәм егетләр кара-каршы ике сафка тезелеп җыр әйтешкән. Кызлар егетләрне, егетләр кызларны үчекләп шаян җырлар җырлаган. Хәтта җыр ярышлары уздырылган. Яшьләр ике сафка бүленеп, каракаршы баскан. Алдан хәзерләнеп тормаганнар. Шул ук минутта җыр чыгарганнар һәм шул җыр белән каршы яктан бер уенчыны үз якларына «әсирлеккә» алганнар:

Ташу вакыты җитмичә
Күперне кузгатмагыз;
Чиле-пешле җыру белән
Күңелне болгатмагыз[13].

Яшьләр дә, балалар да «Кабыргалы, камчылы» уенын яратып уйнаганнар. Уенның тәртибе мондый. Уйнаучылар 10 м ераклыкта ике саф булып кара-каршы тезеләләр. Беренче төркем уйнаучылары, кулга-кул тотынышып, «Кабыргалы, камчылы» такмагын әйтәләр һәм «чылбыр»ны өзәчәк уйнаучының исемен атыйлар.

Кабыргалы, камчылы,
Тама торган тамчылы
Ал кирәк, гөл кирәк
Безгә матур Айгөл кирәк.

Чакырылган уйнаучы, йөгереп барып, каршы яктагы «чылбыр»ны өзәргә тиеш. Өзә алса, каршы якның бер кешесен үз ягына алып китә. Өзә алмаса, шул якта кала. Уен шулай бер яктагылар икенче якка чыгып беткәнче дәвам итә.

Коры җирдә балалар «12 таяк» уйнаганнар. Балалар санамыш ярдәмендә «гөрләүче» («көтүче») сайлыйлар. Бүкән яки кирпеч өстенә 30-40 см озынлыктагы такта куела. Тактаның бер башына 10 см озынлыктагы 12 таяк салына. Тактаның бер очына җыелган 12 таякны, тактаның икенче очына басып, «чәчәләр» дә, уйнаучылар як-якка сибелә. Гөрләүче таякларны тактага тезә кала, шул арада балаларның кайсы кая яшеренә. Гөрләүче качкан баланы табуга, такта уртасына кул белән кагылып, табылган уйнаучы исемен әйтә. Шулай итеп, гөрләүче барлык уенчыларны эзләп табып, тамгалап бара. Гөрләүче эзләп йөргәндә, берәр бала тактага килеп таякларны һавага чөйдереп җибәрә алса, гөрләүче кеше үз урынында кала. Әгәр ул тактага басарга ирек куймыйча, барлык балаларны да табып-күреп тактага таягы белән сугып чыга алса, яңа гөрләүче сайлана.

«Боз озату» йоласы хәзерге вакытта Татарстанның Азнакай, Актаныш, Апас, Кама Тамагы, Минзәлә, Нурлат, Саба, Чүпрәле районнары авылларында һаман да үткәрелеп килә. Мәдәният хезмәткәрләре әлеге йоланы кабат кайтару өчен күп көч куя: йоланы сәхнәләштерә, фәнни эзләнүләр алып бара, авыл картларыннан истәлекләрен яздырып ала, бәйрәмгә балалар фольклор төркемнәрен җәлеп итә һ.б. Татар халкының мирасы бик бай, гореф-гадәтләре мәгънәле һәм эчтәлекле. Иң мөһиме: йолада татарларның табигатьне олылау, аның тәртибе һәм хәрәкәте белән санлашу фәлсәфәсе чагылыш тапкан.

Гөлнара МАНСУРОВА,
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең фәнни хезмәткәре

---

1. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда / Нәкый Исәнбәт. — 2нче басма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. — 1нче т. — Б. 590, 592, 595, 605, 606.
2. Исәнбәт Н.С. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 606.
3. Гыйнвар аеның алтынчы көне.
4. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 3 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — Б. 43.
5. Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. — Б. 110, 111.
6. Уразманова Р.К. Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX-нач. XX вв.). / Историко-этнографический атлас татарского народа. — Казань: Изд-во ПИК «Дом печати», 2001. — С. 20.
7, 9-12. Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең Матди булмаган мәдәни мирас фонды.
8. Баязитова Ф.С. Күрсәтелгән хезмәт, Б. 111.
13. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. — Б. 181.

Олег ХИСАМОВ

Равил Зәһидуллин. «Әти янында».

Туганнарның төбе бер

(Дәвамы. Башы 2019 елның 1нче санында)

Традицион татар гаиләләрендә эшне яки ашны бисмилла әйтеп башларга, китапка кулны юып тотынырга өйрәтәләр. Өлкән буын – әби-бабайлар намаз укырга тотынган икән, аларның бу гамәле бозарга ярамаган изге бер эш итеп карала. Намаз укыган өлкәннәр янында тавышлану да, көлеп утыру да, әрлебирле йөренү дә зур әдәпсезлек санала.

Балаларны мондый көнкүреш әдәбенә әниләре кече яшьтән, үзләренең үрнәгендә өйрәтеп килә. Әйтик, татарларда җиләк-җимеш үстерү, ризык әзерләү, өй җыештыру кебек эшләр белән хатын-кызлар шөгыльләнә. Алар кыз балаларын да 5-6 яшьтән өй эшләренә, кул эшләренә (чигү чигәргә, шәл бәйләргә, тегәргә), ашарга пешерергә өйрәтә башлыйлар. Кече эне-сеңелләрен карарга булышкан кыз бала исә, үзе дә сизмәстән, әни кешедә булырга тиешле сыйфатларны – сабырлыкны, өлгерлекне, җылылыкны үзләштерергә өлгерә. Кыз бала – очар кош, аның канат кагып, башка ояга очар, ягъни килен булып төшәр көннәре дә санаулы гына, ул көн бик тиз килеп җитә. Эшкә осталык, уңганлык менә шул мәлләрдә күренә дә инде. Егетнең атаанасы уларына кәләш сайлаганда кызның шушы осталыгына аерым игътибар итә. Шуңа күрә татарларда, кызны ярәшкәннән соң, ул әзерләгән кыз бирнәсен карау мәҗлесе уздырыла торган булган.

Камиллекнең чиге юк, диләр. Әдәп-әхлак кагыйдәләренең дә иге-чиге күренми. Алар бөтен өлкәгә дә карый, тормышның бөтен якларын да колачлый. Мәсәлән, урманга кергәндә бисмилла әйтеп керү, агачларны сындырмау, урманда кычкырып сөйләшмәү, чүп калдырмау кебек әдәпләрне кем өйрәтә ди-

сез? Гадәттә, урман-болыннарга чикләвек яки җиләк җыярга балаларны өлкән хатын-кыз оештырып алып бара. Элек-электән татарлар арасында урманнан ел дәвамында ипи пешерү өчен колмак җыю, кыш буена җитәрлек урман чикләвеге әзерләү, җир җиләге һәм кура җиләк, бөрлегән, мәтрүшкә кебек урман җимешләрен хәстәрләү киң таралган. Менә шушы эшләрне башкарганда, сүз аралаш та, үз үрнәгендә дә хатын-кыз балаларга гомер буена җитәрлек тормыш сабагы бирергә җитешә дә инде.

Ир-атларның тәрбиясе бераз үзгә, беркадәр кырысрак та тоела. Алар җилкәсендә мал карау (сөт савудан башкасы), бигрәк тә ат белән бәйле эшләр өелеп тора. Татарлар элек-электән ат асрап яшәгән. Сабантуйларда ат чабышлары уздыру, чабышкы атлар үстерү культурасының югарылыгы шуның бер дәлиле. Ат ите кыйммәтле саналып, аннан берсеннән-берсе затлы ризыклар әзерләү киң таралган. Ат тирәсенә хатын-кызны якын китермәгәннәр.

Колын чыннан гаҗәеп бер нәрсә иде: аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була, диләр. Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, әз генә, кыска гына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган ефәк бәйләме кебек үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан, бармак калынлыгы кара тасма кебек булып, койрыктан ялга җиткәнче, кара ефәк йон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка – бу колынны мең, миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз дип күрсәтәләр. Бөтен гәүдәсе, әйтерсең, ходайның үз кулы белән, фирештәләрнең ярдәме белән тигезләп, матур итеп, коелып ясалган. Шундый… сылу, шундый асыл сөяк булып яратылганнар. (Г.Ибраһимов)

Ат ярату, ат тирәсендә кайнашу – татар малайларының иң яраткан шөгыле була. Ир-атлар аларны менә шушы юнәлештә тәрбияләргә омтыла.

Татар гаиләсенең тагын бер аерылгысыз «юлдашы» – сыер. Сыер – җитеш тормыш билгесе. «Сыерлы көн – сыйлы көн» дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр! Авыр елларда нәкъ менә сыер бик күп гаиләләрне ач үлемнән коткарып калган. Шуңа күрә сыерга «Миләшкәй», «Матуркай» дип, матур-назлы сүзләр белән дәшүләренә һич аптырарга кирәкми.

Татар авылларында иң яратып асрала торган кош-корт – каз. Көзге суыклар азагында, кар төшеп, катырып җибәргәч, өйдән-өйгә күчкән каз өмәләре, каз канаты йолкулар, җырлый-җырлый бәкедә каз юулар; талдан үрелгән кәрҗингә каз утыртулар, бәбкә саклаулар, какланган каз, каз бәлеше кебек затлы ризыклар әзерләү – татар тормышының иң матур яклары.

Мондый өмәләр дә, бергәләп аш мәҗлесләре әзерләү дә туган-тумачаны тагын да якынайтучы күзгә күренмәс бер җеп шикелле.

Татар гаиләсендә «кан-кардәшләр» («хәрендәшләр-карындашлар» варианты да бар) атамасы барлыгы турында алдарак та телгә алган идек. Ул әтиләр һәм әниләр ягыннан якын туганнарны белдерә. Һәр туганга ятып, үз итеп эндәшүнең төрле вариантлары очрый: әти һәм әниләр бер булган туганнар – «бертуган абый яки апа», ата-аналарның туганнарының балалары – «тудыка», «туган (туганым, туганкаем) абый яки апа, эне-сеңел», «икетуган абый яки апа, эне-сеңел», «өчтуган абый яки апа, эне-сеңел» дип йөртелә (икетуган, өчтуган вариантларының рус теленнән турыдан-туры тәрҗемә ителгәне күренә). Аерым бер якларда «абзый-түти», «абзыкай-абзыкаем, түтекәй-түтекәем» дип дәшкәннәрен дә ишетергә мөмкин. Хатын-кыз туганнарны «нәнә-тәтә» дип йөртү дә бар.

Өлкән туганнарның хатыннары – «җиңги, җиңгәчәй», ирләре – «җизни» дип йөртелә. Еш кына җиңгиләр – сер сандыгы, иң яшерен серләрне бүлешүче була. Җизниләрдән исә иң беренче чиратта кече ир туганнар – «кайнешләр» – белән уртак тел табу таләп ителә. Шуңа күрә җизнинең кыз ярәшкәндә хәтта нинди бүләк бирүе дә бик мөһим. «Җизни пәкесенә» карап, аңа бәя бирәләр.

Ирләр хатыннарының кече кыз туганнарын «балдыз» – баллы кыз дип йөртәләр. Татар халык авыз иҗатында җизниләрнең балдызларга мәхәббәте турында көлкеле әсәрләр күп, җырлар да байтак, «балдыз сөю язык» дигән тыю да яшәп килә.

Ирләре бертуган булган хатыннарга «килендәш» диләр, ә бертуган кызларга өйләнгән ирләр «баҗай» дип атала. Баҗайлар, туганнар кебек үк, үзара ярдәмләшеп яшәргә тиеш дип санала.

Туганнарның күп булуы – үзе зур байлык. Аларны бергә җыю, кунак итү – иң саваплы гамәлләрнең берсе буларак кабул ителә. Шунысы да бар: туган-тумачаның күбесе читтә таралып, башка җирләрдә төпләнеп яшәргә дә мөмкин бит әле. Сабантуй, Ураза яки Корбан бәйрәмнәрендә, шулай ук

туган көн, туй мәҗлесләре вакытында ерак кардәшләрне дә чакыру мактауга гына лаек гамәл. Алдан ук хәбәрләшеп, алар кайтуны зур әзерлек белән көтәләр: сарыклар суела, бәйрәм ризыклары әзерләнә. Кайтучыларның үз мәшәкате: алар барлык туган-тумачага бүләк-күчтәнәчләр хәстәрли.

Сабан туйлары җитә башласа, йокысы, ялы онытыла иде. Әйне сап-сары балавыздай юып чыгара, мендәр-ястыкларны әйләндерә-әйләндерә мәрхәмәтле кояш күзендә киптерә, сыек чыбык белән иркәләп тузаннарын кага. Мич-морҗаны шомырт чәчәге төсенә кертеп агарта, җиз самоварны ачы катык, ком белән агартып кояш көнләшерлек итеп ялтырата. Агач табаклар, бизәкле агач кашыклар, чуенчүлмәкләр, эреле-ваклы табалар, бәйрәм демонстрациясенә чыккан кебек, киштәләргә, сәке түренә рәт-рәт сөенешеп тезеләләр. Һәммәсенә җан керә! Тәрәзә төбендәге гөл чүлмәкләре тирәли чүпләм башлы апак сөлге өстендә суган кабыгы суында манылган күкәйләр тәгәрәшеп ята, өстәлне төрлетөрле тәкәләр, коймаклар, бавырсаклар, чәкчәкләр бизи.... (А.Гыйләҗев)

Әгәр кунак җыйганда өлкән туганнарның берәрсе, авырыпмы, башка сәбәп беләнме, килә алмый икән, алар янына күрешергә керү гадәте бар. Күрешергә кергәндә чәй яки нинди дә булса тәм-томны күчтәнәчкә алып керү өлкән кешенең күңелен күтәрер өчен дә, үзеңә савап җыярга да бер сәбәп булып тора.

Татарлар арасында нәселнәсәпкә карап үзбилгеләнү киң таралган. Ул милли горурлыкның бер чагылышы булып тора. Бер-берсе белән танышканда, күрешкәндә, «мин шул нәселдән» дип әйтү бар.

Татар халкы күршеләрен дә туганыннан ким күрми якын итә, үзара ярдәмләшеп яшәргә омтыла. Элек-электән, икмәк кирәкме, тозмы, шырпымы – шуның ишене күршегә кереп сорау, күрше белән бергәләп тормыш итү, аларга таяну булган. «Күрше хакы – тәңре хакы» дигән әйтем дә шул хакта сөйли.

Күп кенә эшләрне татарлар туганнары, күршеләре белән бергә җыйналып – «өмә» ясап башкарган, ул күренеш бүгенге көнгәчә дәвам итә. Халыкның йола-гадәтләре арасында «йорт өмәсе», «печән өмәсе», «каз өмәсе», «тула өмәсе» үзләренең күләме, күңеллелеге ягыннан аерылып тора. Өмәләр вакытында бергәләп эшләү, күңел ачу күзәтелә. Авыр хезмәтне җыйнаулап башкарганнан соң хәзинәдә бары белән сыйлану, гармунга кушылып җырлау, кара-каршы такмак әйтешү, тыпырдап бию бер яктан күңелне рухи сафландырса, икенче яктан, бергәлектә, бердәмлектә никадәр көч булуын дәлилләү дә булып торган.

Татарларда гаилә-туганлык мөнәсәбәтләрен, яратып, «туганлык җепләре» дип атыйлар.

Фото Свердловск өлкәсе Түбән Сырга районының Аракай авылындагы Туган якны өйрәнү музее фондыннан алынды.

Өлкәннәрнең «туганлык җепләре өзелмәсен» дип теләк теләүләре шушы мөнәсәбәтләрнең татар кешесе өчен никадәр әһәмиятле булуын күрсәтә. Туганлык җепләрен исә нигез, туган җир бәйләп тора. Нигез – кан туганнарны бергә туплап, туган җиргә бәйләп торучы изге бер урын, оя, «төп». Хәер, алай гына да түгел. Нигез – хәтер сакчысы, мәңгелек бер учак. Әйе, әйе, нәселнең тарихи хәтерен саклаучы сүрелмәс учак...

(Дәвамы бар)



Сыер алсаң, танып ал...

Традицион мәдәниятне үстерү үзәге тарафыннан Татарстан Республикасы Чистай районына оештырылган экспедиция барышында без татар халкында терлек асрау традицияләрен өйрәнүебезне дәвам иттек. Әлки, Апас, Тәтеш, Чүпрәле районы татар авылларында теркәп алынган мал тоту белән бәйле йола-гадәтләр, ышанулар һәм тыюлар Чистай районы татар авылларында да очрады. Ләкин шул ук вакытта моңа кадәр теркәлмәгән табышларыбыз да бар. Мәсәлән, сыер сатып алуга бәйле йола ритуаллары, гадәтләре (Каргалы авылы). Бу йола ике көн буе башкарыла һәм 5 этаптан тора.

Беренче этап. Сыерны алып кайтканчы ук, яңа хуҗа аңа исем куша, яңа исем белән эндәшеп сөйләшә, үзенең аның хуҗасы булуын әйтә. Сатучы да сыерны яңа хуҗа белән таныштыра, ипи алып чыгып, яңа хуҗага бирә, сатып алучы ул ипине сыерга ашата.

Икенче этап. Сыерның элекке хуҗасы малны яңа хуҗаның өенә кадәр озата бара. Сыерны сарайга керткәннән соң, сава торган чиләге белән көтүгә куа торган чыбыркысын калдырып, капканы үзе ябып кайтып китә.

Өченче этап. Яңа хуҗа сыерны сарайга керткәннән соң, йорт иясенә мөрәҗәгать итә, аны да терлек белән таныштыра һәм сыерны рәнҗетмәвен сорый.

Дүртенче этап сыер сатып алуның икенче көнендә башкарыла торган ритуал тәртипләреннән тора. Бу көнне терлекнең элекке хуҗаларын парлап кунакка чакыралар һәм аларны сөтле чәй белән сыйлыйлар.

Бишенче этап. Сыерны көтүдән яңа йортка кайтырга ияләндерү. Бу этап яңа хуҗаның, кулына ипи тотып, көтү каршыларга төшүе, сыер белән сөйләшә-сөйләшә, аңа яңа йортка кайтырга кирәклекне әйтеп, үзе артыннан ияртеп кайтуы белән тәгәлләнә.

Шулай итеп, Чистай районында яшәүче татарларда сыер сатып алу мөһим бер гамәл буларак аңлана һәм тулы бер йола буларак үткәрелә. Сыерны сатучы һәм сатып алучы хуҗалар катнашында уза торган йолада сөт чиләге, көтү таягы һәм чыбыркысы, сатып алынган сыер сөте белән ясалган чәй һәм ипи ритуаль предметлар буларак чыгыш ясыйлар. Йоланың мифологик эчтәлеген абзар иясенә ирештерелә торган мөрәҗәгать тәшкил итә.

Фикерләребезне дәлилләү максатыннан, экспедиция кысаларында язып алган аутентик текстларыбызны тәкъдим итәбез.

«Сыерны сатып алганыбыз бар. Демидовлардан сатып алдык. Сыерлары бик яхшы иде, 6 яшьлек иде. Барып алдык ирем белән икәү, Мансур белән. Кердек өйләренә, чәй эчерделәр башта. Аннан соң сыер янына чыктык. Сыерга исеме белән атап әйттем. Үзем исем куштым. Гөлгенә дип. «Хәзер инде син

безнеке буласың, яңа хуҗаң мин булам, – дидем. – Иртәгә инде бу якка карама, безгә туры кайт», – дидем. Сатучы хуҗа: «Хәзер инде синең – яңа хуҗа, – ди. – Безгә, – ди, – кайтма, – ди, – кирәкми, – ди. – Гөлгенә, – ди, – синең яңа хуҗаң, ул яңача тәрбияләр», – ди. Башларын да сыйпады. Сыер аңлаган кебек карап тора күзеңә. Аннары 1 буханка ипи алып чыкты, миңа тоттырды. Мин ваклап бирә башлагач, сразу ашарга тотынды сыер. Аннан соң сыерның чиләген бирде, и куган чыбыркылары бар иде, шуны бирде. Хуҗасы сыерны безгә хәтле алып кайтты, без алдыннан кайттык. Бауны үзебезнекен алып бардык. Алып кайтып, капка төбенә килүгә, ирем кереп китүгә, сыер да кереп китте. Хуҗасы сразу чиләкне дә, чыбыркысын да куйды да: «Наилә апа, – диде, – бик зур рәхмәт үзегезгә, – диде, – хәзер инде сезгә хезмәт итсен», – дип, капканы үзләре яптылар да, китеп тә бардылар, кызу-кызу.

Мин сарайга алып кергәч, йорт иясенә дә әйттем: «Каршы ал, сарайга кертәм, обижать итмә, бу безнең сыер була», – дидем.

Без икенче көнне Демидовларны кунакка, чәй эчәргә чакырдык. Үзләренең сыерларының сөте белән чәй эчердек. Хуҗасы сарайга чыккан иде, сыер таныды, кычкырды, алдында ризыгы булгач, бик игътибар итмәде, ашавын эчүен белде.

Көтүгә кудык икенче көнне, көтүдән каршы алырга төштем. Көтүдән кайтканда элекке хуҗаларының капкалары янына басып кычкырып тора, үзе миңа карый. Мин: «Кызым, Гөлгенә, безгә инде, – дидем, – ипи дә алып килдем», – дидем. Шуннан минем белән кайтып китте. Бүтән бер дә кычкырмады аларга. Кайтуга тәмле итеп ризыгын әзерләп куя идем. Хайван да назлаганны ярата бит» (Таһирова Наилә, Татарстан Республикасы, Чистай районы, Каргалы авылы).

Чистай районы Нарат Елга һәм Дүртөйле авылларында терлеккә күз тигәндә, яки терлекнең үрчеме тукталганда башкарыла торган имләү-өшкерүләрне дә очраттык. Беренче очракта, күз тигәнне чыгаручы махсус сүзләр әйтелсә, икенче очракта, информант белгән дога-аятьләрен укып терлекне өшкерә һәм шул өшкерелгән ризыкны терлеккә ашата.

1) «Күз тигәннең күзе кайтсын,
Кутәрә алмый биле сынсын,
67 ала күз,
67 кара күз,
Кем икәнен белмимен,
Әллә хатын, әллә кыз,

Илля-билля шифараху, – дип иңбашыннан ике якка төкерергә куша иде әни. Күз тигән булса карыштыра, авыз ачыла, укый алмыйсың, иснәтеп тә тора, авыз да чалшаеп китә. Терлек янында өч тапкыр укыйм мин аны, аннары терлек җиңеләеп китә» (Сибгатуллина Сәгыйдә, Чистай районы, Нарат Елга авылы).

2) *«Сарыкның имен имлим. Имләсәң, бер дә сарыгың бетмәс, дия иде әбиләр. Белгәннәрне укып, әпәйне тотып, өч мәртәбә казанны әйләндерергә. И шул әпәйне аннары турап бирәм инде, сарыкка ашатам. Искә төшкәндә, терлек бетә, сарык үлә башласа өшкерәм. Әпәйне өшкереп бирәм инде, Колһуалла, Нәс, Аятел Көрси, белгәннәремне укыйм инде. Догаларның саны юк. Уң яктан тотынам әйләндерергә. Шулай өшкерүгә, сарыклар җайлашып китә»* (Галимова Маһинур, Чистай районы, Дүртөйле авылы).

Кызыл Болгар авылында сыер бозаулаган җиргә, «бозау тимер күк нык булсын өчен», лом яки балта ыргыталар. *«Соңгылык өстенә тимер бәрергә кушалар иде. Терлек таза булсын дип, соңгылык төшкән җиргә бәрә идек. Без балта бәрә идек»* (Хәсәншина Дамирә, Татарстан Республикасы, Чистай районы, Кызыл Болгар авылы).

Татар Сарсазы авылында исә сугымнан соң үткәрелә торган «Тутырмага җыю» гадәтен язып алдык. Бу йола, гадәттә, йортта эре терлек суйганнан соң үткәрелә. Эре терлек суеп, йоланы үткәрмәү гаеп саналган.

«Тутырмага терлек суйган кеше иптәше белән чакырыла иде. Бөтен туганнар, якыннар, күрше-тирә, укучы бабай чакырыла, парлап чакырыла иде. Кич белән җыела иде. Бу бәйрәм Коръән ашы кебек уздырыла иде.

Тутырма ясау өчен эчәкне юып чистартасың да (тутырма ясый торган эчәк аерым), шуңа тутырабыз. Аңа бавыр, ярма, суган, тәмләткечләр и терлекнең эч маен тапап тутырабыз, ярма белән суганны мясорубкадан чыгарабыз» (Миңгулова Кафия).

Татар Сарсазы авылы зур юл өстенә урнашкан, бу юлдан терлекләрне, казларны районга заготконторага куып алып бара торган булганнар. Зур юл үткән урамда яшәүчеләр капка астыннан сарыкларны, казларны тартып алып калырга тырышканнар. Капка төбенә чыгып урламаганлыктан, күрше-тирә авыллар бу авыл халкын «гадел халык» дип атап йөрткәннәр.

Алсу БАТТАЛОВА,
филология фәннәре кандидаты, доцент.

Әрәпә җыйнау үзе бәйрәм ул!

Иртә җәйнең иң матур көннәре. Урамда яшел үлән исе, җир исе. Бакчада төз түтәлләр; алма агачларын ап-ак итеп агартып куйганнар. Урам буйлап купшы итеп бизәлгән җигүле атлар, гармун тартып яшьләр килә. Сылу кызлар матур итеп милли киемнәр кигәннәр, ат арбасы тулы бала-чага... Истәлекләргә чумды дип уйлый күрмәгез, ел саен үзебезнең Балтач районы Арбор авылында үтә торган үзгә бер бәйрәм – Әрәпә җыйнау күренешен тасвирлавым. Бигрәк матур, җылы, самими бәйрәм инде ул.

Берничә көн алдан «Сабантуйга бүләк җыйнарга чыгабыз» дигән белдерү ясыйбыз. Билгеләнгән көнне Мәдәният йорты каршына җигүле атлар, балалар, бәйрәмчә киенгән кызлар җыйнала. Безнең авылның төп урамының озынлыгы якынча 3 километр (авылыбызда бүгенге көндә 640 кеше яши), әле тыкрыклар бар, шуңа без төш вакытында ук кузгалабыз. Алдан белдерү дә ясалгач, гармун, җыр тавышын ишетүгә, без килеп җитәрәк, һәркем бүләген күтәреп чыга. Әлбәттә, бүләкләрнең төрлесе буладыр (халыкта бит «Энә дә бүләк, дөя дә бүләк» дигән сүз дә бар әле). Иң мөһиме бу түгел. Беренчедән, һәркайсыбыз аңлый: Әрәпәдә бирелгән бүләкләр белән генә Сабантуй бәйрәме уздырып булмый. Күптәннән килә торган гадәт буенча, көрәшчеләргә, ярышларда катнашучыларга бүләкне бездә эшмәкәрләр, иганәчеләр бирә. Вак-төяк уеннарга Әрәпәдән килгәнне бирәләр. Инде нindидер борынгырак яулыклар, сөлгеләр, тукымалар була икән, аларын спектакльләр куйганда, сәхнә бизәлеше өчен дә кулланырга мөмкин. Безнең авыл халкы бүләкне мул бирә. Юмарт кешеләр яши бездә. Бүләктән тыш, әрәпәчеләрне берничә җирдә компотлар кайнатып, коймак, пәрәмәч, кош теле кебек милли ризыкларыбызны пешереп каршы алалар, арбада утырган балаларга капка төбе саен диярлек конфетлар тараталар.

Бик сирәк авылларда була торган үзенчәлектер: безнең авылда Балалар сабантуена дип аерып бүләкләр бирәләр. Әрәпә җыйган көнне кич белән болында Балалар сабантуе була. Яшь әниләр, әбиләр, балалар җыйналып, бик күңелле бәйрәм үткәрәбез. Монда килгән бер бала да бүләксез кайтмый.

Балалар элек-электән Сабантуйның яме булган бит инде. Безнең Арборда олылар Сабантуе иртәсендә дә балалар иртән-иртүк йорттан-йортка йөреп, кызартылган йомырка, кәнфит-прәннек җыйныйлар әле. Бер төркеме китә, икенчесе килә. Әнә шулай, аякларын үлән чыгында юешләтеп, җәйге иртәнең сихәтен тоеп, урам әйләнәләр алар. Йөгердем дә бүләк алдым гына түгел. Нәкъ менә шушындый чаралар аша балалар күңеленә гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз сеңә; гармун моңы, җырлар, такмаклар, шаян сүз, бәйрәмдәге мохит, үзара мөнәсәбәт милли тәрбиянең бик үтемле чарасы булып тора.

Рафилә ҺАДИЕВА,
Балтач районы Арбор авылы
Мәдәният йортының китапханәчесе

«Исәнме, түтәй, бирче бер күкәй!»

Безнең Каташ-Каран авылында элек-электән үткәрелеп килә торган «Әрәпә» дигән бик матур бәйрәм-йола бар. Ул 30 апрель көнне үткәрелә. Әлеге бәйрәм-йоланың нигезендә игенчелек белән бәйле халык ышанулары ята. Язгы сабанга чыгар алдыннан, игеннәр мул булып тишелсен дигән теләк белән, өйдән-өйгә йөреп чи йомырка җыйганнар, аны кырда пешереп ашаганнар, йомырканың бер өлешен исә кара җиргә тәгәрәткәннәр.

Өлкән буынның сөйләвенә караганда, элек бәйрәм бик зурлап уздырылган. Өлкәннәр бәйрәмгә алдан ук әзерләнеп торганнар. Йомыркалар туплаганнар, төрле-төрле күчтәнәчләр хәстәрләгәннәр.

Бу көнне бала-чага авыл буенча йөреп, ярма, сөт, май, йомырка җыйган. Алар капкадан такмаклап килеп кергәннәр:

– Әрәпә, Әрәпә, Әрәпә!!!

– Әрәпә, күкәй, сөт, ярма!!!

– Исәнме, түтәй, бирче бер күкәй!

Аннары хуҗабикәгә:

– Рәхмәт, түтәй!

Тавыгың салсын мең күкәй! – дип чыгып киткәннәр.

Җыелган ризыкларны болында, тауда, кайбер очракларда берәр өйдә, өлкән яшьтәге хатын-кыз җитәкчелегендә пешергәннәр. Сыйланырга бөтен авыл баласы җыелган. Һәркайсы коштабак-кашык алып килгән. Сыйлангач төрле уеннар уйнаганнар, күңел ачканнар.

Каташ-Каран авылының һәр буын кешесе бүген дә «Әрәпә» бәйрәмен шатланып көтеп ала. Бәйрәмне иртәнге якта кече яшьтәге балалар башлап җибәрәләр, төштән соң аңа мәктәп яшендәге балалар, кичке якта авыл яшьләре кушыла. Әрәпә җыю тәмамлангач, ягъни өйдән-өйгә кереп җыйган күчтәнәчләр белән (йомырка, кәнфит, печенье һ.б.) сумкалар тулгач, кечкенәләр төркемнәре белән алдан сөйләшенгән йортка кайталар. Хуҗабикә пешереп биргән йомыркалар белән тамак ялгагач, балалар бергәләшеп төрле-төрле уеннар уйныйлар, табышмаклар әйтешәләр, гомумән, күңел ачалар.

Авыл яшьләре Әрәпәне кичке якта җыялар. Араларында гармунчылар, баянчылар булганда бәйрәм тагы да күңеллерәк төсмер ала, җырлар-биюләр белән үрелеп бара. Көннең кайсы вакыты булуга карамастан, хуҗалар Әрәпә җыючыларны бик теләп каршылыйлар.

Әрәпә җыелып беткәч, яшьләр бергәләшеп болынга, Калатауга, яисә Каран башы чишмәсе буена киләләр. Анда учак ягып җибәрәләр, бер казанда йомырка пешә, икенчесендә ботка яки шулпа кайный, самавыр да үз җырын җырлап шаулап утыра. Шуннан китә уеннар: «Капкалы», «Күз кысышлы», «Сигезле», «Парлашу» һ.б. Әнә шулай таңны каршылап, яшьләр өйләренә таралалар.

Инде асыл эчтәлеген җуйса да, үзенең кабатланмас рухы, төсмере булган «Әрәпә», буыннан-буынга күчеп, әнә шулай, авылда күңелле ыгы-зыгы тудырып, көнкүрешебезнең яме-бизәге булып яши бирә.

Миләүшә СӨЛӘЙМАНОВА,
Сарман районының Каташ-Каран төп гомумбелем бирү мәктәбе директоры.

Фотолар Каташ-Каран Мәдәният йорты директоры Әлфия Рәшит кызы Гәрәевадан алынды.

Сабан туе

Фәнзилә ҖӘҮҺӘРЕВА

нинди туй?



Сабантуй. Бу – бары күңел ачу, бәйрәм итү генә түгел. Гыйбадәт, сәнгать һәм уен чыганагы бер: шатлык яисә кайгы изһар итү. Уен дигәне спорт, музыка һәм биюне дә эченә ала. Ат чабышы, көрәш, сабантуй бүләкләре-бәйгеләре өчен күркәкле тукымалар хәстәрләү, нәкышләнгән йомырка белән балаларны бүләкләү, курай моңнары – боларның барысы да тереклекнең рәхәтен изһар итә торган сәнгать системасы.

Бакый Урманче

Татар халкының милли бәйрәме Сабантуйның, билгесез заманнардан бирле күчмә һәм утрак тормыш мәдәниятләре синтезы буларак, тарихның сикәлтәле борылышларына карамастан, XXI гасырга кадәр килеп ирешкән күркәм йола бәйрәме икәне безгә яхшы мәгълүм. Сабантуй, башлыча, татар авылларында, бигрәк тә Казан артында, аграр тормышның аерылгысыз бер күренеше буларак, үзенә генә хас структур элементлары, ышанулар системасы белән XX гасырның 20-30 елларына кадәр үзгәрешсез үткәрелеп килгән. Төп структур элементлары буларак, беренче очракта без әлеге бәйрәмгә бәйле кайбер йолаларны күз алдына китерергә тиешбез. Шуларның иң үзенчәлеклесе – Сабантуй бәйгеләрендә катнашучыларга бүләк булдыру максатыннан сөлге/бирнә/яулык/кыйбый/әрәпә җыю йоласы. Әлеге йолага, билгеле бер төбәк урынчылыкларында, җирле йола гадәтләре дә өстәлеп үткәрелә килгән. Әйтик, Саба районының Кече Шыңар һәм Олы Шыңар

авылларында, бирнә җыю йоласы комплексында, Сабантуйга бер көн кала бирнә тәбәсе пешерү йоласы да үткәрелә. Шуны да искәртергә кирәк, Сабантуйга бүләк җыю йоласы татар милләтенең бар этник төркемнәренә дә хас күренеш түгел. Мәсәлән, Түбән Новгород һәм башка өлкәләрдә яшәүче мишәрләр өчен «сабантуй» төшенчәсе мәйданда үткәрелә торган бәйгеләр бәйрәмен аңлата. Себер татарларында (сүз җирле

халык турында) Сабантуй бәйрәме бөтенләй үткәрелмәгән. Моның сәбәпләре аларның этник чыгышларында, климатик шартларында, мәдәни традицияләрендә ята.

Инде Сабантуйның шәһәр мәдәнияте структурасына кагылышлы тарихына күз салыйк.

Мәгълүм булганча, Казанда Сабантуй XIX гасырның икенче яртысында гына үткәрелә башлый. Моның төп сәбәпләренең берсе – моңа кадәр авылларында натураль хуҗалык белән көн күргән крестьян катламының, татар буржуазиясе формалашу процессында актив катнашып, аякка шактый нык басып килгән сабын җитештерүче, күн эшкәртүче, тукыма тукучы татар фабрикантларына ялланып эшли башлавы. Нәтиҗәдә, әле генә шәһәр кешесенә әверелгән татарлар, шул исәптән зыялы катлам вәкилләре, фабрикантлар, үзара аралашу-күңел ачу, үз яклары батырын Сабантуйның иң абруйлы бәйгесе – көрәштә сынау, туган төбәк исемен татар дөньясына ишеттерү теләге белән Сабантуйлар оештыра башлыйлар. Чыгымнарны, әлбәттә, чорның татар эшмәкәрләре күтәрә. Моның белән махсус оештырылган Сабантуй идарәсе шөгыльләнә, идарә бәйрәмгә тотылган акчалар буенча җәмәгатьчелек алдында хисап тота. Нәкъ менә шушы вакытлардан моңа кадәр бары тик авыл бәйрәме буларак кына аңланган Сабантуйга җитди үзгәрешләр кертелә башлый. Төп үзгәрешләр: җир эшкәртүгә бәйле булган традицион ышанулар системасы төшеп кала, бирнә җыю йоласы туктала, Сабантуйда төрле төбәкләрдән үз традицияләре белән килеп, үзгә бер конгломерат булып оешкан татарлар катнашуына бәйле рәвештә, әлеге бәйрәм беркадәр тамашага йөз тота башлый. Моңа кадәр авылларда бәйрәмне читтән генә күзәтеп торган хатын-кызлар, бала-чага өчен дә алдан әзерлек, осталык таләп итми торган бәйгеләр (чиләк-көянтә белән су ташу, капчык киеп йөгерү, йомырка салынган кашык кабып йөгерү һ.б.) кертелә башлый.

Хәлле крестьяннар һәм шәһәр байлары үзләренең атларын ат чабышында катнаштырган. Әлбәттә инде, әлеге Сабантуйларда да төп урынны, һичшиксез, көрәш билгән. Көрәш карарга килүчеләрне мәйданга тәртип саклап сыйдыру, социаль статусларын исәпкә алып, тамашачыларга алдан ук урын әзерләү өчен, билетлар сату да оештырылган. Мәсәлән, Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә күренекле татар язучысы Ф. Әмирханның Казан Сабан туенда төшкән фотосурәте саклана. Әлеге фотода көрәш мәйданы утыргычларының номерланган булуы бик яхшы күренә. Бу чорларда Казан Сабан туе татарның иң яхшы көрәшчесен, бүгенге тел белән әйтсәк, абсолют батырын билгеләү чарасы буларак та аңланган. Мәсәлән, урысның күренекле көрәшчесе Иван Максимович Поддубный үзенең осталыгын империянең иң зур циркларында күрсәтә алса, татар көрәшчесе өчен иң зур арена Казан Сабан туе мәйданы булган. Ул вакытларда көрәштә бары тик ике генә җиңүче – батыр һәм батыр асты гына билгеләнгән. Кайбер вакытларда Казан Сабантуйлары өчәр көнгә кадәр сузылган. Мәсәлән, XX гасыр башында Казанда чыгып килгән «Йолдыз» газетасының 1910 елның 30 май, 1 июнь саннарында Бәрәзә авылыннан килгән Хафизулла Алачев исемле егетнең Казан Сабантуеның беренче көнендә үк 52 көрәшчене калак сөягенә салып, батыр калуы турында бик тәфсилләп сөйләнә («Түгәрәк уен», № 3, 2018). Хафизулла үзенә генә хас алымы белән, үзеннән әллә никадәр авыррак гәүдәле көрәшчеләрне дә җиңә алуы белән халыкны «аһ!» иттергән. Сабантуй көрәшен бүген профессиональ спорт төренә әверелгән көрәштән аерып торучы иң зур билге дә нәкъ менә шушы – батырның бар көндәшләрен җиңәргә тиешлек кагыйдәседер, мөгаен. Кызганыч, XXI гасыр Сабантуе көрәшен профессиональ спорт бәйгесе дип тә, чын Сабантуй көрәше дип тә атап булмый. Аны атау өчен татар акылы әлегә сүзен дә таба алмый ахры, бәлки табуны кирәк дип тә санамыйдыр. Моның сәбәпләре, бәлки, Сабантуй көрәшенең тамашачыны тартып торырлык рух һәм көч, дәрт, сәләт бәйгесе булудан әллә кайчан туктавындадыр...

Без югарыда XX гасырның 30 елларына очраклы рәвештә генә аерым басым ясамадык. Сабантуйга, халыкның дистәләгән гасырлар буена сакланып килгән гореф-гадәтләренә бик зур тәэсир нәкъ менә шушы елларда ясала. Аның объектив сәбәпләре бар. Сәбәпләр асылында илдә мәдәни үзгәртеп коруларның бик масштаблы баруы белән беррәттән, башка төрле фикер йөртү тыелуы да ята. Совет язучыларының 1934 елда уздырылган беренче съезды карарлары әлеге процессларның колачын киңәйтә генә. Шушы елларда халык иҗаты әсәрләренә беркадәр ревизияләр ясала, бер төркеме (мәсәлән, тарихи дастаннар, җырлар, кайбер бәетләр)

феодализм калдыклары дигән ярлык белән бөтенләй тыела (ул еллар тарихына кереп калган «Җидегәнчеләр» эшенең бер канаты да шушы идеология белән бәйле). Ә инде йола иҗаты халыкның рухын күтәрүче, аңын «үстерүче» идеологик корал буларак аңлана башлый. Сабантуй татарларга коммунистик рухны сеңдерү өчен иң кулай идеологик корал дип табыла, һәм аның эчтәлеге белән идарә итү вазыйфасы коммунистларның җирле партия оешмалары секретарьларына йөкләтелә. Шушы елларда акрынлап шәхси

милек, ягъни ата-бабадан килгән чәчүлек җирләре, печәнлек болыннары уртак милеккә – колхоз милкенә әверелә. Сабантуй, йола бәйрәме булуыннан туктап, башлыча, авыл батырларын билгеләү, авылдашларны очраштыру бәйрәменә әверелә. Элек Сабантуй көнен, җирнең орлык чәчүгә бәйле җитешүенә карап, авыл картлары билгеләсә, хәзер партоешма бюросы хәл итә башлый. XX гасырның икенче яртысында Коммунистлар партиясенең ТАССР өлкә комитеты идеология бүлеге «Сабантуйны ничек үткәрергә» дигән юнәлештәге күрсәтмәләрне берсе артыннан берсен бастырып, таратып кына тора. Шушы ук елларда Сабантуйларны үткәрү тәртибе беренче чиратта үткәрү көнен регламентлаштыруга юнәлтелә. Ул, кыр эшләре тулысы белән тәмамланып беткәч, июнь аеның соңгы җомгасы, шимбәсе, якшәмбесенә туры китерелә. «Сабан туе — хезмәт туе» дигән лозунг халык аңына актив сеңдерелә. Шушы ук елларда Сабантуйларга пролог өлешләре дә кертелә (ләкин әлегә алар хәзерге кебек театральләштерелгән хореографик композиция кыяфәтендә түгел әле). Аларда өстенлек механизаторларга, яхшы савымчыларга, җыйнап әйткәндә, авыл эшчәннәренә бирелә. Алар катнашында парадлар оештырыла, партия оешмасы кирәк дип тапкан лозунглар язылган плакатлар, транспарантлар Сабантуй мәйданнарын бизи башлый. Эчтәлек асылына җир кешесен – колхозчыны зурлау салына. Мәйдан башланганчы 40-50 минут тирәсе колхоз алдынгыларын котлаулар, аларга бүләкләр тапшыру оештырыла, партиянең халыкка хезмәте өлкәсендәге уңышлары җиткерелә. Көрәш батырының колхозчы гына түгел, алдынгы механизатор булуы тагы да мәслихәт күренә. Элек-электән килгән йола буенча Сабантуй батырына бирелә торган тәкә янына йорт җиһазлары, көнкүреш товарлары да куела башлый. Акрынлап тәкәнең абруе төшеп, ул түбәнрәк дәрәҗәле бүләккә әверелә бара. Кытлык товарлар – суыткыч, «Урал», «Иж-Юпитер» мотоцикллары кебек бүләк алу, әлбәттә, батыр өчен мәртәбә санала башлый.

XX гасырның 90-еллар башында, Совет иле таркалганнан соң, Сабантуй тагын да колачлырак үзгәрешләргә дучар ителә башлады. Иң аянычы: ул үзгәрешләр әле һаман да дәвам итә бирә.

XXI гасыр Сабантуе элекке рухын шактый киметеп, бик аз гына милли төсмерләр сибелгән тамаша – шоу программаларына кайтарып калдырыла килә. Иң аянычы шул, Татарстан территориясендәге татар авылларының 57% нда (2015 елгы саннар) Сабантуйлар инде үткәрелми. Сәбәпләре – авыл җирлеге идарәләрендә Сабантуйга тотарлык акча булмау, авылларның кечерәя баруы. Кайбер җирлек башлыклары әйтүенә караганда, алар җирлек бюджетыннан район Сабантуен үткәрү өчен күпмедер күләмдә акча китереп бирергә мәҗбүрләр. Нәтиҗәдә, Сабантуйлар авыл җирлегенең үзәк авылында гына үткәрелә башлады. Соңгы елларда исә, гомумән, 3-4 авыл җирлегенә бер Сабантуй үткәрү традициягә кереп бара, ә бу 14-15 авылга бер мәйдан дигән сүз. Гадәттә, Сабантуй үткәрелә торган авылда инвестор була, һәм предприятие бюджетыннан җыйналган бүләк тә шушы авыл халкына китә. Әлбәттә, 15-20 чакрым тирәсе ераклыкта урнашкан авыл кешесе үзенә чит-ят авыл Сабантуена барырга атлыгып тормый.

Бүгенге көндәге тагын бер четерекле мәсьәлә – Сабантуйларны үткәрү вакыты. Совет илендә XX гасырның 60 нчы еллары башында Сабантуйларны Татарстанның барлык территорияләрендә билгеләнгән бер вакытта үткәрү гадәте кертелгән булса, ул әле дә дәвам иттерелә. Элек Өлкә партоешмасы бюросыннан килгән Указ хәзер Президент тарафыннан бирелә. Беренче карашка каршылык юк кебек. Ләкин бу бары тик беренче карашка гына. Мәгълүм булганча, Татарстанның шактый күп авылларында, шул авыллардан чыккан эшмәкәрләр, кайбер очракларда авыл фермерлары, халык күңелен күрү өчен, савап яисә беркадәр зәкят тә булсын дип, үзләре теләгән вакытта Сабантуйлар үткәрәләр. Ул Сабантуйлар, Указны бозмас өчен, әллә нинди исемнәр астында (Авылдашлар очрашуы, балалар Сабантуе, Җыен һ.б.) уздырыла. Оештыручылары да авыл халкы үзе, бирнәсен дә бергәләп җыялар. Бәйрәм асылы белән чын авыл Сабантуена туры килә, ләкин бит аның исеме башка.... Бу проблемадан чыгу юлы, әлбәттә, Сабантуйларны Указсыз гына үткәрү түгел. Указ да булсын. Указ нигезендә мәйданына 5әр меңнән артык халык җыя торган зур Сабантуйларга беркадәр тәртип кертеп һәм оештыру кагыйдәләрен, таләпләрен үтәп була. Мондый зур Сабантуйлар – муниципаль районнарның үзәк мәйданнарында үткәрелә торган бәйрәмнәрдән. Шунлыктан Указ кысаларында район үзәкләре Сабантуйларын гына регламентлаштырып, авыл Сабантуйларын 131нче федераль законга туры китереп, районнарның җирле башкарма комитетларының үзләренә хәл итәргә тапшырсак, әллә ни каршылыкка кермәбез кебек. Әлбәттә, Сабантуйларны үткәрү көннәрен авыл җирлекләре алдан ук бер графикка кертергә тиештер анысы. Мондый Сабантуйларны үткәрүнең бар тәртипләре районнарның җирле норматив актлары кысаларында хәл ителә алыр иде.

Муниципаль районнарның үзәк Сабантуйларына кагылышлы тагын берничә борчулы мәсьәлә бар. Шуларның берсе – әлеге Сабантуйларда татар теленең кулланылыш дәрәҗәсе. Мәсәлән, Питрәч муниципаль районы Сабантуе мәйданының төп капкасына кергәндә, бәйрәм белән котлау сүзләреннән гайре, татар телендә башка гыйбарә күренми диярлек. Төп трибуна каршындагы лозунглар да бары тик рус телендә. Сәгать ярымга сузылган ачу тантанасы да башлыча рус телендә алып барыла. Пролог өлешенең дә 20-30 проценты гына татар телендә. Ярыш-бәйгеләр рус телендә бара. Ул гына да түгел, район халкын Сабантуй белән котлап килгән дәрәҗәле кунак та (2018 елгы Питрәч Сабантуена Дәүләт Советы депутаты Сәрия Сабурская килгән иде) тәбрикләү текстын рус телендә язылган кәгазьдән укып чыкты. Фонограмма астында чыгыш ясаган татар эстрадасы артистлары да халыкка мөрәҗәгатьләрен рус телендә җиткерде. Әлбәттә, бу бик аяныч хәл. Без, Сабантуйларны дөньяның әллә кайсы дәүләтләрендә, Рәсәйнең ничә дистә регионнарында татар халкын таныту, телебезне саклау максатларыннан чыгып үткәреп килгән вакытта, Татарстанның үзендә аңлаешсыз күңел ачуга, теге яисә бу артистның чыгышын бушка карап кайтуга корылган чаралар үткәреп азапланабыз. Сабантуйның асылын тәшкил иткән бәйгеләр – капчык сугыш, колгага үрмәләү, гер күтәрү, тауга йөгерү, чиләк-көянтә белән чабулар, капчык киеп йөгерүләр дә хәзерге район Сабантуйларында инде оештырылмыйлар дияргә була. Алар урынына чирәмдә чаңгы ярышлары, кумәкләшеп «чирәм хоккее»нда катнашу, ярымшәрә ирләрнең тайгак булсын өчен май сыланган ясалма тауга үрмәләве, берәр метрлы кеды яки ластылар киеп чабу ише кәмитләр тәкъдим ителә. Әлеге бәйгеләрдә, башлыча, бераз кызмача ир-атлар, ханымнар катнаша. Әүзебез «Сабантуй мәйданнары эчемлексез территория» дип сөйли торабыз...

Балалар мәйданчыкларының аерым оештырылмавы, балалар бәйгеләрендә куркынычсызлык кагыйдәләренең саклануын тәэмин иткән урыннарның бик аз булуы да Сабантуйларның бүгенге көн таләпләренә туры китерелеп бетмәвен күрсәтеп тора. Оештыручыларның җавабы бер: «Балалар өчен батутлар, кабартылган таулар бар, ата-аналары шунда алып барсыннар»... Бу инде бәйрәмнең исеме белән җисеме бер-берсеннән һаман ерагая баруының тагын бер дәлиле.

Татарстанда уздырыла торган район Сабантуйларында елдан-ел «мөгезләр чыгару» да бәйрәмнең милли йөзен бозуга шактый зур этәргеч булды. Хәзер район башлыгы, аның командасы үз алдына милли горефне саклау максатын түгел, «безнең Сабантуйның башкаларныкыннан аерылып торучы «фишкасы» булырга тиеш» дигән максат куя. Нәти-

җәдә, Сабантуйга килүче халыкны чегәннәр җыр театры, татар калфагы, түбәтәе кигән негроид расалы халык вәкилләре, пионер галстуклары таккан кыска итәкле яшь кызлар, тагын әллә нинди галәмәтләр каршы ала. Ни аяныч, хөкүмәт вәкилләрен, Дәүләт Советы депутатларын да шушылай ук каршылыйлар, аларның моңа бер генә дә исләре китми...

Сабантуйларның абруе кимүенә, чыгымнарының чиксез арта баруына китерә торган тагын бер күренеш – район башлыгы чакырып китергән махсус кунакларны кабул итү (зурлап табын артында кунак итү, киткәндә бүләкләр бирү). Әлеге материалны әзерләгәндә, Казан тирәсенә урнашкан берничә район хакимияте администрациясендә эшләүчеләр (әлеге табыннарны әзерләүче хезмәткәрләр) белән аралаштык. Баксаң, Сабантуй башланыр алдыннан әзерләнгән чәй табыны белән төшке аш табыннарының бәясе кеше башына бишәр меңнән дә ким чыкмый икән... Район башлыгының абруе, аралашу даирәсенә карап, кунак табыны 80 кешедән алып 400 кешегә кадәр җитәргә мөмкин, чөнки кунаклар парлап, еш кына гаиләләре белән чакырыла. Ул кунаклар Сабантуйның, кирәклеге аңлашылып бетмәгән парадлары, прологлары, бүләкләүләре каралып беткәч, дөресрәге, район башлыгы бушауга, табын артына кереп утыралар. Алар өчен биредә аерым мәҗлес бара. Кунакларга Сабантуй мөһим түгел, аларга район башлыгының күңелен күреп, әлеге чарада аңа кирәк сүзләрне җиткерү мәслихәт. Кунакларга бүләкләр дә мулдан әзерләнә. Якынча исәпләгәндә, стандарт бүләк пакеты шулай ук ким дигәндә 5 мең сумлык күчтәнәчләр белән тутырыла. Нәтиҗәдә, Сабантуйга дигән чыгымнар бермә-бер арта. Чакырылган кунаклар өчен Сабантуй район хакимияте башлыгы бәйрәменә әверелә, ә ул бәйрәмнең чыгымнары миллионнар белән исәпләнә.

Соңгы елларда «Сабантуйларның кызыгы бетте» дигән сүзне бик еш ишетергә туры килә. Чыннан да, район Сабантуйларына халык, башлыча, теге яисә бу эстрада артистының чыгышын тыңларга, бераз «әйләнеп керергә» дип кенә чыга. 2018 елда уздырылган Казан шәһәре Сабантуена, кеше аз булачагын алдан чамалап, шәһәрнең урта гомум белем бирү мәктәпләре укытучыларын (һәр мәктәптән 7 шәр укытучы), балалар бакчалары тәрбиячеләрен мәҗбүри разнарядка белән чыгардылар. Шушы уңайдан үзеннән-үзе «Мондый Сабантуй нигә кирәк?» дигән сорау туа. Бәлки Мирный бистәсендә үтә торган, берничә кат тимер киртәләр белән әйләндерелгән Сабантуйны, җыйнак кына итеп, туристларга, Казан кунакларына татар, рус, инглиз телләрендәге махсус программалар белән әзерләп үткәрергәдер?

Ни аяныч, Сабантуйның бизәге булган көрәш тә хәзер татар рухын күрсәтә торган бәйге түгел. Безнеңчә, төп сәбәп – Сабантуй көрәше белән спорт ярышын бер дип карау. Спорт төре буларак, татарча көрәшнең үз кагыйдәләре, үз тәртипләре бар. Әлеге кагыйдәләрне саклап, ярышларның гадел үтүен тәэмин итүче судьяларыбыз да бар, шөкер. Йола буенча, Сабантуй көрәшендә өченче урынга лаек көрәшчеләр билгеләнми, анда батыр һәм батыр асты гына тәгаенләнә. Сабантуйларда берәүгә дә бил бирмәгән батырны бәяләү – әлеге милли бәйрәмебезнең дәрәҗәсен, халыкның какшамас рухын чагылдыручы иң мөһим күрсәткеч ул. Бүген исә бездә ситуация шактый кытыршы. Әлеге кытыршылыкның бар картинасын 2018 елда Чебоксар шәһәрендә уздырылган Федераль Сабантуй көрәше батырына бүләк (автомобиль) бирүдә килеп чыккан гауга ачып салды. Бу турыда вакытлы матбугатта шактый саллы гына язмалар да күп булды. Сайтларда китерелгән материаллардан көрәшчеләрнең Татарстандагы район Сабантуйларын территорияләргә бүлеп, теге яисә бу күренекле көрәшченең, әлеге Сабантуйда катнашмавы бәрабәренә, яуланган машинадан процентларны кайтару гадәтләре турында да укырга мөмкин.

Эшләр алга таба да болай барса, Сабантуебыз киләчәктә үз йөзен тулысынча югалтып, бик зур чыгымнар белән үткәрелә торган шау-шулы тамашага гына кайтып калырга да мөмкин.

Фәнзилә ҖӘҮҺӘРЕВА,
филология фәннәре кандидаты, доцент

Р. Мөхәммәтҗанов фотолары.

Милләтне фән белән күтәрүче галим

Татар фән дөньясында энциклопедик гыйлемгә ия булган шәхесләр күп булмаган, хәтта, алар йөз елга бер генә туганнар дияргә дә була. Шундыйларның берсе XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән гаять киң эрудицияле галим Ризаэтдин Фәхретдин булса, хәзерге заманда исә, лаеклы рәвештә, күренекле археограф, әдәбият галиме, лингвист, фольклорчы, текстолог, тарихчы, этнограф, эпиграфист, педагог Марсель Әхмәтҗанов исемен атарга тиеш булабыздыр.

Гыйнвар аенда Р. Фәхретдиннең 160 еллыгын билгеләп үткән идек, шушы көннәрдә филология фәннәре докторы, профессор Марсель Ибраһим улы Әхмәтҗанов үзенең 80 яшьлек юбилеен каршылады. Әгәр дә фәнни эшчәнлекләрен тикшерсәк, бу ике шәхес арасында бик зур охшашлыклар күрербез...

М. Әхмәтҗанов 1939 елның 26 мартында Лениногорск районы Шөгер авылында дөньяга килә. Ерак бабалары исә Әтнә районы Олы Мәңгәр авылыннан булган. Галимнең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Марсель бине Ибраһим бине Әхмәтҗан бине Гайнетдин бине Галиәсгар бине Габдрәшит бине Мөслим бине Арслан бине Әбәк бине Җәбәк.

1943 елда Әхмәтҗановлар гаиләсе Арча районы Яңа Кенәр авылына күченеп килгәнлектән, яшьлеге шунда уза. Кечкенә Марсельны, җиде яше тулгач, ата-анасы Яңа Кенәрдәге урыс мәктәбенә бирә. Фәкать татарча гына фикерләргә өйрәнгән бала урысча укытуны кабул итә алмый, тора-бара ул бу мәктәптә укудан баш тарта. Икенче елга ата-анасы баланы татар мәктәбенә күчерергә мәҗбүр була. Нәтиҗәдә, малай мәктәптән фәкать «бишле» билгеләре генә алып кайта башлый. Ул үзенең яшьтәшләреннән белемгә омтылуы белән аерылып тора. Мәктәптә укыганда иптәшләре хәтта «профессор» дип үрти башлыйлар (әлбәттә, уйнап әйтелгән сүзнең киләчәктә чынга ашасын бу вакытта әле сыйныфташлары да, Марсель атлы малай үзе дә башына да китерә алмый).

1957 елда Яңа Кенәр мәктәбен тәмамлаганнан соң, тормыш йөген тарту өчен, унсигез яшьлек егет башкалабызның бер заводына гади эшче булып урнаша. Әмма белем алуга булган теләк үзенекен итә: 1963 елда ул Казан дәүләт университетының кичке бүлегенә укырга кереп, 1968 елда тарихчы белгечлеге алып чыга.

1972 елда М. Әхмәтҗанов Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага укырга керә һәм тел белеме буенча (җитәкчесе Фазыл Фәсиев) диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты исеменә лаек була. Диссертацияне ул Казахстанның Алма-Ата шәһәрендә яклый.

М. Әхмәтҗановның шәҗәрәләр буенча язылган фәнни эше («Исследование татарских шеджере в источниковедческом и лингвистическом аспектах: (по источникам XIX-XX вв.)») галимнәр тарафыннан бик югары бәяләнә.

Яшь галимнең максатчанлыгын, тырышлыгын, фәнни куәтен күреп, аңа Институтта эшкә калырга тәкъдим итәләр.

Марсель абыйның зур казанышларыннан берсе – татарның борынгы шәҗәрәләрен эзләп табып өйрәнү һәм фәнни әйләнешкә кертү. Галим совет идеологиясе шартларында кирәксезгә чыгарылган әлеге фәнни өлкәне яңадан яшәтеп җибәрә, шәҗәрәләрнең гаять кыйммәтле чыганаклар булуын дәлилләп бирә. Русиядә генә түгел, хәтта бөтен дөньяда да татар шәҗәрәләрен аның кадәр яхшы белгән, җентекләп өйрәнгән кеше юк, дип әйтергә мөмкин. Соңгы берничә дистә елда халыкта шәҗәрәләр төзү эше җанланган, нәселне өйрәнү теләге арткан икән, монда, һичшиксез, М. Әхмәтҗановның да өлеше зур. Шунысы сөендерә: 2013 елда галимгә 10 китаптан торган «Татар шәҗәрәләре» дигән хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе бирелде.

Галим бөтен гомерен татар әдәбиятын, тарихын, традицион мәдәниятен өйрәнүгә багышлаган. Эшчәнлеге дәверендә ул, бер-бер артлы фәнни экспедицияләрдә катнашып, археографик материал, ягъни борынгы кульязмалар һәм сирәк басма китаплар җыеп, Институт мирасханәсе хәзинәләрен баетып тора. Әнә шул археографик материаллар нигезендә, Марсель Әхмәтҗанов «Татар әдәби мирасын өйрәнү проблемалары: әдәби чыганакларны барлау, тикшерү методы нәтиҗәләре» дигән темага докторлык диссертациясен яклый. Әлеге хезмәтендә ул борынгы татар китабының тарихын ачып анализлый; фәнни әйләнешкә яңа чыганаклар кертә; борынгы татар әдипләре тарафыннан иҗат ителгән әсәрләрнең таралышын, яшәешен һәм система буларак чагылышын билгели; археографик материаллар системасының аерым әсәрләрнең язылу максатларын ачуга ачкыч икәнен дәлилли; татар шәҗәрәләре системасы борынгы әдипләрнең тормышын өйрәнүгә әһәмиятле чыганаклар икәнен исбатлый; татар кульязмалары битләрендә моңа кадәр мәгълүм булмаган яңа әдәби жанрларны ача; әдәбиятыбыз тарихында билгесез, яки аз билгеле булган шагыйрьләрнең мирасларын фәнни әйләнешкә кертә; йөзләгән кульязма текстларны хәзерге графикага күчереп, текстологик яктан эшләп чыга; борынгы язма чыганак текстларын тарих белән, башка тарихи чыганаклар белән тыгыз бәйләнештә өйрәнү методикасын эшли; яңа әдәби ядкарьләрне башка кардәш әдәбиятлардагы версияләре белән бәйләнештә һәм чагыштырып өйрәнү методикасын мисалларда күрсәтә. М. Әхмәтҗановның диссертациясе нигезендә язылган «Татар кульязма китабы» (2000) гуманитар өлкәдә эшләүче һәр галимнең диярлек өстәл китабына әверелде.

Татар әдәбиятының XVII – XIX гасырлар тарихы М. Әхмәтҗановка кадәр җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, бу озын тарихлы дәверне тулырак ачу өчен басылып чыккан әдәби ядкарьләрнең текстлары гына җитми иде. Шунлыктан галим, борынгы кульязма китапларның

Остазым белән
фәнни экспедициядә.

һәм документларның әдәбиятыбыз тарихын өйрәнү өчен кыйммәтле булуын аңлап, татар әдәбияты тарихын яңа фактлар, чыганаклар, әсәрләр белән баетты, тулыландырды. Мәсәлән, XVIII йөз татар әдәбиятына багышланган хрестоматияләрдә урын алган әсәрләрнең күбесе аның тарафыннан табылып, әзерләнеп, текстологик яктан эшләнеп укучыларга тәкъдим ителде.

М. Әхмәтҗанов борынгы халык авыз иҗаты ядкарьләрен халыкка кире кайтару өлкәсендә дә бик зур эш башкарган кеше. Аның «Каһарман Катил. Дастан», «Угызнамә» (1998), «Дастаннар ватаны» (1999) исемле китаплары зур популярлык казанды. Аларда фәндә әлегә билгеле булмаган әсәрләр текстологик эшләнелеп, гарәп графикасыннан кириллицага күчерелеп, киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде.

Галимнең меңләгән тираж белән 1991 елда басылып чыккан хезмәте – «Төш юрау китабы» да халык арасында зур популярлык казанды. «Татар халкының борынгы ырым-арбаулары һәм төрле фалнамәләре» (2012) дигән китап та галимнәр, шулай ук киң катлам укучы тарафыннан көтеп алынды. Әлеге китапка борынгы кульъязмалардан чүпләп алынып, текстологик эшләнелеп, гарәп графикасыннан кириллицага күчерелгән, мәхәббәттә уңышка ирешү, бозулардан, дошманнардан, чирләрдән саклану өчен укыла торган 130дан артык (алар XVIII-XX гасырларга карый) ырым текстлары кителгән. Моннан тыш, бу хезмәттә төш юрау тәгъбирләре, календарь фалнамәләр, табигать сынамышлары да урын алган. «Татар археографиясе. Татар халкының кульъязма тыйб хәзинәсе мирасы» (2016) хезмәтендә Марсель абый укучыларны үзе туплаган бай милли медицина мирасыбыз белән таныштырды. Моңарчы бу өлкә фәнни яктан бөтенләй өйрәнелмәгән иде. Галимнең фәнни экспедицияләрдә табылган археографик материалларының фәнни тасвирламаларын үз эченә алган унга якын китабы (ул аларны үз хисабына бастырып чыгарды) яшь галимнәр өчен менә дигән методик ярдәмлекләр булып тора.

Марсель абый татар эпиграфикасын өйрәнү өлкәсендә дә зур көч куйган. Узган гасырның 70 нче елларыннан башлап системалы рәвештә экспедицияләргә чыга галим. Һәм Татарстанның барлык районнарында диярлек, барлык чиктәш республикаларда, Санкт-Петербург, Оренбург, Чиләбе, Касыйм, Екатеринбург, Уфа, Троицк шәһәрләрендә халкыбызның ташъязма мирасын бөртекләп җыя. Нәтиҗәдә бер-бер артлы «Үлгәннәрнең каберен бел» (2000), «XVII-XVIII гасыр татар ташбилгеләре» (2011), «Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре» (2011), «Татар археографиясе. Татар эпиграфикасын өйрәнү дәверендә тупланган зират культурасы хакындагы кайбер материаллар» (2013), «Татарстандагы татар зиратлары ташбилгеләре язмалары» (2016) кебек бибәһа китаплары дөнья күрә. Галимнең татар мәдәниятенең борынгы традицияләрен өйрәнүгә багышланган бу хезмәтләрендә мәдәниятебезнең күп гасырлар буе тарихи үсеше киң географик мәйданнарда яшәгән халкыбызның милли үзенчәлекләренә басым ясап күрсәтелгән.

Зиратларда билгә кадәр үскән үләннәр, ташландык каберләр иңгәннән соң барлыкка килгән чокыр-чакырлар арасында борынгы кабер ташларын эзләп йөрү олы яшьтәге галим өчен генә түгел, яшьләр өчен дә бик кыен иканлеген һәр эпиграфист белә. Әлеге эшкә фәкать татар фәненә һәм халкына фидакарьләрчә бирелгән шәхесләр генә тотына ала.

М. Әхмәтҗанов татарның тарихын һәм этнографиясен өйрәнүдә зур хезмәт куйды. Ул, күпсанлы язма чыганаклар нигезендә, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Касыйм ханлыгы, Нугай урдасында яшәгән татарларның этник тарихын ачты, «Меңъеллык татар нәселе» (2000), «Нугай урдасы: татар халкының тарихи мирасы» (2002, 2009) китаплары белән тарих фәне үсешенә зур өлеш кертте, татар этногенезы тарихын дөрес юлга салды. Шулай ук галим игътибарын хәзерге Татарстандагы аерым төбәкләрне дә җентекләп өйрәнүгә юнәлткән, мәсәлән, «Олы Мәңгәр авылы тарихы» (2000), «Ахун авылының шәҗәрә китабы» (2006) һ.б.

Олуг галимебезнең бүгенге көндә иллегә якын китабы дөнья күргән, меңгә якын фәнни, фәнни-популяр һәм публицистик мәкаләләре басылып чыккан. Марсель Әхмәтҗанов – Г. Ибраһимов исемендәге ТӘҺСИ һәм КФУда диссертацияләр яклау Советы әгъзасы, Халыкара төрки академия академигы, Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, хезмәт ветераны. Галимебез бүген дә сафта – зур иҗтиһат белән фәнгә, милләткә хезмәт итә. Без аңа исәнлек-саулык, иминлек, яңа фәнни ачышлар теләп калабыз!

Айдар ГАЙНЕТДИНОВ,
филология фәннәре кандидаты.

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ

Татарлардагы кайбер күрәзә ысуллары

Адәм баласы, уйлый башлаганнан бирле, үзе белән тирә-як табигатьнең, галәмнең үзара бәйләнеше барлыгы турында гениаль фикергә килгән. Күпьеллык күзәтүләр, тәҗрибәләр нигезендә вакыйгалар, күренешләрнең бер-берсенә бәйле логик бәйләнеше барлыгын исбатлаган. Адәм баласының шушы аналитик фикерләү нәтиҗәсендә туган күпьеллык тәҗрибәләре нигезендә тупланган белемнәре катлаулы фаллар системасын тәшкил иткән.

Татар халкының да төрки телле ерак бабалары үзләре өчен төрле фал ачулар системалары иҗат иткәннәр. Аларның фал мирасы борынгы Азия һәм Якын Көнчыгыш цивилизацияләре казанышлары белән дә баеган, тулыланган.

Фал ачуларның ысуллары бездә күп төрле булган, аларга реалистик күз белән карaганда, без конкрет табигать һәм җәмгыять күренешләренә, аларның логик эзлекле әверелешләренә анализ нәтиҗәсендә туган информацияләрне күрербез.

Һәрбер авыруның башлангыч чорында төрле билгеләре булган кебек, табигатьтә, күк йөзендә күренгән, кеше тарафыннан гайре табигый саналган күренешләр дә (ай, кояш тотылулар, зилзиләләр, көчле яңгырлар, вакытсыз яшен, күк күкрәүләр) табигать закончалыклары нигезендә барлыкка киләләр һәм җирдә, кеше яшәгән табигый мохиткә тәэсир итәләр. Табигый үзгәрешләр билгеле биологик һәм иҗтимагый күренешләр белән дә тыгыз бәйләнгәннәр. Димәк, шуларның әверелешләренә нигезләнеп, фал ачуның рациональ нигезе барлыгы аңлашылса кирәк.

Татар телендә фал ачуны «багу», «күрәзәлек итү» диләр. Бу эш белән шөгыльләнүчеләрне багучы, күрәзәче дип атыйлар.

XX гасыр башында татар халкының бик бай, озын тарихлы фаллар системасы булган. Аларның бер өлеше – мәлхәмәләр, төш тәгъбирләре, йолдызнамәләр – кульязма һәм басма китаплар рәвешендә язуга беркетелгәннәр. Икенче берләре телләрдә йөргән. Телләрдә йөргәннәр арасында шул ук төш юраулар, һава торышы фаллары да булган. Моннан тыш һәрбер конкрет очракка фал ачу ысуллары һәм алар белән шөгыльләнүче кешеләр булган. Соңгы төркемгә «Коръән» ачу, көзгедән карау, карта салу, түшлек салу, шырпы салу, борчак салу, гәҗит яндырып карау, комалак салу ысулларын һәм елның аерым вакытларында сынап беленә торган көннәрне кертергә мөмкин. Әлбәттә, фал ачуларның бер төре кара ышануларга әйләнеп китә.

Татар халкының фал ачу ысулларын әлегә төпләп, система итеп карап өйрәнгән кеше юк. Бу өлкәдә Каюм Насыйри кебек галимнәрнең хезмәтләрендә аерым эпизодлар гына теркәлеп калган. Хәтта ки, татарда бүгенге көндә ничә төрле фал ачу системасы булганлыгын кистереп әйтү дә кыен.

Фал ачу, күрәзәлек, багу кебек эшләр борын-борыннан килә. Ләкин алар җәмгыятьтә килеп туган иҗтимагый кризислар вакытында тагын да җанланып китәләр. Чөнки кризислар вакытында шәхес аеруча дискриминацияләнә, изелә.

Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган бу хезмәт фәнни-археографик экспедицияләр вакытында күзәтелгән материалларга нигезләнеп язылды, һәм ул тулылыкка, камиллеккә дәгъва итми.

«Коръән» ачу

«Коръән» ярдәмендә фал ачу күренеше татарлар арасында элек еш очраган. Соңгы елларда безгә бу эш белән шөгыльләнгән бер генә кешене очратырга туры килде. Ул – Казан шәһәрендә яшәүче Әминә апа Ильясова. Күрәзәче, ният кылып, «Коръән» китабын ача һәм андагы сүрәне, гарәпчә мәгънәсен аңлап, куелган сәальгә туры китереп, татарча шәрехләп чыга. Мондый ысул белән «Кыйсса-и Йосыф» һ.б. китаплар ярдәмендә дә фал ачу бар.

Көзгедән карау

Фалның бу төре Бөек Ватан сугышы елларында һәм аннан соңгы дәвердә киң таралыш алды. Көзгедән карау белән Әтнә

районының Яңа Кенәр авылында Сабира апа Мөхәммәдша кызы шөгыльләнде. Ул апа 1960-еллар тирәсендә үк вафат булды. Кызганычка, аның фал ачу ысулы тәфсилләп язып калынмаган. Ләкин беркадәр сүзләре хәтердә саклаңган. Атнаның кайсыдыр көнендә, төн уртасында, ул, сүрәләр укып, ут яндырып, чормада урнаштырылган көзгесе янына менә. Көзге янында лампасын куеп, аңа карый башлый. Аның сүзләренә караганда, көзгедә язмышы кызыксындырган кешегә бәйле галәмәтләр күренә торган булган.

Авылда кемнеңдер хәбәрсез югалган вакытында, хатыны үтенгәч, Сабира апа көзгегә карый һәм чокырга ике яктан балчык ишелгәнен күрә. Күрәзәче моны югалган кешенең үлеменә юрый.

Карта салу

Фалның бу төре күптәннән килә, бүген дә карта салып фал ачучы, багучы кешеләр бар әле. Ләкин аларның багу принциплары язып алынмаган.

Төшлек салу

Кешенең күңелен борчыган мәсьәләне, аеруча, кеше язмышларын ачыклау өчен «төшлек салу» гадәте әлегәчә саклаңган.

Элегрәк укымышлырак төш юраучылар була иде, хәзер алар бармы-юкмы – әйтеп булмый. Төш юраучы кеше, куелган сәальгә багышлап, мендәр астына төш юрау китабын салып йоклый, күргән төшен куелган сорауга карата юрый.

Гәҗит яндырып багу

Сугыш вакытында аталарыннан, улларыннан, агаларыннан, балаларыннан хәбәр көткән кешеләр гәҗит яндырып багып, күңелләренә юаныч табалар иде. Гәҗит төнге сәгать 12 дә ак мич фонында яндырыла. Ялкыннан мич стенасына төшкән күләгәләргә карап, якыннарының «хәлләрен беләләр» иде.

Шырпы белән багу

Бу багуның максаты бары «әйе» яки «юк» дигән җаваплар алу өчен генә.

Багу өчен санап тормыйча берничә шырпы алына һәм алар түбәндәге рәвештә куела башлый: «әйе», «юк», «әйе», «юк»...

Әгәр шырпылар «әйе» белән бетсә, уңай җавап, «юк» дигән белән бетсә, тискәре җавап була.

Шырпы белән багу ысулы 1994 елда Яңа Кенәр авылында Ф. Каюмовадан (1912 ел туган) язып алынды.

Моннан тыш, халык арасында кара ышануларга (Казан арты ышанулары) нигезләнгән фаллар бар. Мәсәлән, тавык әтәч булып кычкырса, хуҗага зыян була. Моннан соң ул тавык буе белән сәке тактасын үлчиләр, әгәр сәке башына тавыкның башы чыкса, тавыкны суялар.

Базарда ат сатканда, атны йөгән сабын кием итәге белән тоткан хәлдә сатып алучыга тапшыралар, югыйсә, сатучыда ат малы тормавы мөмкин, кул арты китә, дип ышаналар.

Атка икмәкне пычак белән кисеп ашатырга ярамый, сындырып, кисәкләп ашатырга кирәк, югыйсә, ат киселеп бетәр, дип ышаналар һ.б.





Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,
филология фәннәре докторы, профессор.

Фәрит ЮСУПОВ

Төш күрү. Төш юрау



2019 елның 15 февралендә Совет гаскәрләренең, ун ел дәвам иткән мәһшәрдән соң, Әфганстаннан чыгуына утыз ел тулды.

Кеше – Аллаһы Тәгаләнең иң сөеп яратканнарының берсе. Ул кешене бер генә җан иясенә дә насыйп булмаган могҗизалар белән бүләкләгән. Шундый могҗизаларның берсе – төш күрү – күпчелек очракта аерым шәхесләргә генә махсус аталган нинди дә булса бик мөһим информацияне иясенә җиткерү ысулы. Ләкин Аллаһы Тәгалә аны ни рәвешле тормышка ашыру юлларын бүгенгә кадәр сер итеп калдырган. Тиешле вакытысәгате килеп җитми торып, кеше төш күрү, төш юрау серләрен ача алмаячак. Аллаһы Тәгалә хәтта, бу могҗизаны катлауландыру өчен, кайбер кешеләргә фәлсәфи һәм гадәти төшләрне бер-берләреннән аеру сәләтен дә биргән. Фәлсәфи төшләр кешене, төрле катлаулы символлар аша, булачак мөһим вакыйгаларга әзерли. Мондый төшләрне бик гади генә итеп юрап булмый. Моның өчен инсани затка Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән иксез-чиксез вакыйгалар арасыннан бу очракны аңларга ярдәм итә торган символларның серен чишү сәләтенә ия булырга кирәк. Шуңа булса кирәк, хәдисләрдә төш юраучыларны пәйгамбәрлек сыйфатларына ия булган затлар итеп бәялиләр. Гади төшләрдә исә кешенең көндәлек тормышындагы мәшәкатьләре кешенең зиһен эшчәнлеге йокы халәтендә булганда да дәвам итә. Төш юраучылар мондый төшләргә аеруча игътибар итмиләр, төшкә ни кермәс дип кенә куялар. Гадәттә кеше бу төшләрне башка исенә дә алмый, ул аның хәтеренә кире әйләнеп кайтмый. Фәлсәфәле төшләр үзләренең серләрен шунда ук ачмаска да мөмкиннәр. Алар кешенең гомере буенча, вакыт-вакыт исләренә төшеп, бик озак еллар сер булып кала бирәләр.

Төш күрү – бөтен халыклар өчен уртак күренеш. Ләкин төшләрне дөрес итеп юрау сирәк халыклар өчен, аерым алганда, бик тирән рухи мәдәнияткә ия булганнары өчен генә хас. Шундыйлардан мин, беренче чиратта, төрки халыкларны атар идем. Татарлар алар арасында аерым урынны алып тора.

Бик борынгы заманнардан бирле татарларда төш юрау традициясе яшәп килгән. Без, бала вакытларыбызда, йокыдан уяну белән, күргән төшләребез белән уртаклаша идек. Төрки дөньяга багышланган фәнни эшчәнлегем барышында мин бу гадәтнең борынгы төркиләрдән үк килгән яшәү рәвеше булганын аңладым. Дастан каһарманнары да, йокыдан уянгач, иң беренче итеп, күргән төшләре белән уртаклаша торган булганнар. Төшләрне махсус рәвештә күрү, аларның мәгънәләрен юрау себер татарлары арасында бүгенге көнгә кадәр аеруча киң таралган. Шушы көннәргә кадәр аларда сакланып калган «Кузы Көрпәч белән Баян Сылу» дастаныннан кыска гына бер өзек китереп китәсем килә. Кузы Көрпәч үзенең ярәшкән ярын – Баян Сылуны эзләп, бик ерак юлларга чыгып китәргә җыена. Ул вакыттагы кешеләр, нинди дә булса бер мөһим эшкә тотынганчы, махсус төш күреп ала торган булганнар. Шушы төшне күрми торып, зур эшләргә тотынмаганнар. Зур сәфәргә чыгып китәргә дип җыенган улына әнисе: «Улым, китми тор, мин төш күреп алыйм», – дип әйтә. Һәм ятып, аз гына черем итеп, төш күреп ала.

Әнисе улына мөрәҗәгать итә:
– Бүген яман төш күрдем, балам,
Өйнең артында байтирәк күрдем, балам,
Өй өстенә йыгылдым, балам.
Ишекнең алдында сары йылан,
Юлыңа сузылып ята гуй, балам.
Кузы Көрпәч әнисенә әйтә:
– Бүген яман төш күрдем, әни,
Өйнең өстендә утыз бүре, әни,
Утыз көтү бугай алар, әни.
Кырның кырык бүресе, әни,
Алар кырык көтү кебек, әни.

Хәзерге вакытта, татарларда гына түгел, башка халыкларда да төш салу, төш күрү, төш юрау традициясе бетеп бара. Шулай булуга карамастан, хикмәтле төшләрнең серенә төшенү теләге кешеләргә беркайчан да тынгы бирмәячәк.

Беренче төш.

Абзарда бозауны бәйле тоталар

1990 елның май башлары. Советлар Берлегенең дәүләт буларак яшәвенә санаулы көннәр генә калган заман. Бер гасырга якын ябулы торган тимер капкалар да ачылам-ябылам дип торган көннәр. Төрек дөньясын өйрәнү вакыфы рәисе, данлыклы Туран Язган Казанда булганда, Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтын зиярәт итеп, мине, эшлекле сөйләшүләрне дәвам итәргә дип, үзләренә чакырып киткән иде. Советлар дәүләте тимер капкаларны болай гына ачып була торган итеп төземәгән икән. Чит илләргә чыгу өчен таләп ителгән рәсми чакырулар алдау өчен уйлап чыгарылган гамәл булып чыкты. Иң мөһиме, үзебезнең Чит илләр министрлыгыннан рөхсәт визасы кирәк икән. Бу визаны алыр өчен синең кулыңда билет булу мөһим. Билеты булмаганнар белән сөйләшеп тә тормыйлар. (Шунысы гыйбрәтле: мондый башваткыч бары тик безнең ил өчен генә хас булган.)

Берничә айга сузылган «Кәҗә белән кәбестә» әкияте минем файдага тәмамланды. Минем өчен таныш булмаган бер кеше Мәскәүдән шалтыратты: «Сезгә Төркиягә чыгарга виза бирелде, ләкин ул кыска вакытлы. Сез бер көн эчендә илдән чыгып китәргә тиешсез». Мин Мәскәүдәге дусларыма шалтыраттым. Сөйләп бетергесез маҗаралар кичеп, самолет китәргә дүрт сәгать калганда, мин Шереметьево һава аланында басып тора идем инде.

Казаннан Мәскәүгә китәргә санаулы минутлар гына калганда, үзем эшләгән Милли мәктәпләр институтына кереп чыгарга туры килде. Кабул итү бүлмәсендә авылча итеп киенгән, берсе өлкән яшьтәге, икенчесе аннан шактый яшь ике хатын-кыз басып тора иде. Минем кем икәнемне аңлагач, алар, бер-берсен бүлә-бүлә, үзләренең гозерләрен аңлата башладылар. Олырак яшьтәге апаның улы Әфганстанда ике ел хезмәт иткән икән. Илгә исән-сау кайтасы көннәрне минутлары белән санаган көннәрнең берсендә егет әфганлылар белән бәрелештә юкка чыккан. Малайдан хат килмәгәненә, хәрби комиссариаттан бернинди хәбәр булмаганына елга якын вакыт узган. Әле моннан ике-өч ай элек егетнең дәү әтисе төш күргән: боларның яз башында гына туган бозаулары югалган, имеш. Аны эзләп-эзләп тә таба алмаганнар. Шушы бозауны эзләп кайтып килгәндә, дәү әтисе бер сарайга юлыккан. Сарайда беркем дә юк икән. Бозау, бик тә нәүмиз кыяфәттә, бауга бәйләнгән килеш басып тора, ди. Бабай шул минутта уянып китә. Дәү әнисенә: «Мин малайны таптым, ул әсирдә», – дигән. Шул ук минутта өйдәге бөтен кеше йокыларыннан сикереп торган. Якын туганнары, күрше-күләннәре җыелганнар. Бабай тиз ге-

нә районындагы хәрби комиссариатка йөгергән. Андагылар бабайны көлеп кенә каршы алганнар: «Әй, бабай-бабай! Әгәр дә һәр кеше һәр күргән төшен сөйләр өчен безгә килсә, без шуларны юрап кына утырыр идек. Оныгың турында бер генә хәбәр дә килгәне булмады әлегә», – дигәннәр. Дәү әтисе, нәрсә эшләргә дә белмичә, өйләренә кайтып киткән.

Ике-өч атнадан соң дәү әтисе тагын төш күргән. Малайны әсирдән азат иткәннәр. Бозаулары башка терлекләр белән далада йөри. Ләкин аларга бик якын килми, кырый-кырыйда гына чемченеп йөри икән.

Аптырагач, егетнең әнисе белән дәү әнисе Казанга юл тотканнар, татар газеталарында, радиокомитетта, тагын әллә кайларда-әллә кайларда булганнар... Әлбәттә, алар да нәрсә әйтсеннәр. Кемдер аларга безнең Институтның адресын биргән, барып карагыз әле, дигән. Бу хәл мине бөтенләй аптыраушта калдырды. Мин дә шул бер сүзне сөйләргә мәҗбүр булдым. Шулай да, аларны аз гына булса да юатыйм дип, «сез мөрәҗәгать иткән кешеләр ярдәм итә алмаса, Аллаһы Тәгалә бар бит. Ул сезне ярдәменнән ташламас», дидем. Аларга бернинди дә ярдәм итә алмавыма бик борчылдым.

Төркиягә чакырылуымның максаты – дөньядагы төрки телле мәктәпләр өчен уртак уку планнарын төзүдә катнашу. Элеккеге Советлар Берлегеннән, шулай ук Ирак, Сирия, Иран дәүләтләреннән килгән белгечләр белән, иртәдән кичкә кадәр, барлык төрки халыклар өчен үрнәк була алырлык уку планын төзибез. Бик тә киеренке эш белән ун көн вакыт үткәне сизелми дә калды. Өйлә ашы вакытында Туран Язган, бик серле генә итеп, икебезнең бер җыелышка китәчәгебезне хәбәр итте. Кая баруыбыз да сер булып калды. «Баргач күрерсең» дигән җавабы белән чикләнде. Вакыф каршында торган үтә дә «текә» машинасының руленә дә үзе генә утырды. Аның машина йөртүе бик сирәк очракларда гына була торган иде.

Без 30-40 минуттан соң Стамбулның үзәк мәхәлләләренең берсендә урнашкан бик тә зиннәтле Мәдәният йорты каршысына килеп туктадык. Керү ишекләре янында полицейскийлар белән сәеррәк милли киемнәр кигән кешеләр керүчеләрнең кемлекләрен (документларын) тикшереп торалар. Туран Язган белән икебезне дә бик тә дәрәҗәле кешеләр янындагы беренче рәткә утырттылар. Залдагы кешеләрнең үзара, төрек теленнән тыш, мин моңарчы ишетмәгән телдә сөйләшүләренә игътибар иттем. Төрек һәм татар сүзләрендә [а] авазын [о] белән алмаштыруларыннан боларның фарсы телендә яки аңа охшаш телдә сөйләшүләрен аңлап алдым.

Биредә Әфганстаннан күчеп килгән җәмәгать, сугыш тәмамланганнан соң, киләчәк яшәешләрен ничек итеп җайга салу турында фикер алышалар иде. Тупланты шактый дәвам итте. Аңлавымча, монда катнашучылар да бер-берләрен кабатлаган фикерләрдән арганнар, туйганнар иде. Менә бер заман туплантыны алып баручы рәис, урыныннан торып, трибуна артына килеп басты, үз телендә нәрсәдер сөйләде, сүз азагында минем исемне, фамилияне нәкъ татар телендәгечә, шул кадәр саф итеп әйтте, көтмәгәннән йөрәгемне без белән кадаган кебек булды. Чыгыш ясаучыларның юк-бар сүзләренә дә аяк тибеп, кул чабып утырган зал тирән тынлыкка чумды. Чебен очса, аның безелдәве бөтен залга ишетелер иде. Мин бөтенләй югалып калдым, Туран хоҗа мине кулымнан тотып аякка бастырды. Башымнан яшен тизлеге белән «бу бит чып-чынлап оештырылган провокация» дигән уй үтте. Минем аптырап калган хәлемне аңлаган Туран хоҗа: «Хәзер инде нәрсә сөйләсәң дә ярый», – дип кенә әйтергә өлгерде. Гомеремнең иң күп өлешен студентларга лекция сөйләп уздырсам да, нәрсә турында сөйләячәгемне көрсигә барып җиткәнче тәгаен генә башыма китерә алмадым. Мин, залдагы халыкка төрек телендә мөрәҗәгать итеп: «Сез минем – бер шурави (совет) профессорының – үзегезнең каршыгызда басып торуына шаклар каткан кебек, үзем дә шушы секундларда сезнең арагызда булуыма ышана алмыйм, – дидем. – Сез илегезнең, халкыгызның киләчәк тормышын тыныч шартларда ничек итеп җайга салу турында киңәшергә җыелгансыз. Безнең халык та шул ук гамь белән яши. Ун ел дәвам иткән канкойгыч сугышларда никадәр асыл егетләребезнең гомерләре киселде, никадәр егет гарип калды, никадәр әниләр, әтиләр, дәү әтиләр, дәү әниләр, кара кайгыга түзә алмыйча, вакытыннан алда фани дөнья белән хушлаштылар...» Мин Төркиягә китәр алдыннан очрашкан ике татар хатыны, алар кебек меңнәрчә ата-аналар, ятим балалар турында сөйләдем. Кайда соң ул мин әле генә сөйләгән асыл егетләребезнең берсе? Аның кабере билгесез булып калырмы? Әти-әнисенә, дәү әти-дәү әнисенә кемнәр нинди хәбәр китерер?

Миңа бу вакыйганы сөйләү гаять дәрәҗәдә авыр булды, тавышым карлыкты, күзләремнән

яшьләр акты. Бу фаҗига «шуравиның» дошманнарының да күңелен йомшартты. Зал тиз генә таралырга теләмәде. Мине әфган журналистлары чолгап алды. Аларның татар егетенең тормышын нечкәләп беләселәре килде. Бу егетләр татар дастаннарында сөйләнә торган каһарманнарга охшап торалар иде. Аларның зифа гәүдәләре, зәвык белән сайланган киемнәре, үз-үзләрен тотышлары миндә соклану уятты. Ләкин араларыбызда уннарча еллар алып барылган дошманлык салкыны әллә кайлардан ике якны да суытып тора иде. Бу аңлашыла да, төрек булсалар да, алар Әфганстанда туып-үсеп, аяусыз сугышның ачысын-төчесен татыган, кулларына кайнар корал тотып сугышкан «дошман» егетләре иде ич. Минем тарафтан булган җылы мөнәсәбәт аларны да җебетеп җибәрде. Алар, бер-берсен уздырып, «әгәр ул егет тере булса, без аны, һичшиксез, табачакбыз», диделәр. «Ничек? – дидем мин. – Ни өчен табачагыгызны шулкадәр ышанып сөйлисез?» «Без аның юлларын беләбез, – диделәр. – Шикләнмәгез, без моның чынчынлап шулай булачагына ышанып әйтәбез». «Их, егетләрем, минем Төркиядә бары тик бер атна вакытым калды. Тагын кайчан киләчәгем билгеле түгел», – дип офтандым. Егетләр минем отельнең исемен, бүлмә санын язып алып, шул ук мәлдә күздән дә югалдылар.

...Калган алты көнем алты сәгать кебек узып китте. Әфган журналистларыннан һичбер хәбәр булмады. Мин иртән үк тутырган чемоданымны ишек төбенә үк китереп куйдым. Әнә мине һава аланына алырга килгән машинаның кычкырткан тавышлары да ишетелде. Мин, авыр сулап, ишекне ачтым, чемоданымны коридорга чыгардым. Шул вакыт мәрмәр баскычлар буйлап йөгергән тавышлар ишеттем. Мондый затлы кунакханәдә торучы бер генә кеше дә баскычлардан йөгереп йөрмәс. Егетләрнең аяк тавышы бит бу! Шул мәлдә алдыма тиргә баткан, үтә дә сөйкемле, җылы күңелләре белән бозларны да эретә алырлык асыл егетләр килеп басты.

Минем белән очрашудан соң, егетләр үзләренең Стамбулдагы редакцияләренә йөгергәннәр. Әфганстанда тапшыруларын төрек, пуштун телләрендә алып бара торган радиостанцияләр белән бәйләнешкә кергәннәр. Һәр программа азагында әлеге вакыйганы сугыш китергән бер фаҗига итеп аңлатканнар. Дүртенче көннең азагында гына Кандагардагы бүлекчәләренә бер карт пуштун килеп кергән. «Беләм мин ул егетне», – дигән. Егетләр шул ук көнне Стамбулдан Кабулга, аннан Кандагарга очканнар. Пуштун бабай аларны пөхтә генә бер йортка алып барган. Башта йортка үзе генә кергән. Бераздан егетләрне дә өйгә чакырганнар. Ләкин өстәл артында олылар гына булган. Аксакаллар озак кына тәмләп чәй эчкәннән соң, ишек алдына һава суларга дип чыкканнар. Егетләр, төнге караңгылыкта, ишек алдында үскән агачка сөялеп торган бер яшь ирне абайлап алганнар. Аның янына килеп, көнчыгыш халыкларының гадәте буенча кочаклашып күрешкәннәр. «Без аны кочагыбызга алганда, аның һәр күзәнәге тетрәнеп тора иде, – дип сөйләделәр егетләр. – Без аңа сез сөйләгән вакыйгаларны баштанаяк сөйләп бирдек. «Мин беләм, мин дә ул тапшыруларның һәрберсен тыңлап бардым, – диде ул безгә. – Ахырдан, акылдан яздым бугай, дип уйладым. Өйдәгеләргә радионы чыгарып ташларга куштым. Минем язмышымнан әнәсеннән җебенә кадәр хәбәрдар булган кышлак халкы да бу хәбәрне тетрәнеп кабул итте». Егетнең үзләрендә яшәвен беркемгә дә әйтмәскә дип, кышлак халкы бер-беренә сүз биргән».

Егетнең журналистларга сөйләвенә караганда, каты сугышлар вакытында, ул, яраланып, әсир төшкән. Аны елдан артык зинданда тотканнар. Тыныч холыклы, ярдәмчел булуын исәпкә алып, шартлы рәвештә иреккә чыгарганнар. Егетнең кулы дөрестән дә алтын булган: төзәтеп булмаслык өй кирәк-яракларын, электр приборларын, металлдан ясалган аш-су әзерләү җиһазларын яңаларына караганда да яхшырак итеп төзәтә торган булган. Кышлакның абруйлы бер гаиләсе аны үзләренә кияү итеп алуны зур дәрәҗә итеп санаган. Журналист егетләрнең аның туган

иленә кайту мөмкинчелегенә карата биргән сорауларына: «Бу бер фаҗигане икенче бер фаҗига белән алмаштыру булыр иде», – дигән. Хәзер аларның 3-4 яшьтәге ике уллары бар, тиз араларда өченче балалары булачагын сөйләгән. Әти-әнисеннән, дәү әти-дәү әниләреннән, туганнарыннан аны гафу итүләрен үтенгән. Егетләрне урамга кадәр озатырга чыкмаган. Ишек алдында үсеп утырган агачка сөялгән килеш, аларның өйдән чыгып китүләрен күрмәмешкә салышып басып калган.

Мине озатучы егетләр, артык хисләнгәнемне тоеп, моның сәбәбен ачыкларга теләделәр. Халыкның һәр кешесе – аның бүленмәс бер җәүһәр бөртеге. Ул бөртекнең югалуы – халык өчен зур югалту. «Әти-әнисе өчен гомерлек сагыш һәм әрнү» дигән сүзләремне һәркайсы үзенчә итеп кабул итте. Мин күңелемнән: «Үз халкыңның бер бөртеге булып яшәү нинди зур бәхет икән!» – дип уйладым...

Умарта оясын хәтерләткән Стамбул һава аланы – ярты дөнья кисешкән юллар чаты. Бу кадәр халык шушы мәһшәр арасыннан үзләре барасы юлларын ничек итеп таба алалар икән, дип уйлап бардым. Мин дә шушы кеше сөйләп бирә алмаслык ташкынга ияреп, алга таба агылдым. Егетләр дә булган кадәр шушы ташкынга ияреп бардылар. Мин артыма әйләнеп карадым. Алар да, мин күрсен дип, кулларын югары күтәргән хәлдә, шактый озак басып торганнардыр дип уйладым. Бу вакыйгаларга нәкъ егерме тугыз ел узган. Аркасы белән агачка сөялеп калган татар егете бүген дә төшләремә керә...

Икенче төш.

Төштә күргән кан – якын туган, кардәш димәк

Урал артындагы бер татар авылында утырам. Максатым шушы якларда яшәүче татарларның тарихлары, телләре, рухи мәдәниятләре турында китап язу иде. Бу якларга беренче килүем генә түгел. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, халкыбызның бу төркеме Урал якларының гүзәл табигате кочагында бик борынгы заманнардан бирле яши икән. Башта бу туфракларда себер татарлары, соңыннан, Себер ханлыгын руслар басып алгач, казан татарлары да килеп урнашкан. Кечкенә, ләкин бик тә пөхтә өйдә олы яшьтәге бабай белән әбидә яшим. Мине үз уллары кебек кабул иттеләр. Әби дә, бабай да бу яктагы халыкның тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен шулкадәр яхшы беләләр иде ки, теләсә нинди сорауга көннәр буе сөйләп утыра алырлар иде. Минем «Бу якларда төш салу, төш юрау осталары бармы?» дигән соравыма каршы әби: «Син бик ардың, бераз хәл алып кер. Күршеләребез дә синең белән танышырга тели», – дип, мине урамга озатты.

Урал арты татарларының һәр авылы да диярлек зур күлләр янында урнашкан. Капкадан балыклы күлгә кадәр 20-30 метрдан да ерак булмас төсле. Күршеләрнең капкаларын ачып кергәндә, илле яшенә дә җитмәгән хуҗабикә ишек алдында сап-сары, симез табан балыкларын чистартып ята иде. Мине әллә кайчангы танышы кебек каршы алды:

– «Бәхетле кунак ризыгы белән килә» дигән сүз чынлап та дөрес икән! Шушындый симез табаннарны ашарга кемгә генә насыйп булыр икән дип уйлап өлгермәдем, капкадан сез килеп кердегез.

Табын артында утыра-утыра, төш салу, төш юрау турында сөйләшеп китүебезне сизми дә калдык. Галимҗан, әнә, Сәгыйдә сөйләсен дип, утырган урыныннан җәһәт кенә торып, бүген генә туралган каен өеменә күчеп утырды.

– Төш салучылар да, төш юраучылар да бетеп баралар бит инде. Без, йокыдан торыр-тормас, нинди төш күрдем икән, дип уйланып торыр идек элек. Бер көнне йокымнан тора алмый хәлем бетте. Сыер саварга тормакчы булам да тагын түшәккә авам. Ул көнне сыер тәки көтүгә куылмый калды. Йокыдан торгач та, аягымны сәлендереп тик утырам. Нәкъ исерек кеше күек. Баш эшләми, ләкин ниндидер бер куркыныч хәл булганын сиземлим. Тора-тора бик куркыныч төш күргәнемне аңлый башладым. Шунсын ачык хәтерлим: без кунаклар көтәбез икән. Өстәл өстендә ит турыйм. Ите үземә ошамый. Ябык. Төштә ябык ит күрсәң, хәерлегә түгел. Каты авыру белән генә котылсаң ярый ла! Шыр сөякле бер ит кисәген кисәм дисәм, әллә нәмә булды да, тоткан пычагым белән кулымны бик нык итеп кискәнмен. Нишләргә дә белмим, кан кулым буйлап чаптырып ага. Алай итеп карыйм, болай итеп карыйм, канны һич кенә дә туктата алмыйм. Бездә җәйләр бик эссе була. Галимҗан, эссегә түзә алмыйм дип, ишек алдына чыгып яткан икән. Ул, минем тавышны ишетеп, йөгереп килеп керде. «Урыныңны берничә кабат «бисмилла»

әйтеп яңадан җәеп ятып кара»,– дип, яңадан тыштагы урынына чыгып китте. Кая ул йоклау! Күземне йомган хәлдә «Аятел Көрси»ләремне укып, төшнең мин күргән тәртибен төземәкче булып маташам. Юк. Булмады. Көн шушы киеренкелек белән үтте. Кичен Галимҗанга минем янга ятарга куштым. Икебез дә әллә нинди хәлдә. Күзне йокы алмый. Аз да үтмәде, тәрәзә шакыган тавышка уянып киттек. Күршенең быел әрмиягә китәсе улы: «Телеграмны әле шушы минутта гына, клубта утырганда, телефон аша районнан бирделәр. Мин алдым да туры сезгә йөгердем», – диде. Үзе бераз читкәрәк китеп басты. Китми тора. Галимҗан ул биргән кәгазьне алды да ай яктысына каршы тотып укырга маташа. Кулыннан теге кәгазе төшеп китте дә, үзе шап итеп җиргә утырды. «Нәрсә булды?» – дим. Бер сүз дәшми. Күрше малае: «Сәгыйрә апа, әйдә, өйгә керик әле», – ди. Аңламыйм. Көчхәлләр белән акылга килдек. Әфганстандагы малаемны, бик нык яраланып, госпительдә ята, дип язганнар. Минем ирем Галимҗаным менә дигән кеше. Егет вакытында да бик боевой, үтә дә акыллы иде. Телеграмны тотып районга җәяү чыгып йөгерде, юлда берәрнәрсә очрар әле, дип. Таң алдыннан гына кайтып керде, телеграмның кайдан җибәрелгәне күрсәтелмәгән. Галимҗан, ял итеп тә тормастан, Курганга китте. Аннан да бернинди хәбәрсез кайтты. Кайтып керү-кермәс, ишектән үк: «Кием-салым, акча әзерлә, мин шушы минутта Чиләбедән Мәскәүгә очам», – дип, өйнең астын-өстен күтәреп атты. Капка төбендә: «Мин малайсыз калдым бугай инде, хәзер синнән дә аерыламмы?» – дип елавыма, «Мин оборона министрына барам. Борчылма. Син мине беләсең, мин малай белән кайтачакмын», – дип чыгып йөгерде. И, ходаем, бер атна дәвамында минниләр генә күрмәдем. Күршеләрем мине ашатып-эчертеп, кочаклап кына утырдылар. Бер атнадан соң гына телеграмы килде: «Мин малай янында, ул исән», дигән иде. Ул телеграмны бөтен авыл егетләре, малайлары олимпия утын китергән кебек китерделәр. Мин шул минутта ук хушымнан язганмын. Өч көн буе йоклаганмын. Медсестра янымда кунган.

Малай иптәшләре белән частьләренә кайтып җитәм дигәндә генә, чолганышка эләккәннәр. Бик күп егет шунда ук һәлак булган. Калганнарын тегеләрдән коткарып калсалар да, вертолет белән больница булган җиргә чыгара алмаганнар. Иптәшләре егет яныннан бер минутка да китмәгәннәр. Малайның хәле үтә дә авыр булганга, турыдан-туры Ташкентка алып чыкканнар. Саташканда, аңга килгәндә дә, «әтине табыгыз», дип пышылдый торган булган. Әтисе булса, аны исән калдыруына ышанган. Ташкентка мин дә киттем. Галимҗан «министрга доложу» дип кенә торганга, бернәрсә дә эшли алмадылар, янында булырга рөхсәт бирделәр. Күзен мин килгәч ачты. Бик озак елмаеп ятты. Бераздан әтисенең кулын тотып ята башлады.

Аягына баскач, өч ай отпуск бирделәр. Менә дигән булып терелде. Тагын шуны өстәп әйтим: минем кулымның каны акканын авылда тагын бер хатын күргән икән. Ул бик күп елларга кадәр аны беркемгә дә сөйләмәгән. Кан күрү – туганыңа зур хәвеф яный дигәнне аңлата, диләр безнең якта. Хәвефле итеп күргән төшне иясенә сөйләргә ярамый.

Фәрит ЮСУПОВ,
филология фәннәре докторы, профессор,
Халыкара Дил Коруму җәмгыятенең
мәһбир-әгъзасы. Стамбул-Төркия.

Һөнәр алды – кызыл тел

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дигән мәкаль коры урында тумаган. XX гасыр башларына Идел буе татарларының 150дән артык кәсебе билгеле, ди галимнәр. Агач эшкәртү, күн белән эшләү, туку-эрләү, тегү-чигү, киез басу... Һәр һөнәрнең үзенең аерым осталары булган. Һәм алар үзләренең эшләнмәләрен сәнгать дәрәҗәсенә җиткергәннәр. Әлеге традицияләр күп вакытлар буыннан-буынга күчеп килсә дә, илдә-көндә барган үзгәрешләр, техник алгарыш нәтиҗәсендә аларның күпчелегенә ихтыяҗ калмаган. Бүген исә халык һөнәрчелеге бездә нәкъ менә сәнгати яктан кызыксыну тудыра.

Без инде 15 елдан артык Яр Чаллы шәһәренең 13нче татар балалар сәнгать мәктәбендә эшлибез. Безнең мәктәптә укучылар рәсем сәнгатен алты төрле юнәлештә өйрәнә. Шуларның берсе – декоратив-гамәли сәнгать дәресләре. Әлеге дәресләрне алып барганда терминология мәсьәләсендә шактый кыенлыкларга юлыктык. Баксаң, бу өлкәдә без атамаларны, уйлап та тормыйча, рус телендә кулланабыз икән. Һөнәре булгач, аның атамасы да татарча булган бит инде, ул атамаларны, һичшиксез, телебезгә кайтарырга кирәк. Без шул юнәлештә беренче адымыбызны атладык, дип әйтә алабыз. Каюлы күн темасын өйрәнгәндә, бу өлкәгә кагылышлы атамалардан кечкенә бер сүзлек төзеп карарга булдык. Сүзлекне төзергә укучыларыбызны да җәлеп иттек. Бу эштә бигрәк тә безнең сәнгать мәктәбендә җиденче ел белем алучы Адилә Зарипова һәм Гөлнара Шәехововалар зур тырышлык күрсәтте. Китапханәләрдән, ачык чыганаклардан (интернеттан) бергәләп күп мәгълүмат тупладык. Татар теле укытучылары да бик ярдәм итте. Шулай итеп, уртак тырышлык белән, «Бизәкле татар декоратив-гамәли сәнгать атамалары сүзлеге» барлыкка килде.

Алга таба сүзлегебез тагын да тулыланыр, ул халык һөнәрчелегенең башка төрләрен дә үз эченә алыр дип уйлыйбыз. Бу сүзлек татар халык һөнәрчелеге белән кызыксынучыларга, сынлы сәнгать дәресләрен алып баручы укытучыларга, сәнгать мәктәбенең рәсем бүлегендә укучыларга аеруча файдалы булыр дип ышанып калабыз.

Зөлфия ДАДАШОВА, Миңнур ЗОЛЬНИКОВА,
югары категорияле сынлы сәнгать укытучылары.

Каюлы күн һөнәрчелегендә кулланыла торган атамалар

Идел буе болгарлары югары сыйфатлы тире эшкәртү осталыгы белән дан тоткан. Казан осталары җитештергән бизәкле аяк киемнәренә чит илләрдә дә ихтыяҗ зур булган. Күн эшкәртү ысулы татар милли сәнгатенең символына әверелгән. Бу һөнәр бүгенге көннәргә кадәр сакланган һәм каюлы күн стилендә тирене нәфис эшкәртү ысулы төрле әйберләр әзерләгәндә киң кулланыла.

Азия аяк киеме (Азиатская обувь) – XVIII-XX гасырларда Россия мөселман халыкларында киң таралган, Казан артында җитештерелгән аяк киемнәре төрләренең гомуми исеме: йомшак һәм каты табанлы читекләр, күн кәвешләр, башмаклар, чүәкләр.

Булгар (Булгари) – Идел буе болгарлары тарафыннан җитештерелгән югары сыйфатлы кызыл һәм көрән төстәге күн сорты. XIII-XIX гасырда төрле илләргә чыгарылган йомшак өй итекләрен дә шулай дип атый башлыйлар. Фарсы телендә «булгар» – хуш исле төсле күн дигән мәгънәне аңлата.

«Дворян» читекләре («Дворянские» полусапожки) – XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында Казанның читек тегү кәсебендә хатын-кызлар өчен озын кунычлы заманча матур итеп эшләнгән читекләр барлыкка килә. Читекнең алгы ягында җепле бәйләү ясалган һәм кунычы казан җөе ысулында вак нәкыш белән бизәлгән була.

«Казан» җөе («Казанский»/«татарский» шов) – кулдан киселгән күн кисәкләрен бер-берсенә теркәтеп тоташтыру ысулы. Мондый ысул ныклыгы һәм матурлыгы белән аерылып тора. Казан җөе без (шило) һәм чигү энәләре ярдәмендә өчкырлы казык (колодка) өстендә тегелә.

Кәвеш (Кауши/кавуши) – өйдән чыкканда йомшак читек өстеннән киелә торган күн галошлар. XIX гасыр ахырында резина галошлар барлыкка килү сәбәпле, читек тегү кәсебеннән күн галошлар кысрыклап чыгарыла.

Каюлы күн (Кожаная мозаика) – казан җөе ысулын кулланып башкарылган каюлы читек тегү кәсебе һәм каюлы күн сәнгате исеме.

Озын кунычлы ир-атлар читеге (Вытяжные ичиги) – кара, куе-яшел, көрән, зәңгәр, чия төсендәге йомшак табанлы, бер арткы җөй белән тегелгән аяк киеме. Ул, башка читекләрдән аермалы буларак, тоташ киселгән тиредән тегелә. Читекнең кунычы аерым төстәге бизәкле кисем белән тәмамлана.

Сәхтиян күн (Сафьян) фарсы телендә «эшкәртелгән кәҗә тиресе» дигән мәгънәне аңлата. Ачык төсләргә буялган югары сыйфатлы юка һәм йомшак тире. Иң киң таралган сәхтиян күн кызыл төстә булган.



Читек (Ичиги) – азиялеләрнең аяк киеме төре. Озын һәм кыска кунычлы, йомшак табанлы, өйдә киелә торган читек. Соңрак «читек» сүзе хатын-кызларның каты табанлы һәм биек үкчәле итекләренә карата да кулланыла башлый.

Татар чигүендә кулланыла торган атамалар

Татар халык һөнәрчелегенең иң киң таралган һәм традицион төрләренең берсе – чигү. Элекке заманда татар өйләренең һәммәсендә дә матур бизәкләр төшереп чигелгән намазлык, өйне икегә бүлеп торучы чаршау, сабый бишегенә тартылган чыбылдык, тәрәзә пәрдәләре, кашагалар, мендәр тышлары, җаймәләр булган. Халкыбыз еллар һәм гасырлар буе бизәкләп эшләү һөнәрен саклап һәм үстереп килгән.

«Алтын каурый» («Золотое перо») – юнәлеше буенча айсыман бөгелгән үсемлек-чәчәк бизәге. Мондый бизәк калфак чигүдә кулланыла.

Бәрхет, ефәк, парча, сатин – чигү өчен кулланыла торган тукыма төрләре.

Гарус, ефәк, мулине, катылган җеп, йон җеп, канитель – чигүдә кулланыла торган җеп төрләре.

Канитель – ефәк җепкә спираль итеп уралган алтын яки көмеш җеп.

Күперткән элмә (Высокий тамбур) – вак атламнар ясап кабарып торган бау рәвешендә тамбур җөе белән чигү.

Сәйлән белән чигү (Вышивка бисером) – сәйлән бөртекләре кулланып чигү ысулы.

Тамбур җөе (Тамбурный шов) – бизәкләрне буыннар барлыкка китереп бер үк төрле атламнар – чылбырсыман җөй белән чигү.

Тырнак алмалау (Ушковая техника) – өчпочмаклы вак ефәк тукыма кисәкләрен бер-берсе өстенә тегеп, күпертмәле чәчкәләр чигү.

Ука (позумент, галун) – чигүдә кулланыла торган алтын яки көмеш җепләр.

Татар орнаментында чәчәк атамалары

Казан татарларының декоратив-гамәли сәнгатендә чәчәкле үсемлек орнаменты мөһим урын алып тора. Чәчәкле үсемлекләр халкыбыз сәнгатенең һәр төрендә дә киң таралган, ә чәчәк мотивларының күптөрлелеге кайчак гаҗәпкә калдыра. Бизәкләрдә борынгы көнчыгыш дала үсемлеге (лалә, лотос, пальметта) белән беррәттән, соңрак килеп чыккан бакча һәм кыр чәчәкләре дә урнаштырыла. Бу күптөрле чәчәк дөньясында, табигать мотивлары белән бергә, фантастик чәчәкләр дә зур урын били.

Алтын чәчәк (хризантема) – чәчәкләре төрле төстә, таҗ яфракчыклары кәрзин формасында оешкан декоратив үсемлек.

Акчәчәк (ромашка) – сары урталы, ак таҗ яфракчыклы чәчәкле үсемлек.

Дәлия чәчәге (георгин) – кызыл, сары, алсу, шәмәхә, ак эре чәчәкле декоратив үсемлек.

Канәфер чәчәге (гвоздика) – кызыл, алсу, шәмәхә, ак төстәге чәчәкле үсемлек.

Кашкарый (астра) – төрле төстә чәчәк ата торган, таҗ яфракчыклары кәрзин формасында оешкан чәчәкле үсемлек.

Кыңгырау чәчәк (колокольчик) – шәмәхә яки күе зәңгәр төстәге, чәчәге кыңгырауга охшаган үсемлек.

Лалә чәчәге (тюльпан) – чәчәкләре төрле төстә, өч эчке һәм өч тышкы таҗ яфракчыкларыннан тора. Лалә татар орнаментында иң еш очрый торган чәчәкләрнең берсе.

Мәк чәчәге (мак) – кызыл, алсу чәчәкле декоратив үлән үсемлек, җимешләре тартмалык формасында өлгерә.

Чалмабаш (пион) – кызыл, алсу яки ак эре чәчәкле декоратив үсемлек.

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Чигү чигәм алтын җепләр белән...

Алтын җепләр белән чигү – бик борынгыдан килгән асыл сәнгать. Археологик табылдыклар укалап (алтынлап) чигүнең Шәрык илләрендә инде безнең эрага кадәр VI-V гасырда ук барлыкка килүе турында сөйли. Вакытлар узу белән бу сәнгать Себер, Кавказ, Идел буе, Азия, Европа җирләрендә дә тарала.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, татарларда чигү сәнгатенең яңадан чәчәк аткан чоры XVIII-XIX гасырларга туры килә дип исәпләнә. Алтынлап чигү дә нәкъ менә XVIII гасырның икенче яртысында популярлашып китә. Элек чигүдә саф алтын, көмеш кулланылганга күрә, бу һөнәр бик кыйммәткә төшкән, алтынлы калфак, түбәтәйләрне бары тик шәһәр байлары гына кия алган, дигән фикер дә бар. Әмма гади татар йортындагы исәпсез-хисапсыз чигүле әйберләр арасындагы ислам атрибутикасы – намазлык, ләүхә, шәмаил, Коръән савыты, китап япмасы – барысы да шулай ук тамбурлы яисә тоташ чигү, алтын җепләр белән чигү ысуллары кулланып, гаҗәеп бай орнаментлар белән баетылган була.

Казан татарларының укалы чигүенең даны ерак-еракларга киткән, XIX гасырда алтынлап чигүче танылган осталар булган. Аларның затлы кул эшләре данлыклы «Печән базары»нда, Мәскәү, Түбән Новгород шәһәрләрендә узган ярминкәләрдә сатылган.

Совет чорында юкка чыгу алдына килеп баскан татар декоратив-гамәли сәнгате, узган гасырның туксанынчы елларында милли үзаңның үсеш алуы нәтиҗәсендә, яңадан күтәрелеп китте. Яшь рәссамнар, тегү-чигү осталары, музейларда сакланган чигүләрнең классик үрнәкләрен өйрәнеп, әлеге борынгы һөнәрнең серләрен белгән, инде сирәк кенә калган осталарны табып, җиң сызганып эшли башлады. Нәтиҗәдә, алтынлап чигү белән шөгыльләнүче яңа буын осталар барлыкка килде.

Шуларның берсе – рәссам Луиза Фәсхетдинованың исеме дә, иҗат эшләре дә күпләргә таныштыр дип уйлыйм. Луиза ханым чигү һөнәрен Бохарага ук барып үзләштерә. Кайткач, бик җентекләп, үзебезнең музейлардагы чигү үрнәкләрен, татар бизәкләрен өйрәнә. Бер үк вакытта шушы юнәлештә фәнни эшчәнлек тә башлап җибәрә. «Казан татарлары калфак, изү, күкрәкчә, камзулларын алтын җепләр белән чигеп бизәгәннәр. Бүгенге көндә без чигешләрнең камил үрнәкләрен генә күрәбез. Кызганычка, борынгы бизәк һәм кабатланмас асыл нәкышләрнең байтагы җуелган шул. Тәфсилләп өйрәнә башлагач, болар бик тиз күзгә ташлана», – ди Луиза ханым.

Ә менә язмамның героен – Нурислам Сираҗиев дигән егетне мин социаль челтәрләрдә очраттым. Әлеге һөнәрне хатын-кызлар белән генә бәйләп күз алдына китергәнгә, кызыксынуымны җиңә алмыйча, түбәтәйләр, калфаклар чигүче егетне тиз арада эзләп тә таптым.

Бик тә кызыклы егет булып чыкты Нурислам. Казанда туып-үсеп, рус мәктәбендә укыса да, ана телен камил белә, алай гына да түгел, һәр сүзне чигүдәге сәйләннәр төсле сайлап кына сөйләшә! Бу уңайдан ул дәү әниләренә – яшүсмер чакта ук Әтнә районы Күлле Киме авылыннан Казанга чыгып китеп, гомере буе очкычлар җитештерү заводында эшләгән, телнең моңын, байлыгын әкиятләр аша сабый аңына сеңдергән Кәшифә әби белән Саба районының Шәмәрдән бистәсендә яшәүче Илгизә әбигә рәхмәтләр укый.

Нурислам белеме буенча – тел белгече. Татар, рус телләреннән тыш, төрек, гарәп, фарсы телләрен әйбәт белә. Казанда гуманитар институтны тәмамлагач, гарәп телен өйрәнергә дип Үзбәкстанга чыгып китә; аннан кайткач, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый.

Нурислам балачактан ук чигү белән кызыксына. Әле студент елларында ук, Мәрҗани мәчетендә Габделхак абый Каюмов белән таныша. Теләче ягындагы атаклы бүрекчеләр нәселеннән булган Габделхак абый, хатыны белән бергәләп, Иске татар бистәсендә бүрекләр, казан кәләпүше теккән кеше булып чыга. Үзенең гомер буе туплаган тәҗрибәсен ул Нурислам белән дә уртаклаша, алай гына да түгел, үзенең кәсебен егет кулына тапшыра. Шулай итеп, Нурислам, элеккеге үрнәкләр нигезендә, укалап түбәтәйләр, калфаклар чигә башлый. Чигүнең төрле ысулларын кулланып, татар бизәкләрен мендәр тышлыкларына, сөлгеләргә, кульяулыкларга, футболкаларга төшерү белән дә шөгыльләнә.

Казан кәләпүше кара төстә була һәм ул бизәксез итеп, өске өлеше алтыга бүленеп, кулдан сырып эшләнелә икән. Башны тирләтми торган, үзе җиңел һәм уңайлы мондый түбәтәйләрне Нурислам бүген бик күп әзерли. «Әлбәттә, бик четерекле эш, ләкин бүгенге көндә якташлар да, чит өлкәләрдәгеләр дә нәкъ менә казан кәләпүше белән кызыксына», – ди ул. Баксаң, Г. Кариев исемендәге яшь тамашачылар театрының яңа премьерасы – Г. Исхакый әсәре буенча куелган «Кәҗүл читек» спектакле өчен дә бөтен кәләпүшләрне Нурислам теккән икән!

– Башта тегә генә идем, аннары китаплардагы сурәтләргә, үзем фотога төшереп саклап куйган рәсемнәргә карап чигә башладым, – ди Нурислам. – Укалап чигү өчен Төркиядән кайткан сыйфатлы хәтфәләрне кулланам. Аларга бизәк бик таслы ята, матур килеп чыга. Аннары, Һиндстан осталары алтынлап чигәргә бик оста. Һиндстанда чигү белән нигездә ир-егетләр шөгыльләнә. Эш алымын алардан карыйм да, үзебезнең милли бизәкләрне төшерәм. Бабайдан калган бик иске кәләпүш бар иде безнең өйдә. Хәтфәсе кырылып бетсә дә, алтын бизәкләренә берни булмаган. Шуңа карап гел соклана идем. Минем дә шулай чигәсе килә! Элегрәк, әле туксанынчы елларда да алтын җеп табу бик авыр иде. Эзләнә торгач, бер әби милиционер улының фуражкасын бирде. Аның алтын җепләр чорнап бәйләп ясалган бизәге бар. Менә шуны сүтеп, эчендәге сүс җепләрен тартып чыгарып, алтынлы җепләрен чигүдә кулландым. Хәзер мондый мәшәкатьләр юк инде, шөкер. Канительне теләсәң Мәскәүдән, теләсәң Һиндстаннан, теләсәң Әфганнан кайтартып була.

Ука белән чигү бик катлаулы эш. Технологиясе авыр, әмма өйрәнәм дигән кеше үзләштерә ала. Тимерчыбык бик нәзек, аны мең кат

итеп урап, җеп хәленә китерәләр, күпшә кебек була инде; нәтиҗәдә, махсус алтын җеп килеп чыга. Бизәгенә карап, шул тимер җепне кайда 2 мм, кайда 7 мм озынлыкта кисеп, энәгә кертеп бизәк чигәсең. Бик авыр, матавыклы, нечкә эш. Сызыкларның дөрес якка ятуы кирәк. Шуңа да кыйммәтле чигү ысулы булып санала ул.

Казанда беркадәр укытучы булып эшләп алганнан соң, Мәскәүгә китәргә була Нурислам. Сату-алу белән бәйле эшкә алына. Әмма түбәтәйләрдән башланган тегү-чигү эше күңеленә тынгы бирми. Кичләрен тамбурлап чигү эшенә керешә. Җиренә җиткереп, элмәген-элмәккә, җөен-җөйгә китереп эшләргә яраткан Нурислам, татарча тамбурлы чигү буенча бирәр файдалы киңәш тапмаммы дип, интернетта бик озак эзләнә. Тапмый. Башкортостаннан Рая Вилданованың башкорт телендә яздырылган берданбер видеоязмасы гына очрый. Кат-кат шуны карый ул.

Алга таба «Вконтакте» социаль челтәрендә чигү белән кызыксынучылар өчен үз төркемен булдыра. Ул төркемдә бүген Россиянең төрле төбәкләреннән 800дән артык кул эшләре осталары теркәлгән. XIX-XX йөзләргә караган, дөньяның иң зур музейларында саклана торган чигү үрнәкләре, төрле бизәк схемалары, рәсемнәр тупланган биредә. Нурисламның үзенең кул эшләре дә, видеоматериаллар да бар.

– Бу шөгыльнең тагын шул ягы бар: кул эшләрен югары бәягә сатып булмый, ким бәягә сатсаң «өстеңнән чыга», чөнки материаллар шактый кыйбат. Бервакыт Американың Лос-Анджелес шәһәрендә яшәүче милли җанлы танышым Айгөл Гыймрановадан посылка килеп төште. Ачып җибәрсәм, тартма тулы зиннәтле тукыма, чигү кирәк-яраклары! Рәхәтләндем мин алар белән! – ди Нурислам.

«Җаны теләгән – җылан ите ашаган», дип дөрес әйткәннәр. Бүгенге көндә Нурислам үзенең яраткан эшеннән илһам, иҗат дәрте алып, канатланып яши. Казандагы, Мәскәүдәге һәм чит илләрдәге дусларын котларга җыенса, бүләк эзләп азапланмый – затлы бүләк һәрчак кул астында. Нурисламның редакциягә алып килгән кул эшләрен күреп, үзебез дә таң калдык: шулкадәр нәфис һәм оста итеп укалап чигелгән калфак, казан кәләпүше, тамбурлы чигү белән чигелгән сөлгеләр, япмалар. Бу чигешләрне махсус программа куелган чигү машинасы гына эшли аладыр сыман. Тик... машина чигешендә мондагы җылылык булмас иде шул. Кул җылысы гына түгел, күңел җылысы, самими ихласлык, мәхәббәт аңкый бу гүзәл чигешләрдән!

Шул ук вакытта, күңелне әрнетеп, базарларга, шәһәребезнең йөзен чагылдырырга тиешле сувенирлар сатыла торган кибетләргә әллә кайлардан китереп тутырылган, сыйфатсыз материалдан тегелгән ялтыр-йолтыр түбәтәйләр күз алдына килде...

Нурисламның хыял-теләкләре тормышка ашып, гасырлар кичә-кичә килеп җиткән затлы-зәвыклы казан түбәтәен җитештерү дәүләт тарафыннан игътибарга алынса, бу – татарның милли үзаңын, милли горурлыгын үстерүдә үзенә бер әһәмиятле адым булыр иде, мөгаен.

Бистәнең татар учагы

Казан шәһәренең Киров районында урнашкан 15нче татар гимназиясендә берничә тапкыр булганыбыз бар. «Татарстанның иң яхшы мәктәбе» Республика бәйгесе җиңүчесе, «Россиянең иң яхшы мәктәбе» Бөтенроссия бәйгесе лауреаты дигән исемнәргә лаек булган әлеге гимназияне тарихы Идел Болгары чорларына барып тоташучы Бишбалта бистәсенең чын мәгънәсендә татар милли-мәдәни учагы дип атасак, һич ялгышмабыздыр. Узган ел гимназиядә Казан адмиралтействосы тарихы һәм Адмиралтейство (Бишбалта) бистәсе татарларының тормыш-көнкүрешенә багышланган музей ачылуы 15нче татар гимназиясенең дәрәҗәсен тагын да күтәреп, эшчәнлеген тагын да тирәнәйтеп җибәрде.

Әлеге музейны булдыру Татарстан Республикасының вице-премьеры, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы рәисе В.Г. Шәйхразиев, Конгрессның башкарма комитеты рәисе, тарих фәннәре докторы Р.З. Закиров, танылган эшмәкәр, Конгрессның Милли шура бюросы әгъзасы Э.Ә. Ганеев, Конгрессның Милли шурасы әгъзасы, тарих фәннәре докторы Д.М. Исхаков (ул әле музейның фәнни җитәкчесе дә булып тора) һәм эшмәкәр Г. Хисаметдиновларның ярдәме белән гамәлгә ашырылды.

Музейның исеменнән үк күренгәнчә, экспозициянең зур өлеше Казанда Петр I тарафыннан төзелгән Адмиралтействога багышланган. Шуны ассызыклап китәргә кирәк, Адмиралтейство төзү өчен Бишбалта бистәсе очраклы гына сайланмаган. Бишбалта авылы тирәсендә элек-электән нарат һәм имән урманнары шаулап утырган. Болгар дәүләте чорында биредә көймәләр ясаганнар (бистәнең исеме «биш балта» да биредә балта осталары хезмәт куйганлыгына ишарәле). Казан ханлыгы чорында болгар-татарлар көймәләрне Тәзик (Тәҗик) ком утравында (ул Бишбалта каршысында булган) ясыйлар.

Петр I, Адмиралтейство төзү турында карар кабул иткәндә, һичшиксез, татарларның кораблар төзү эшендәге традицияләренә таяна. Алай гына да түгел, Адмиралтейство эшенә җәлеп ителгән халыкның – аларны лашманчылар дип йөртәләр – зур күпчелеген йомышлы татарлар тәшкил итә. Арада чуашлар, марилар, мордвалар да күп була. Лашманчылар бушлай урман кисәргә, аны эшкәртеп, Казанга китерергә тиеш була. Үсмерләрдән башлап, картларга кадәр барлык ир-егетләр, үзләренең атлары һәм эш кораллары белән кышын урманга китәләр. Алар юеш һәм салкын землянкаларда яшиләр. Тимер кебек нык, колач җитмәслек юан имәннәрне егып, ботакларыннан чистарталар. Аларны кар өстеннән сөйрәп, елга ярына китерәләр. Яз көне, елгалар ташыган вакытта Казанга агызалар. Бу эшләрдә меңнәрчә кеше һәлак була...

Казанда ел саен яз көне бишләп корабны суга төшергәннәр. Җиде ел эчендә өч дистә чамасы кораб суга төшерелә.

1722 елның маенда Петр I Казанга килә. Ул Адмиралтейство эшеннән бик канәгать кала. Аннары ул Казан судноларында Персия походына китә. Һәм Россия флоты Каспий диңгезендә бер-бер артлы җиңүләр яулый.

Адмиралтейство төзелү крайдагы сәүдә әйләнешен бик нык арттыра. XIX гасырның 40-60нчы елларында Казан губернасы илнең үзәк районнарына һәм чит илләргә 15 миллион пот чамасы ашлык җибәрә. Базарда, ашлыктан тыш, күн, сабын, терлек мае, поташ, бал, балавыз, комач, кытай тукымалары, мех һәм агач материалларына ихтыяҗ зур була. Товарлар Мәскәү, Петербург, Әстерхан, Оренбург, Саратов, Рыбинск, Ростов-Дон, Ярославль, Түбән Новгород, Уфа, Эрбет, Петропавловск тарафларына озатыла. Кытай белән Россия арасындагы сәүдә юлы үзәге булып саналган Кяхтада Казан күне сатыла.

Музейдагы экспозициянең икенче өлеше Бишбалта татарлары тарихына багышланган. Йорт җиһазлары, эш кораллары, савыт-саба, кием-салым, чигешләр, бизәнү әйберләре, халык уен кораллары, дини китаплар һәм башка предметлар – болар барысы да бер-берсен тулыландырып, Бишбалта татарларының тормыш-көнкүрешен, рухи дөньясын шактый тулы һәм ачык итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Археолог Альберт Борһанов коллекциясендәге казылма табылдыклардан торган почмак музейның эчтәлеген тагын да баетып, тирәнәйтеп җибәрә.

Музейга кергән кеше Бишбалта татарларының дини-рухани тормышы турында да байтак мәгълүмат алып чыга.

Мәгърифәтче Ш. Мәрҗанинең «Мостафадел-әхбар...» дигән хезмәте буенча, 1805 елда Бишбалтада Казан сәүдәгәре Йосыф Мортазин акчасына мәчет төзелә. 1878 елның 1 нче февралендә мәхәлләдә мәдрәсә ачыла. 1906 елда мәдрәсәдә 40 шәкерт укыганлыгы билгеле. Кыз балаларны мулланың остазбикәсе белән азанчы хатыны өйләренә җыеп укыта. Мәдрәсәдән тыш, Бишбалтада шәһәр казнасы хисабына мөселман училищесы да ачыла. 47 малайга белемне татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган Габдрахман Вәли улы Рафыйков бирә, дин сабагын мәхәллә мулласы укыта.

1898 елның 18 нче февралендә Казан губерна идарәсе сәүдәгәр Сөләйман Мөхәммәтҗан улы Аитов акчасына Бишбалта халкы өчен икенче мәчет төзергә рөхсәт бирә.

«Казан Адмиралтействосының өч йөз еллыгына туры китереп ачылган музеебыз балаларга татар тарихын, аерым алганда, Бишбалта бистәсе татарлары тарихын өйрәнүдә, аларның милли үзаңын үстерүдә әйтеп бетергесез роль уйный, – диде музей проектының җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Кадрия Габбасова. – Экспонатлар туплау дәвам итә. Шунысы куанычлы, музеебыз экспозициясен тулыландыруда гимназиянең укытучылар коллективы гына түгел, укучыларыбыз, аларның әти-әниләре дә актив катнаша. Шулай булгач, алар инде татар тарихына, милләтнең киләчәгенә битараф булмаячак дигән сүз. Гомумән, безнең гимназия бистәнең татар мохитен саклап калырга тырыша».

Гөлсинә ХӘМИДУЛЛИНА

«Әй бәңа зийәрәт кыйлгучы...»

Бишбалта бистәсе зираты бик борынгы чорларга, ягъни Казан ханлыгы дәверенә үк карый дигән фикерләр булып, зиратта шул турыда искәрткән язмалы таш та табылуга карамастан, тарихи чыганакларда бу тирәдә борынгы кабер ташлары булу турында мәгълүмат очрамый. Казан шәһәре һәм аның тирәсендәге борынгы эпиграфик истәлекләрне өйрәнгән галимебез Ш. Мәрҗани, шулай ук XX гасыр башында эпиграфика белән шөгыльләнгән Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Г. Әхмәров, С. Вәхиди һ.б. галимнәр дә Бишбалта бистәсе ташъязмалары хакында бер сүз әйтмәгән. Без белгән борынгы карталарда да Бишбалта бистәсендә татар зираты күрсәтелмәгән, фәкать XVIII йөзнең ахырына караганнарында гына хәзерге Брюсов урамындагы зират билгеләнгән.

Тарихчы Е.В. Липаков, Бишбалта зиратына 1848 елның декабрендә нигез салынган, чөнки Казан шәһәре Думасы шул елда аны ачарга карар чыгарган, дип язган[1]. Дөрестән дә, архивта сакланган тарихи документларга караганда, аларда шул елда Бишбалта бистәсендә татар һәм рус зиратларына җирләр бүлеп бирү хакында сүз бара, әмма без, 1793 елга нисбәтле карта[2] нигезендә, XVIII гасырда инде анда татар зираты булган, дип төгәл әйтә алабыз. Ә 1848 елгы документта әлеге зиратны зурайту, чикләрен билгеләү турында сүз барган, чөнки анда болай диелгән: *«Җир үлчәүче ярдәмчесе Сапожниковка эшчеләр кирәк-яраклары белән астролябия чылбырларын күтәреп йөрү, таяклар кагу, чокырлар казу һәм баганаларны элек билгеләнгән урыныннан яңа чик борылышларына күчерү өчен кирәк»*[3]. Бәлки, зират байтак еллар ябылып торып, 1848 елда анда җирләргә рөхсәт итә башлаганнардыр. Ул вакытта зиратның җирләрен билгеләү, үлчәү, казыклар кагу эшләре җир үлчәүче ярдәмчесе Сапожниковка йөкләнгән. Бу эшне башкарып чыгу өчен аңа гласный Командировка мөрәҗәгать итәргә боерылган. Командиров исә ун эшче яллаган һәм үз кесәсеннән кирәкле суммада акча бүлеп биргән. 1849 ел башында эшчеләр буласы зират урыннарында чокырлар казыганнар, таяклар һәм баганалар утыртканнар, астролябия белән җир үлчәргә ярдәм иткәннәр. Шул рәвешле, Сапожников зиратлар өчен кирәк булган барлык эшләрне тиешле дәрәҗәдә үтәп чыккан. Ахырдан шәһәр бюджетыннан гласный Командировка тотылган акчаларын кире кайтарганнар. Шулай итеп, татар зиратының яңа чикләре билгеләнгән, ә рус зираты Игумново бистәсе янында барлыкка килгән.

1875 елда зиратның попечителе итеп галим Галимҗан Барудиның атасы Мөхәммәдҗан Ибнеямин улы Галиев билгеләнгән[4]. Каберстан су янында урнашканлыктан, яз саен аны өлешчә су баса торган булган, шуңа күрә 1879 елда Шәһәр думасының санитар комиссиясе зиратны ябарга дигән тәкъдим белән чыккан. 1884 елда Макарьев чиркәве башлыгы Сычов та бу мәсьәләне күтәреп, зиратка мәетләр җирләүне туктату ягында тор-

ган. Әмма Мөхәммәдҗан Баруди тырышлыгы белән ул ябылмыйча калган, шулай да шәһәр түрәләре мәетләрне яхшылап һәм тирәнрәк күмү шарты куйган булган[5]. Су басу аркасында, үлгәннәрне анда җирләргә тырышмаганнардыр, шуңа күрә 1881 елда да әлеге зират кечкенә генә урын биләгән[6].

Безнең уйлавыбызча, Бишбалта бистәсендәге зират XVIII йөздә барлыкка килгән булса кирәк. Казан ханлыгы чорыннан ук мәгълүм булган бистәдә, әлбәттә, шул борынгы дәвергә караган зират та булмыйча калмагандыр. Бәлки анысы Бишбалтаның төп урынында, ягъни хәзерге «Петрушкин двор» тирәсендәрәк урнашкандыр. Һәрхәлдә, Брюсов урамындагы зиратта Казан ханлыгы чорына түгел, хәтта XVIII йөзгә нисбәтле эпиграфик истәлекләр дә сакланмаган.

Зиратка Бишбалтада яшәүче татарларны, шул тирәдәге предприятиеләрдә һәм якындагы сәүдә пристанендә эшләүчеләрне, бистә сырхауханәсендә вафат булган мөселманнарны җирләгәннәр. Бишбалта бистәсендә яшәүче татарларның кайберләре Яңа татар бистәсе һ.б. зиратларга күмелгән.

Моңарчы әле Бишбалта зираты эпиграфик планда бөтенләй өйрәнелмәгәнгә, андагы хәзерге көннәргә кадәр сакланып калган ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен узган ел Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан фәнни экспедиция оештырылды. Шул рәвешле, гарәп язулы кабер ташларын эзләп табып, һәрберсен фотога төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Барлыгы 25 кабер ташы (күбесе фрагментлар) табылды.

Мисал өчен:

Билгесез кабер ташы фрагменты, XIX гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

«...

1) дарел-фәнадан дарел-бәкайә рихләт [кылды]

2) гарикы рәхмәт улсун».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әй бәңа зийәрәт кыйлгучы...

Сул ягы (калкытып язылган): «... кыйлуңыз шад».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

«...

1) фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте.

2) Рәхмәткә күмелсен».

Уң ягы: «Әй, мине зиярәт кылучы...

Сул ягы: «... [рухымны] шатландырыгыз».

Таш үлчәмнәре: 106х33х10.

Үзенең тышкы кыяфәте һәм палеографик билгеләре буенча әлеге таш һичшиксез XIX гасыр урталарына туры килә һәм зиратта сакланган иң борынгы эпиграфик истәлек булып саналырга хаклы. Кызганычка каршы, җимерелү сәбәпле, текстына зур зыян килгән.

Әсхабҗамал Йосыф кызына куелган кабер ташы фрагменты, XIX гасыр.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

«...

1) көн мөтәвәффиййә Әсхабҗамал

2) Йосыф кызы Мотыйгулла хәлә-

3) -ле 36 йәшендә рух пәрфөтухы

4) тарафе гыйләллинә пәрвәз әйләде нәүвәраллааһ».

Уң ягы (уеп язылган): «... әүләд гакыйл кәрәм әйләб безә дайим дога кыйл».

Сул ягы (уеп язылган): «[Галәмәт]дән морадым бер догадур бу көн бәңа икән йарин сәңадур».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

«...

1) көн вафат булучы Әсхабҗамал

2) Йосыф кызы — Мотыйгулла хәлә-

3) -ле - 36 яшендә аның юмарт рухы

4) килеп чыгу тарафына очты. Аллаһ нурландырсын».

Уң ягы: «... акыллы балалар, юмартлык кылып, безгә даими дога кыл[ыгыз]».

Сул ягы: «[Галәмәт]тән морадым бер догадыр; бу көн миңа икән, иртәгә сиңадыр».

Таш үлчәмнәре: 87х34х18.

Үзенең тышкы кыяфәте һәм палеографик билгеләре буенча әлеге таш XIX гасырның 70 нче елларына туры килә.

Мулла Билаледдин Габид улына куелган кабер ташы, 1918 ел.

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Әш-шәйху

2) мулла Билаледдин

3) әл-Габиди әл-Бохари

4) 48 сәнә имамәт итеб

5) 80 йәшендә

6) 1336 сәнәи һиҗриййә мөхәррәм 19 нда

7) 1918 сәнәи миладиййә үктәбр 14

8) мәдфүн».

Уң ягы (уеп язылган):

1) «Рахимәһүллааһү Тәгааләә

2) рахмәтән вәәсигаһ».

Сул ягы (уеп язылган): «Нәүвәраллааһү мәркадәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Шәех

2) мулла Билаледдин

3) Габиди Бохари,

4) 48 ел имамлык итеп,

5) 80 яшендә

6) һиҗри 1336 елның 19 мөхәррәмендә,

7) милади 1918 елның 14 октябрендә

8) җирләнде».

Уң ягы:

1) «Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте

2) белән рәхим кылсын».

Сул ягы: «Аллаһ аның каберен нурландырсын».

Таш үлчәмнәре: 122х42х30.

Югары зәвык белән ясалган әлеге мәһабәт таш бүгенге көндә зиратта бөтен килеш диярлек сакланып калган бердәнбер эпиграфик истәлек, чөнки ул нык материалдан, төгәлрәк әйткәндә, көрән граниттан эшләнгән.

Әлеге кабер иясе – мулла Билаледдин Габид улы –1841 елның 20 маенда Тәтеш өязе Олы Яңасала волосте (хәзерге Кама Тамагы районы) Иске Казиле (Суыксу) авылында дөньяга килгән. Ташындагы 80 яшь дигәне һиҗри ел исәбе белән билгеләнгән, һиҗри ел бераз кыскарак булганга күрә, вафат булганда милади ел исәбе белән аңа 77 яшь булган. Билаледдин хәзрәт Казандагы Хәммад Халиди мәдрәсәсендә гыйлем туплап, 1874 елның 3 маенда указ алганнан соң, Бишбалта бистәсе мәчетендә ярты гасырга якын, ягъни 1918 елга кадәр имам-хатыйб һәм мөдәррис вазыйфаларын башкарган. Билаледдин хәзрәтнең үзен дә, һичшиксез, чын җәдидче итеп санарга мөмкин. Рәсми документларда әлеге мулланың мәдрәсәсе кадими буларак күрсәтелсә дә, чынлыкта, анда җәдидчелек һәм дини реформаторлык рухында укытканнар. Кабер ташында ул «шәех» дип күрсәтелсә дә, Билаледдин хәзрәтнең суфичылык сектасы белән бернинди бәйләнеше юк, бу – олылау йөзеннән әйтелә торган сүз.

Бишбалта бистәсе зиратындагы иң борынгы ташлар, эшләнеше һәм палеографик билгеләре буенча, XIX гасыр урталарына карый, әмма аларның да, күбесенең текстларына зыян килгәнгә күрә, төгәл куелу вакытын ачыклап булмый. Датасы язылган ташлар арасында иң борынгысы 1910 елның апрель аена карый. Иң соңгы куелган кабер ташы 1933 елга карый, ул Гайшәбикә Сәгъди кызына һәм Рилия Харис кызына куелган. Бу елларда гамәлдә латин язуы булганга, әлеге ташъязма истәлек яртылаш гарәп, яртылаш латин графикасында язылган. Халык сөйләвенә караганда, Бишбалта зиратына XX йөзнең 50 нче елларында да мәетләрне җирләгәннәр, әмма Куйбышев сусаклагычы барлыкка килү аркасында, зиратның байтак өлешен су баса, һәм су астындагы эпиграфик истәлекләрнең әрәм булуына көенергә генә кала...

Югарыда искә алынган шәхескә куелган кабер ташыннан тыш, без тагын алты кешенең исемнәрен яки фамилияләрен ачыклый алдык.

Эш барышында Шакир исемле ташка язу остасы исеме ачыкланды. Аның ташбилгегә бик матур каллиграфик стиль белән уйган язуы, һичшиксез, игътибарга лаек. Бу останың мөэзин булганлыгын белдек, кызганычка каршы, бүтән мәгълүмат юк. Бәлки, әлеге шәхес Бишбалта бистәсе мәчетендә 1907 елдан башлап мөэзин вазыйфасын үтәгән Шакир Мирхәйдәров булгандыр дип уйлыйбыз.

Ни аяныч, халык тарафыннан ничә тапкырлар җыештырылса да, зират эче тулы чүпчар: пластик шешәләр, кәгазьләр, целлофан пакетлар, шәхси гигиена әйберләре, кулланылган шприцлар һ.б. Әйткәнебезчә, бөтен ташлар диярлек ватылган, җимерелгән, аударылган.

Шушы язманы укыганнан соң, Бишбалта татарлары, бәлки, зиратка барып, мәрхүмнәр рухына дога кылырлар, кабер ташларын тәртипкә китереп, зиратны җыештырып кайтырлар дигән өметтә калабыз.

Айдар ГАЙНЕТДИНОВ,
филология фәннәре кандидаты

---

1. Липаков Е.В., Афонина Е.В. История татарских кладбищ: Специальное издание к 1000-летию основания города Казани / Е.В. Липаков, Е.В. Афонина. — Казань, 2005. — С. 46.
2. Россия дәүләт борынгы актлар архивы: ф. 1354, тасв. 138, I бүлек, сак. бер. М 8.
3. Татарстан Республикасының Милли архивы: ф. 114, тасв. 1, сак. бер. 2029. — Б. 3—3 арты.
4. Липаков Е.В., Афонина Е.В. История татарских кладбищ: Специальное издание к 1000-летию основания города Казани / Е.В. Липаков, Е.В. Афонина. — Казань, 2005. — С. 46—47.
5. Шунда ук. — С. 48—49.
6. История Казани в документах и материалах. XIX век. Книга III: Управление, бюджет, хозяйство / Под ред. И.К. Загидуллина. — Казань: Главное архивное управление при КМ РТ, 2011. — С. 48.

Урта Уралда җәй

Свердловск өлкәсе Түбән Сырга районының Аракай авылындагы Туган якны өйрәнү музее фондында Урта Урал татарларының этнографиясен чагылдырган бик күп фотолар саклана. Төрлесе төрле чорларга караган әлеге ядкарьләрне чын мәгънәсендә «Вакыт көзгесе» дип атарга мөмкин.

Салават ГОБӘЕВ,
«Аракай авылы милли-мәдәни комплексы» директоры

Михнәтле юллар аша...

Фольклор экспедицияләрендә йөргәндә, халык авызыннан төрле-төрле гыйбрәтле тормыш мисаллары ишетергә туры килә. Аларның аеруча йөрәккә үтеп кергәннәрен хәтер дәфтәренә дә теркәлеп кала. Чистай районының Уракчы авылында яшәүче Факия Гыйлмран кызы Гомәрева (1935 елгы) сөйләгән хәлләр бүгенге көнгә кадәр исемә төшеп, күңелемне тынгысызлап тора. Җиңү бәйрәмен каршылаган көннәрдә, әлеге истәлекне журнал укучыларына да җиткерергә булдым.

– Минем әни бик авырлык белән үскән, – дип башлады Факия апа. – Әниләреннән 6 бала калганнар алар. Гаиләгә үги әни килеп, икенче никахтан тагын 6 бала туа. «Иртүк торып пич яга идем, казанга буем җитми иде, ашарга пешерә идем», – дип сөйли иде әни. Нужалы булды инде мәрхүм анам.

1939 елны бик күп гаиләләр бәхет эзләп читкә чыгып китте. Безнең Талкыш авыл советыннан чыгып киткәннәр белән без дә Казахстанның Кустанай өлкәсенә юл алдык. Безне бик яхшы каршы алдылар. Фатирларга урнаштырдылар. Саман ызбалар иде болар. Җир идән иде. Такта юк иде анда. Бәйрәмнәр җитә башласа, идәнне сыер тизәге белән чистарталар иде.

Менә шулай яңа җиргә ияләшеп кенә барганда, Бөек Ватан сугышы башланды. Әтине сугышка алдылар. 1942 елда кечкенә сеңелебез туды. Җиде бала булдык. Әти сугыштан хат язды: «Әминә, балаларны урыслар арасында калдырма, зинһар». Бабай белән әби дә шулай дип яза: «Әминә, зинһар, балаларны урыслар арасында калдырма, ничек булса да алып кайт». Сыерыбыз бар иде. Тана иде ул. Күршедәге марҗа әби әйтә: «Аня, – ди, – син бу тана белән кайта алмыйсың, – ди, – менә минем сыерымны җигеп кайт, минем сыерым бик яхшы йөри», – ди. «Манька» исемле кара сыер иде ул. Шул сыерны җигеп, 7 баланы тагып, юлга чыктык.

Ул юлда күргән михнәтләрне сөйләп бетерә торган түгел! Җәй челләсе иде. Сыерны савып сөтен эчәбез. Туктыйбыз. Хәер сорашып йөрибез. Бөтен әйберләребезне сатып бетердек, өсләребездә сәләмә генә. (Факия апа елап ала. – А.Б.) Сугыш вакыты бит, кая гына туктасак та, күпер төбендәме анда, төнлә киләләр дә, «монда йөрмәгез, хәзер монда солдатлар килә», дип куып җибәрәләр. Сыерны җигәбез дә тагын китәбез инде. Күкрәк баласы белән кечкенә энем арбада, ә без – әни, калган биш бала – арба артыннан кайтабыз. Урал тауларыннан, ташлар арасыннан берүзебез кайтабыз, юлны ничек белеп бетерергә кирәк! Таулар-ташлар арасыннан төшкәндә, ике апа (берсе 1927, икенчесе 1929 елгы иде), арба тәгәрәп китмәсен дип, сыерның тәртәсен тотып, аркалары белән терәп төшәләр иде. Менә шулай, бер ай дигәндә, каядыр кайтып туктадык без. Шунда берсе әнигә акыл биргән: «Син, – дигән, – ничек бу балаларың белән кайтып җитәсең, кечкенә балаларыңны ал да военкоматка бар. «Балаларымны калдырып китәм, теләсәгез нишләтегез, мин башка кайта алмыйм», дип әйт», – дигән. Әни Әлфия белән мине алып барган, дөрестән дә, аңа Норлатка кадәр кайтыр өчен поездга билет алырга язу биргәннәр. Билетларны алдык, ә менә 1927 елгы апага билет бирмиләр генә бит! И елыйбыз барыбыз да, и елыйбыз инде. Шунда проводникның күңеле нечкәрдеме инде, апаны тиз генә вагонга керттеләр дә, әйберләр астына тыгып куйдылар. Менә шулай Норлатка кайтып төштек. (Юлда безгә туган тиешле бер бабайны очраткан идек, сыер шулар белән калды. Алар без кайтып

бер ай үткәннән соң кайтып төштеләр.)

Ике олы апа, безне килеп алсыннар дип бабайга хәбәр бирү өчен, җәяүләп Чистайга таба чыгып киттеләр. Алар, мескеннәр, курка-курка урманнар аша кайтканнар. Аннары юлда ниндидер нефтьчеләр килеп чыгып, апаларны машиналарына утыртып, әпәйләр дә биргәннәр.

Бабай, безне каршыларга дип, ат белән Уракчыдан Норлатка чыгып киткән.

Ә бу вакытта Норлатта әнигә әтинең дусты, шуфир Хәсән абзый очраган. «Нишләп йөрисез, Әминә?» – дип сораган. Әни хәлләрне сөйләп биргән инде. Хәсән абый: «Мин дустымның балаларын монда калдырмыйм, давай, алып кайтам», – дип, безне машина белән төяп алып кайтты аннары.

Без бакча артыннан кайтып кергәндә, әби мескен бәрәңге бакчасында ие, кулын каш өстенә куеп карап тора ие. «Әллә, балакайларым, сез кайтасыз инде», – дип каршы алды әби.

Бабай, мескен, Норлатка барып җиткән. Анда кеше булмагачтын, кайтканда авыл саен кереп: «7 балалы хатынны күрмәдегезме? 7 балалы хатынны күрмәдегезме?» – дип сорап йөргән. Озак вакыттан соң гына кайтып керде бабай.

Аллага шөкер, исән-имин кайтып җиттек шулай. Апалар бөтенесе эшкә тотындылар инде, бабай белән бергә әпәй чабарга йөрделәр. Әнине конюх итеп куйдылар. Хәзер без барлыгы 10 җан булдык. Бабай белән әбинең ашарга әпәйләре дә бар иде, бәрәңгеләре дә бар иде. Ашаттылар-эчерттеләр. Шулай иттереп, шушында төпләнеп, шушында яшәп калдык, Аллага шөкер!

Әни бик нужаланып үстерде инде, мескенкәй генәм. Бик авырлык белән яшәдек, Аллага шөкер! Әни безгә әйтә иде: «Эшләгез, эшләп кеше үлми; эшләп кеше үлсә, мин үлгән булыр идем», – дияр иде. Көндез атлар карады, төне буе кешегә киез итек асты салды, йон эрләде, безне үстерәсе бар бит... 97 яшендә бакый дөньяга күчте әниебез.

Әти кайтмады, сугышта үлде. Безнең кайтканыбызны ишетеп үлде. Бик шатланды инде, безне кайтарып калдырганга. Әнигә рәхмәт әйтеп хатлар язды.

Шундый хәлләр үтте баштан, Аллага шөкер!

Алсу БАТТАЛОВА,
филология фәннәре кандидаты,
Республика традицион мәдәниятне
үстерү үзәгенең фәнни хезмәткәре

Юл-сәфәр юрамышлары

Юлга чыгучы өйдә үзенең сыныгын калдырса – тиз әйләнеп кайта. Өйдә бу сыныкны саклап торырга тиешләр. Моның нигезендә ризык тартуга ышану ята.

Юлга чыкканда берәр кирәкле, бик күптәнге әйбереңне онытсаң – юлың уңмаячак.

Юлга чыгар алдыннан эт уласа – уңышлы юлга.

Юлга чыгар алдыннан кемдер өй җыештырып йөри башласа, идән себерсә, тавыксавыт шылтыратса – ниятеңне кичектереп тор. Юл хәвефле булачак.

Юлга чыгар алдыннан өйдә бала еласа – сәфәреңне кичектереп тор. Бала тынычлангач кына кузгал.

Юлга чыкканда юл өстендә яткан себеркене атлап чыгарга ярамый, югыйсә афәткә юлыгырсың. Кайбер якларда: көянтәне атлап чыгарга ярамый.

Юлга кузгалганда өй каршындагы агачка тотынып юл догаларын укы – юлың уңачак.

Юлга чыгар алдыннан өй артындагы артыш, миләш, балан, карама кебек куакларның берәр ботагын яисә яфрагын өзеп сал – юлыңда зәхмәт кагылмас.

Юлга чыгар алдыннан тәрәзә өлгеләрен юсаң – юлың уңар, исән-сау йөреп кайтырсың.

Юлга чыгучыга тегәрҗеп бирсәң – юлы кыска була.

Юлга чыгучыга хатыны үз күлмәгеннән җеп алып бирсә – юлчы исән-сау әйләнеп кайтачак.

Юлга чыгучы үбеп китсә – исән-сау кайтмавы бар. Шуңа күрә борынгылар озатышканда үбешергә кушмаганнар.

Юлга чыгучы ир бишектәге баласын өч мәртәбә әйләнеп чыкса – исән-сау йөреп кайтачак.

Юлга чыгучы эткә ризык бирсә – юлы уңачак.

Юлга чыгучыга чигүле янчык бирсәң – серен кешегә әйтмәячәк.

Юлда таш, кәс кисәкләренә типкәләп барырга ярамый – юлың уңмый, бәла сорыйсың.

Чыганак: Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар.. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 262-263 битләр.

Мәдинә МАЛИКОВА

КАР СУЛАРЫ

Ибраһим абый Газинның
якты истәлегенә багышлыйм

(Хикәя кыскартып бирелә)

Мин кар суына барам. Күгелҗем сукмак буйлап тау арасына менәм. Сукмак тар, аякларны туп-туры басарга кирәк, юкса батасың. Элекке заманнарда авыл кызлары эзләренең җепкә тезелгәндәй тигез булуы белән мактанганнар. Ә без үстек, шәһәргә киттек, аннан аяк башларын ике якка каратып йөрергә өйрәнеп кайттык.

Мин балачактагыча туры басарга тырышам. Сукмак читендә кар өсте челтәрләнгән, ул кыш көнендәге кебек күзләрне чагылдырмый, асылташлар сипкәндәй җемелдәми. Кар да картая икән. Дөрес, биредә ул шәһәрдәге кебек каралмаган, пычранмаган, тик тоныкланган, басылган, авырайган. Уйсу җирдә ул әле нык ята, ләкин яз кояшы аны тау түбәсеннән куган инде, ул, күкселләнеп торган текә тау битенә өр-яңа җыерчыклар салып, агып төшкән. (...)

Язын чишмә юлларына ташу төшә, Минзәлә елгасы яман болгана иде. Әнкәем суны тау арасыннан, кар астыннан алып кайта иде. Кар суы, чишмә суы кебек тәмле булмаса да, салкын, чиста була, керне ныграк агарта, чәчне әйбәтрәк йомшарта иде. Шуңа күрә мин дә бүген кар суына барам. Беренче карашка кар бик нык ята әле, беркайда да чүмечләп-чиләкләп алырлык су күренми. Ләкин бу өстән караганда гына шулай. Менә мин балачактан билгеле урында, кар астыннан почмагы гына күренеп торган зур соры таш янында туктыйм. Таш тирәли кар эреп, уелып төшкән. Сукмак кырыендагы карны чүмеч белән чумырып алам. Чумырган саен, чокыр тирәнәйгән саен, кар авырая, чылана бара. Ниһаять, чокыр төбендә үлән күренә. Кар астыннан сиздермичә генә су агып ята икән. Әнә ул узган елгы корыган үлән сабакларын да, яшел чирәмне дә үз юлы уңаена каратып, тарап куйган. Кар суының саф җиле битемне иркәләп, сыйпап үткәндәй була. Мин тагын бер саерак чокыр казыйм. Аңа саркып, сабый күз яшедәй чиста су җыела. Үземне күрергә теләгәндәй, кар өстенә иеләм, су агышын ишетергә тырышып, тынып калам. Әйе, мин чыннан да үземне күргәндәй булам, тик күп юллар үтеп, гомер уртасына җиткән кешене түгел, унөч яшьлек, чандыр кызны күрәм; мин ишетәм, ләкин су челтерәвен түгел, вак ташлар өстеннән сикереп аккан чишмә кебек саф, яңгыравыклы тавыш ишеткәндәй булам:

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул...

Рафис тавышы бу. Әллә соң аның җыры тау өстендә сакланды микән дә, һәр яз саен, кар суларына ияреп, авылга төшә микән?

Иделне безнең беребезнең дә күргәне юк иде. (...)

Мин, алтынчы класста укучы, тамагы ипигә туймаган арык кыз, унөч яшемдә шушы Идел турындагы җырны һәм аны җырлаган малайны яраттым.

Кай җире матур иде ул малайның, дип сорасалар, аңлатып бирә алмас идем, мөгаен: түгәрәк йөз, кара чәч, буйга кечерәк кенә. Тик кара күзләрендә үзәкләргә үтә торган моңсагыш бар иде аның. Рафис ятим малай иде. Әтисе сугышта үлгән, әнисе улын әбисенә китереп куйган да үзе читкә китеп барган... Малай җиде классны укып бетерсен, ә мин шәһәргә урнашыйм, ныгытып төпләнгәч, кайтып алырмын, дигән. Китереп куйган, дим, чөнки Рафис башка авылда туып-үскән бала иде.

Безнең арада ярым ятимнәр күп, ә менә тулы ятим, өстәвенә ят авылда яшәргә мәҗбүр бала – ул берүзе иде. Авыл малайлары аны

чит күрделәр, араларына кертмәскә тырыштылар. Бәлки, шуңа күрәдер, аның күз күрмәгән Идел турындагы безнең өчен яңа җыры бәгырьләрне телгәләрлек моңлы иде.

Аның тау өстендә мал саклаганда җырлаганын мин онытылып тыңлый идем, аның язмышы белән үз язмышым арасында уртаклык тоя идем.

Дөрес, мин ятим түгел, атам-анам исәнсау, ләкин урамда, бала-чага арасында үземне ялгыз хис итә идем, чөнки гаиләдә бердәнбер бала идем. (...)

Кайчан ярата башладым мин Рафисны? Әйтә алмыйм. Бу хис минем күңелемдә, кар астыннан аккан су кебек, сиздермичә, күренмичә уянды. Кар суының беренче тамчысы кайчан, кайда хасил булганын кем генә әйтә алыр икән? (...)

Ул җиденче класста укый, ә мин алтынчыда. Без бер-беребездән китап-дәфтәр алыша башладык. Алар арасында кыска гына язулар да була иде. (...)

Яңа ел җитеп килә иде. Гадәттәгечә, озын тәнәфестә уеннар оештырдык. Уртада алмаш-тилмәш бииләр, ә калганнар түгәрәк ясап, карап тора. Түгәрәк кечкенә, балалар берничә рәт баскан. Шунда Рафис минем артка килеп басты, биючеләрне күрергә теләгәндәй, җилкәм аша үрелеп карады һәм, тирә-яктагыларга сиздермичә генә, кесәмә нидер салды. Мин кулым белән капшап карыйм – салкын, каты әйбер. Алып карарга җай юк – кем дә булса күрер, дип куркам. Класска кергәч, бигрәк тә сак булырга кирәк: янымда, бит очларын чокырайтып, зәңгәр күзләрен чекрәйтеп, усал малай – Нур утыра, берәр нәрсә сизсә, бөтен мәктәпкә фаш итәсен көт тә тор.

Дәресләр беткәнен ничек газапланып көткәнемне, аннары кызлар белән авыл урамы буйлап кайтканымны тәфсилләп сөйләп тормыйм.

Ниһаять, абзарга кереп, калтыранган кулларым белән бүләкне кесәдән чыгардым. Ул – тар гына кызыл каеш булып чыкты. Андый бил каешларының модага кереп кенә барган чагы, аларны табу кыен иде. Рафисның әнисе посылка җибәргән булгандыр. Ул елларда читтәге кешеләр авыл җирендәге туганнарына шундый вак-төяк әйбер-кара җибәргәлиләр иде. Аларны азык-төлеккә алмаштырып була иде.

Гадәт буенча мин, егетнең бүләгенә каршы бүләк итеп, чиккән кульяулык бирергә тиеш идем. Бик пөхтә итеп, аллы-гөлле бизәкләр төшереп чиккән булыр идем мин ул кульяулыкны! Дөньяда иң матур кульяулык булыр иде ул! Ләкин, күпме генә хыялланcам да, мин бу эшне башкара алмадым. Чөнки минем ситсым да, чигү җепләрем дә юк иде.

Мин ситсы белән җеп табу җаен эзләп йөргән арада, яз җитте. Ул елны кар сулары акканын тәрәзәдән генә карап яттым, чөнки бик озак бизгәк белән авырдым. Тау өстенә малларны миннән башка гына менгерделәр балалар, миннән башка гына, узган елгы коры-сарыны җыеп, бәрәңге пешереп ашадылар. (...)

Кичкә таба ишектән Рафис килеп кергәч, минем гаҗәпләнүемне, сөенүемне сөйләпаңлатып бетерерлек булмады. Рафис, гомер буе бусагабызны атламаган Рафис, минем уйларымнан чыкмаган Рафис көпә-көндез килде дә керде бит. Дөрес, ул берүзе түгел, күршебездә яшәүче ерак кардәше Наил абый белән иде.

Әнкәй белән миңа кычкырып сәлам биргәч, Наил абый:

– Зәйтүнә, синең әдәбият дәреслегең бармы? – дип сорады.

– Бар.

Тавышым бик хәлсез чыкты. Мин нәкъ ишеккә каршы, түрдәге сәкедә әнкәемнең эре шакмаклы палас-шәлен ябынып ята идем. Рафис кергәндә, түшәк өстендә аунап ятуыма бик гарьләндем.

Наил абый күрше авыл мәктәбендә тугызынчыда укый иде.

Кече яктан сәерсенеп карап торган әнкәйгә ул алтынчы класс дәреслегенең үзенә нигә кирәк булганлыгын озак итеп аңлатырга кереште. Мин, урынымнан кузгалып, түшәм астындагы киштәгә үрелдем. Хәтеремдә: ябыклыгымнан, хәлсезлегемнән, аякларымның аклыгыннан кы-енсындым. Сәкедән төшеп, күзләрем белән идән ярыгына текәлгән хәлдә, китапны Наил абыйга суздым. Ләкин, кире менеп китәргә өлгермәдем, Наил абый дәреслекне актаргалады да:

– Ә-ә, безгә кирәк тема юк икән монда, – дип кире бирде.

Мин сәкегә басып киштәгә үрелгән идем, китап арасыннан бер кәгазь очы килеп чыкмасынмы! Аптырап, Наил абыйга карыйм, ә ул миңа ым кага: «Яшер», янәсе. Кәгазьне бит араларына эчкәрәк төртеп, китапны киштәгә куйдым. Аллага шөкер, казан астына иелгән әнкәй аны-моны сизмәде. Ул суга киткәч тә, китапны кире алдым. Аннан хат килеп чыкты. Хатның беренче юлы «Зәйтүнә!» ялтырап тор-

ган нечкә бакыр чыбыктан үрелеп, кәгазьгә беркетелгән иде. Дөньяда минекеннән дә матур исем юклыгына мин шунда ышандым. Ул алтын белән язылгандай балкып тора иде: «Зәйтүнә!» Рафис аны шундый оста, шундый тигез итеп үргән иде! Аннары ул минем белән очрашып сөйләшәсе килүе турында язган: «Кич белән турыгыздан җырлап үтәрмен, чык әле»,– дигән иде.

Бәхеткә каршы, әткәй өйдә юк иде. Бик иртә торырга күнеккән әнкәй яту белән йокыга китте. Ә мин, йөрәгем тибүе аша җыр тавышын еректан ук ишетергә теләп, тын да алмыйча ятам.

Менә түбән очтан Рафисның җырлап килгәне ишетелде:

Идел өсләрендә йөзгән
Аккошларга тиң бит ул...

Аның җырын ишетеп, авыл халкы, күңелен моң-зар басканга шулай җырлый инде бу бала, дип уйлагандыр, бәлки. Рафисның җыр белән миңа мәхәббәтен аңлатканын, аккошларга мине тиңләгәнен без икәү генә белә идек шул.

Мин җәһәт кенә торып ишек янына бардым. Шыпырт кына чыгып китәргә кирәк иде. Әмма кул белән кагылуга, ишек ыңгырашып куйды, бу тавыш тынлыкны ярып, йөрәгемне көйдереп узды. «Баш бетте!» – дидем мин. Бераз торгач, әнкәй урыныннан кузгалмагач, ишекне ныграк эттем – ул тагын да яманрак шыгырдады. Тагын шым булдым. Бераздан батырлыгымны җыеп, каһәр суккан ишеккә ныклап ук төрткән идем – әнкәйнең куркынган тавышы ишетелде:

– Кем бар анда?

Мин телсез-өнсез калдым. Үземне зур җинаять өстендә тотылгандай хис иттем.

– Кем ул? Зәйтүнә, синме әллә?

– Мин...

– Нишлисең анда?

Мин еламсырап:

– Су эчәсем килгән ие, – дидем.

– Ә-ә, – диде әнкәй, тынычланып.

Ишекне каерып ачтым да өйалдына чыктым. Аның шыгырдавына шулхәтле күнегелгән, шул көнгәчә сизмәгәнмен дә икән.

Кинәт тамагым кипкәнен тоеп, чүмеч белән салкын чишмә суы алып эчтем. Рафис кире югары очтан түбән очка таба җырлап узды:

Караңгы төн, томанлы көн,
Без аерылган төн бит ул...

Йөрәгемнең ялкынын бер чүмеч су гына түгел, киң Идел дә сүндерә алмас иде кебек.

Рафис тавышы торган саен ерагайды, мин кире өйгә кердем. Гомеремдә беренче тапкыр егет белән күзгә-күз очрашырга тырышуым шулай тәмамланды.

Озакламыйча мин савыгып җиттем, әткәйнең солдат шинеленнән бозып теккән бишмәтемне киеп, тауга сыер сакларга мендем.

Кич иде, тауда әле бала-чага берәнсәрән генә. Өйдә озак утырганга, саф тау һавасыннан, җир исеннән башым әйләнеп тора иде.

Шунда миңа партадашым Нур бәйләнде бит. Әле төртә, әле бишмәт җиңемнән тарта, мыскыллы сүзләр әйтә, көлә. Башка чакта минем моңа әллә ни исем китмәс иде, читкәрәк тайпылып, дәшмирәк торсам, үзе үк мине онытыр иде әле. Ләкин Рафис та шунда булганга, мин бик гарьләндем. Хәер, Нур үзе дә мине Рафис алдында юри кимсетә, чөнки безнең мәхәббәтебез малай-шалай өчен сер түгел иде инде. Нурны этеп җибәрергә, аның сүзләренә тагын да ачырак итеп җавап бирергә батырлыгым да, көчем дә җитмәде.

Шулчак Рафис егетләрчә нык басып безнең янга килде дә, кара күзләрен утлы күмердәй яндырып, үзеннән шактый калку Нурның якасына ябышты, бөтен тауны яңгыратып, ачулы тавыш белән:

– Син ник аны «обижаться» итәсең? – диде.

Әйе, «обижать» түгел, «обижаться» диде. Чит авыл малае булганга, ул безгә ят, сәер сүзләр ычкындыргалый иде. Бала-чага аның бу сүзеннән туйганчы көлде. Ләкин Нур көлмәде, ярсыган малай белән сугышу хәлсез кызны кыерсытуга караганда күчне күбрәк сорый иде шул.

Ул чакта тауга Нурның дуслары менеп җитмәгән иде әле. Соңрак, әлбәттә, Рафистан үчен алгандыр. Әмма шуннан соң ул миңа тора салып бәйләнүдән туктады. Шулай итеп, минем дә яклаучым булды. Абыем кебек якын итүче, кирәк икән, минем өчен утка керүче кешем булды. (...)

Рафисның әнисе янына китәр чагы җитеп килә иде.

Мин әнкәйгә йон оек бәйләргә ниятем барын әйттем. Үзебезнең сарыкның язгы йонын яздым, бик нечкә итеп җеп эрләдем. Аннары күрше авылдагы кардәшләребезгә кунакка барып, ике көн эчендә бер кием перчатка бәйләдем. Бөтен осталыгымны җигеп, баш бармакча төпләренә сырлар куеп бәйләдем

мин аларны. Кунакта чакта юып киптерергә генә вакыт җитмәде.

Өйгә кайткач, мин күрше кызы Ләләгә серемне чишәргә мәҗбүр булдым, ул перчаткаларны юарга ризалык бирде. (...)

Ләләнең әнисе Хөснихатима түти кызының бер самавыр су кайнатып, сабын күбеге күпертеп, перчатка юганын күргән. Ләләгә ни, ул әнисенә, Зәйтүнә перчаткасы бу, дип әйткән дә биргән.

– Нигә үзе юмый соң ул? – дип сораган Хөснихатима түти.

Ләлә аңа рәтле җавап бирә алмаган.

Ул перчаткаларны кадерләп кенә, чормага элеп киптергән. Перчаткалар кершәндәй ак, каз мамыгыдай йомшак һәм җылы иде.

Мин аларны кәгазьгә төрдем дә бишмәтемнең куен кесәсенә тыктым. Кич җылы, күлмәкчән дә туңмас идем, ләкин бишмәт кимәсәм, перчаткаларны яшерер урыным булмас иде.

Без Рафис белән очрашу турында алдан килешеп куя алмадык. Ләкин бу – аның авылда соңгы киче, иртәгесен ул китәчәк иде. Кичке уенда да без бер-беребезгә якын килә алмадык, аннан соң мин кызлар белән югары очка, ул малайлар белән түбән очка кайтып китте.

Мин иптәшләрем белән хушлашып калдым, тик өйгә кермәдем, җилкапка араталарына ябышып, аны көттем. Караңгыда, тынлыкта берүзем озак көттем. Ул, әлбәттә, килде...

Без бик аз сөйләштек. Хат алышырга да вәгъдә бирешмәдек, хәтта ул бәхеттән дә без мәхрүм идек, чөнки авылның хат ташучысы безнең хатларны әткәйгә йә әнкәйгә бирәчәк иде.

Без өй буендагы эскәмиядә янәшә утырып тордык. Мин перчаткаларны бүләк итәргә һич кенә дә җай таба алмадым. Яланаягым белән каты җиргә караңгыда күренмәс сызыклар сызам, кымшанган саен кесәмдәге кәгазь кыштырдый. Моны ишетеп Рафис:

– Ни кыштырдый ул кесәңдә? – дип сорады.

Мин перчаткаларга кер кунудан куркып, аларны кәгазьгә төреп тыккан идем.

Җәй уртасында кешегә йон перчатка бүләк итү дә, аларны кәгазьгә төрүем дә ничектер бик уңайсыз, көлке булып тоелды.

Мин, беткән баш беткән, дип, суга чумгандай тәвәккәлләп, тирән итеп сулыш алдым да бүләгемне кесәдән чыгардым.

– Бу сиңа...

Рафис өенә кайтуга, кичтән тутырып куйган чемоданын ачкан, әбисеннән яшереп, перчаткаларны оекбаш эченә үк салган.

Ләкин йокыга сак карчык оныгының чемодан актарганын сизеп яткан, таң ату белән торып, Рафис сабыйларча изрәп йоклаган арада, аның әйберләрен тентегән, перчаткаларны күреп, бик сөенгән, кызганычка каршы, үзе генә сөенеп калмаган.

– Менә минем улыма кызлар перчатка бүләк иткән! – дип, күршесенә йөгереп кергән. Ә аларда Ләләнең әнисе Хөснихатима түти утыра икән...

Шулай итеп, минем Рафиска бүләк бирүем бөтен авылга фаш булды.

Рафисның машинага утырып, тимер юл станциясенә китүен күрү, аны озатып калу бәхетләре миңа тимәде. Җәрәхәтле йөрәгемә тоз салып, авыл малайлары артымнан:

– Пирчәткә... пирчәткә... пирчәткәнең бер бармагы поездга кысылып өзелгән бит, – дип кала торган булдылар. Ачыктан-ачык мыскыллададылар, чөнки яклаучым киткән иде шул инде. (...)

Ул чакта безнең авыл аша машиналар сирәк үтә иде. Гүләгән тавыш ишетелгән саен, миндә бу машинага утырып Рафис кайтмадымы икән, дигән тиле өмет кабына иде. Ул кайтмады.

Бер елдан мин үзем дә авылыбыздан чыгып киттем. Мин кояш баешына юл тоттым, ә Рафис кояш чыгышына киткән иде. Шулай итеп, безгә очрашулар насыйп булмады.

Бик күп еллардан соң гына мин шуны белдем: Рафис поездга билет ала алмаган икән. Ул төннәрен вагон ишегенең тоткасына ябышып барган. Җәй булса да, төннәр салкынча, вагоннар һаваны ерып, җилләп бара, тимер тоткалар боздай суына. Әмма Рафисның куллары туңмаган, чөнки мин бүләк иткән, каз мамыгыдай йомшак һәм җылы перчаткаларны кигән булган ул...

Минем күңелемдә күп кышларның карлары ята. Ул тыныч, үзгәрешсез, хәрәкәтсез кебек. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Ул карлар астыннан сиздермичә-күренмичә генә, гомерем язының ташкын сулары ага...

Мин чиләгемә кар суы тутырам. Саф, чиста су өстендә эреп бетмәгән шикәр кебек кар йөзә. Атлаган саен чүмеч чиләккә бәрелеп чыңлап куя.

Чиләгемдә кар суын, күңелемдә Рафис җырын, беренче мәхәббәтемнең онытылмас истәлеген алып кайтам.

«Тукай Кырлайда». В.И. Куделькин.
Татарстан Республикасының Сынлы сәнгать дәүләт музеенда саклана.

Җыр ачадыр күңелне...

(Шәриф Каюмов истәлекләре)*

1902 нче ел октябрь числосы булырга кирәк, әти безне Җаек шәһәре мәдрәсәләренең берсенә укырга бирергә иртеп китте. Бу мәдрәсә Габдулла Тукай укый торган Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсе иде.

Бу вакытта Тукай мәдрәсә шәкертләре арасында зур шәкерт булып, ул дәресне хәлфәләрдән укымый, хәзрәттән укый иде.

Хәзрәттән дәрес алучылар арасында Тукай, аның шәриге Мортаза Шәрипов, безнең хәлфәбез Гомәр Хөсәенев, Мыек Сафа, Урыс Йосыф, Зиннәт, Фәсах, Тукай белән җырлаучы Вәли, казакълардан Урынгали, Иргали һәм башкалар укыйлар иде. Хәзрәт дәресе вакытында, кайвакыт зур бәхәсләр чыга иде. Хәлфәләр һәм зур шәкертләр арасында хәзрәт

тарафыннан куелган чуалчык мәсьәләләрне чишү яки дәресне йомгаклау Габдулла Тукай, Г. Хөсәеневләргә туры килә иде. Тукаев бу вакыт мәдрәсәдә генә укымыйча, учитель Әхмәтша школасына русча укырга да йөри, алар Урыс Йосыф белән бергә укыйлар. Ул вакыт безнең мәдрәсәдә «Мөхәммәдия» уку модада иде. Тукай дәрестән бушаган вакытларда, мәдрәсә идәне буйлап йөреп, көйләп, «Мөхәммәдия» укырга ярата, безнең хәлфә Хөсәенев, Тукайга кушылып, кайвакыт Вәли белән шулай бергә җырлап йөриләр иде. Тукай ашханәгә юынырга төшкән вакытларда, ашханә буена җырлап йөри, биредә ул «Мөхәммәдия» укымый, ә татарның милли көйләрен: «Кара урман», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү» көйләрен җырлый иде. Атна саен була торган кичәләрдә, хәлфәләр соравы буенча, Тукай күп вакыт кыска көйләрне яратып җырлый иде. Тукай иске вакытта укыла торган «Йосыф китабы» кебек китапларны җырлап тәнкыйть итә. Ул вакытта ук сүзлекләрдән файдалана, аның тәбәнәк өстәле өстендә калын-калын рәсемле сүзлекләр тора иде. Мәсәлән, минем бик яхшы хәтеремдә: бервакыт безнең мәдрәсәгә атна саен кереп йөри торган Шәкүр хәлфә килә. Ул кеше белән күп сөйләшми, утырып Коръән укый башлый. Шәкүр хәлфә гакылга саеккан иде. Ул кереп утыру белән, Тукай аңарга калын, рәсемле сүзлек бирә. Шәкүр шатланып ала. Укырга теләгән китаптан ниндидер рәсем килеп чыга, ул ачуланып китапны мәктәпнең икенче башына кадәр ыргыта да, «кяфер син, динсез син» дип, Тукайга ачулы сүзләр әйтеп чыгып китә. Башка шәкертләр шаркылдашып көлә башлыйлар, мәдрәсә шау-гөр килә.

* * *

1904–1905 нче елларда Төркиядәнме, каяндыр Мөхәммәтвәли исемле бер төрек килде. Төрек Вәли Тукайга караганда гәүдәгә бераз зуррак, ләкин нык, йомры, таза егет иде. Аңарга мәдрәсәдә «төрек Вәли» дип йөриләр иде.

Тукай белән төрек Вәли бик тиз дуслашып киттеләр. Тукайның төрек телендә сөйләшә белүе һәм фикердә бер булулары аларны якынлаштырды диеп уйлыйм.

Минем исемдә калганча, төрек Вәли Төркиядән ниндидер бер сәбәп белән качыпмы, сөрелепме килгән егет булырга кирәк, чөнки аның турында шундый сүзләр сөйләнә иде.

Тукай ара-тирә төрек Вәли белән төрекчә җырлыйлар иде, ашханәгә бергә төшеп, бергә юынып, бергә ашап-эчеп тордылар. Ләкин төрек Вәли озак тормады, бер кышмы, шул тирә генә булды. Шуннан соң каядыр китте.

Бу вакыт Тукай янына Габдулла Кариев та бик еш килеп йөри, Тукай һәм Кариев яхшы дуслар иде.

* * *

Габдулла Тукай дүрт ай балалар укытты. Аның балалар укытуы турында бер истәлек тә юк. 1904 нче еллар булырга кирәк, безнең хәлфә Гомәр Хөсәенев кызыл мал белән сәүдә итүче Вәлиулла Апаковка ялланып хаҗга китә. Гомәр хәлфәдә укучы егерме бишләп баланы зур шәкертләр бүлеп алалар. Шул вакыт унлап баланы Габдулла укыта.

Ул тиз вакыт эчендә укуга үзгәлек кертә. Мәдрәсәдә парталар булмаса да, беренче мәртәбә кара такта шул ук Гомәр хәлфә утыра торган тәбәнәк аяклы өстәл янына асып куела. Тукайдан күреп, башкалар да такта ясаталар. Тукай балаларны укытканда, бигрәк тә язарга, телгә, хисапка игътибар итә һәм күбрәк яздыра иде.

* * *

Язгы су ташуы вакытында Урал, Сакмар, Чаган сулары бергә кушылалар, һәр елны Чаган безнең мәдрәсәнең ишек алдына килеп җитеп, ике-өч чакрымга җәелә иде.

Тукай, Гомәр хәлфә, Тукайның шәриге Мортаза Шәрипов, Исмәгыйль Шәрипов, Тукайның җырчы иптәше Вәли, төрек Вәли, Фәсах һәм башкалар бергә җыелышып, сигезтугыз кеше, көймә белән Чаган елгасы буйлап, Урал елгасы кушылган җиргә пикникка чыгалар иде. Моның өчен пәнҗешәмбе көн кич белән сәгатьче Камалиның каегын (көймәсен) сорап, тагы да кемнәндер икенче көймә хәзерләп, иртәгесен шул ике көймәне янәшә куеп, көймә өстенә такта тезеп, киез җәеп, барганда самовар куеп, самовар морҗасыннан төтен чыгарып, кайсы ишкәк ишеп, кайсы койрык тотып, самоварчы малай самовар янына утырып, кәеф-сафа корып бара идек. Ул вакытның мәдрәсәләрендә куллана торган музыка коралы – кубыз Тукайның кесәсендә була. Мәдрәсә янынннан көймә кузгалып киткәч тә, Тукай белән Гомәр

хәлфә әкрен генә «Мөхәммәдия» китабыннан сыздырып җибәрәләр:

Чөн адәм җәннәтә керди,
Юҗә гыйззәтләрә ирди, –

дип башлап китәләр. Шәһәрдән ераграк киткәч, «Мөхәммәдия» көе тукталып, Тукай белән Вәли татар халык көйләрен җырлый башлыйлар, җырлау тиешле урынга барып җиткәнчегә кадәр дәвам итә. Тукай күп вакыт көлке җырлар да җырлап көлдерә иде:

Эскрипкәм тари-тари,
Тари булса да ярый;
Безгә кызлар ләкмәс инде,
Карчык булса да ярый, –

дип куя. Күп вакыт Тукай түбәндәге җырны сөеп җырлый иде:

Челтәрле күперләре сиксән такта,
Кемнәр йөри иканләү,
герерай-герерай, һай, бу чакта.
Сау бул да сау бул дигән чакта,
Сулкылдап ук елыйдыр,
герерай-герерай, һай, кочакта.

Шулай ук Тукай, көлдерү, күңел күтәрү өчен булырга кирәк, «Галимҗан кызы бәете»н әйтә иде. Көймә яр кырыена туктагач та, Тукай урын сайлый, кем беләндер, хәтерләмим, ләкин озаграк торалар. Алар кайтканда, ут ягылып, самовар куелып, ашъяулык җәелеп беткән була. Тукай бу урынны ошатмый: «Әйдәгез, егетләр, без бик матурын таптык, анда барыйк, бу ләззәтсез урын, тиречеләр исе килә», – ди ул. Барыбыз да күтәрелеп, Тукай сайлаган урынга күчәбез. Дөрестән дә, Тукай сайлаган урын – бик матур күренеш. Сул яктан Урал елгасы тулы казан ясап, борылып-борылып, гөрләп, сөйләшеп ага, икенче яктан Урал суының кабыргасына Чаган елгасы килеп кушыла. Зур тирәк, тигез, югары, хәтфә кебек ямь-яшел чирәм. Шул вакыт Тукай сайлаган урынның кыйммәтен, манзарасын аңлата да, кесәсеннән агач шакмакка бәйләнгән, җиз телле кубызны алып, тигез итеп киселгән тирәк төбенә утырып, уйный башлый. Чыннан да, Тукай кубызны матур итеп уйный иде. Башкорт халкының курай тавышларын чыгара, Урал елгасының агымына, сирәк кенә ак мамык тавы кебек агарып торган болытларга карап уйный. Самовар өлгерә, аш пешә, ашъяулык җәелә, көнбагыш, чикләвек, чәчәкле конфет ашъяулык әйләнәсенә сибелә, әңгәмә, җыр, уенкөлке белән чәй эчелә.

Тукай күп мәртәбә шул ук җырларны җырлый иде:

Минем сөеп җиккән атым
Кара белән тимеркүк;
Сагынганда айга карыйм,
Ай да ялгыз минем күк.
Мин сандугач булыр идем,
Кунар тирәгем булса;
Тал тибрәтеп сайрар идем,
Күземә яшьләр тулса.

Чәйдән соң төрле уеннар башлана: куышу, йөгерешү, сикерешүләр китә. Ләкин Тукай җептән сикергән вакытта, аның аягы җепкә эләгә иде, яки сикерә торган җепкә килеп җиткәч, җепнең астыннан чыгып китә; яисә җепкә килеп җиткәч, сикергән була да, авызына сулыш тутырып пуф итеп, төрле кыланышлар белән көлдерә иде.

Мондый пикник җәенә бер-ике мәртәбә була иде. (...)

* * *

Камил, Мисырдан кайткач, атасы Мотыйгулла хәзрәт урынына мәдрәсәдә дәрес бирә башлый. Ул озын буйлы, аягында заграничный сары штиблет, өстә яшел чапан, чапан астыннан карлыгач койрыклы фрак, ак жилет, башында кызыл фәс; үзен гадәттән тыш күтәренке тотуы, кирәксез урында көлүе, принципсызлыгы, мөәзин урынына манарага менеп, гадәттән тыш кычкырып азан әйтүе, патша думасына сайлау вакытында җанытәне белән депутат булып сайланырга йөрүе, япь-яшь булуына карамастан, ике хатын алуы, шәһәр байгуралары каршында ресторсннарда җырлап йөрүе һәм башка шундый кыланышлары Тукайга ошамый, яратмый гына түгел, ул чыраен сыта, җирәнә иде. Уральск шәһәрендә думага сайлау кампаниясендә татар байларының җыелышы Шәрык клубында була иде. Тукай бу вакытта Шәрык клубында бер бүлмәдә тора. Мин бу вакытта Г. Әхмәтҗанов байда торам. Миңа ниндидер бер йомыш белән клубка барырга туры килде. Тукай кара кәләпүш киеп, үзе тора торган бүлмәдән чыгып йөри, клубның сәхнәсе өстендә, яшел сукно япкан зур өстәл тирәсендә җыелып утырган байгураларның талашканын карый, ә Камил Мотыйгый кулын селтәп, әллә нәрсә сөйли иде.

Тукай берникадәр Мотыйгулла хәзрәт йортында бер бүлмәдә торды. Камилнең типографиясе дә шул ук йортта иде. Тукай ялгызлыкны ратканлыктан, Камилләр өендә тору аның табигатенә авыр булгандыр,

чөнки аларга килем-китем, чыр-чу, бала-чага, бигрәк тә хатын-кыз Тукайның изелүенә сәбәп була. Бу вакытта Тукай чиктән тыш күп эшли. Типография таш идәнле, караңгы, бик тәбәнәк, һавасы юеш, көн якта тәрәзә юк. Әнә шул шартлар эчендә, беренче буларак, хезмәт дәверен кичерә. Тукайны мәдрәсә һавасыннан да начар булган таш стена кочаклап ала. Тукайның беренче туберкулез палочкалары да шул вакыттан башлануына һич шик юк. Камил Мотыйгый болай акланмакчы була: «Тукай үзе бу турыда бернәрсә дә язмый иде», – ди. Чыннан да, Тукай язмый, аның бу өлештә язмавы Камилгә хәерхаһ булганлыктан түгел, бәлки ул остазы Мотыйгулла мулла хәтере өчен яза алмый. Гомумән, Тукай Уральскида яшәгән дәверен яза алмый. Тукай Уральскида яшәгән дәверен йә киләчәктә язу өчен калдырамы, яисә кирәксенмиме. Тукай Казанга кайткач та, тулысы белән Казан атмосферасына чума.

* * *

Тукай яшүсмер балаларны ярата, алардан качмый, алар белән утырыша, аларга әкиятләр сөйли. Без, шул ук мәдрәсәдә укучы балалар, Тукайны аптыратып, йөдәтеп, аның әкият сөйләвен сорый идек. Ул безнең үтенечне бервакытта да кире какмый. Без, ун-унбер яшьлек балалар, Тукай тирәсенә җыела идек. Тукай түгәрәкләнеп утырган балалар уртасына, ике тезен кочаклап, идәнгә утырып сөйли башлый. Сөйләр алдыннан кисәтү ясый, «йокламасагыз гына сөйлим» ди ул. Тукай әкият сөйләгәндә, тупас итеп, сукты да екты, торды да китте, дип сөйләми. Ул тасвирлы итеп, кешеләрне, диюләрне, табигатьне, җәнлекләрне, кошларны, матурын матурлап, ямьсезен ямьсезләп, җанландырып сөйли. Без, аның әкиятен тыңлаучы балалар, кайберләребез утырган җирдән йоклап та китә идек. Ул икенче вакыт шушы туктаган җирдән алып сөйли башлый иде, «кайда тукталдык әле без?» дип, балаларга сорау бирә иде. Аның әкиятендә җырлар, шигырьләр, бәетләр дә була. Мин Тукай сөйләгән әкиятләрнең өчесен хәзерге көндә дә яхшы беләм. Аның бу әкиятләре миндә саклануы, онытылмавы шуннан диеп уйлыйм: Тукай әкиятләрен түкми-чәчми үзем дә бик күп сөйләдем.

Тукайның әкиятләре, ни сәбәптәндер, ярлы, ятим егеттән башлана, мәсәлән, «Хәсән», «Гали», «Әсгать белән Әмҗәт» әкиятләре. Әсгать белән Әмҗәт әкиятләрен мин томанлы төш кебек кенә хәтерлим, «Хәсән», «Гали», «Утыз ул, утыз кыз» әкиятләре яхшы сакландылар.

Тукай мәдрәсәдә була торган кичәләрдә җырлый иде. Дөрестән дә, ул җырны сөеп җырлый иде. Тукай укудан, эштән бушаган арада мәдрәсә идәне буйлап уйланып җырлап йөри. Иртә-кич тәһарәтханәгә юынырга төшсә, анда укучы балалар, зур шәкертләр, хәлфәләр булмаса, сөлгесен муенына урап, папирос тартып җырлап йөри иде. Җырлый торган көйләренең арасында, минем белүемчә, хәзергә кадәрле җырланмый, ишетелми торган җыр кушымталары да бар. Мин бу җыр кушымтасын Тукайның үз иҗаты дип әйтә алмыйм, ләкин Тукай күп вакыт бу кушымтаны кушып җырлый иде. Бу кушымтаны татар җырларының бик күбесе белән җырларга мөмкин. Мин Тукайның үзе җырлаган җырны язам:

Җилбер-җилбер йөргән чакта,
Җил ачадыр куенымны;
Күңелсез чакта җырласак,
Җыр ачадыр күңелне.
Кушымтасы:
Хөрмәтлү Мәхбүбәм,
Сине төшемдә үбәм,
Синең өчен җаным фида,
Күрмичә торалмыйм.

Бу кушымтаны җырлаганда – «хөрмәтлү»нең «лү» авазы күтәренке тавыш белән, икенче, өченче юлы кыска басым белән, дүртенче юлдагы «торалмыйм»ның «а», «ы» авазлары күтәренке тавыш белән җырлана иде.

Тукай укыган Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә, атна саен дип әйтерлек, ябык кичә ясала иде. Бу кичәдә төп җырчы Тукай булып, Вәли белән янәшә утырып җырлыйлар, ләкин Тукай һәрвакыт ике тезен кочаклап утыра иде. Шундый кичәләрнең берсендә мәдрәсәдә булган барлык шәкерт һәм хәлфәләр дә җырладылар.

---

* Кыскартылып бирелә.

Чыганак: Тукай турында замандашлары: истәлекләр, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр җыентыгы. – Казан, 1960. – 46-53 битләр.

ЮАТКЫЧЛАР

Баланы биеткәндә

Биече, улым, биече,
Би кызларын алырбыз;
Би бирмәсә, хан бирер,
Хан бирмәсә, бай бирер.
Байның кызы урынлы,
Ике күзе эренле,
Ярлы кызы яркадай,
Ике күзе чаркадай.

* * *

Бие, кызым, бие, кызым,
Быелгы бәрән бирермен;
Быелгысын яратмасаң,
Җирәнгесен бирермен;
Җирәнгесен яратмасаң,
Артыңа чыбык бирермен.

СҮЗ УЕННАРЫ

Әйтешләр

Монда май бар иде, ул кайда?
- Тычкан ашаган.
- Тычкан кайда?
- Мәче ашаган.
- Мәче кайда?
- Салам астында.
- Салам кайда?
- Үгез ашаган.
- Үгез кайда?
- Тегермән астында.
- Тегермән кайда?
- Утка янган.
-Ут кайда?
- Көл булган.
- Көл кайда?
- Күккә очкан.

Сәхифәне бизәүдә Балык Бистәсе районы Шомырбаш төп гомуми белем мәктәбенең башлангыч сыйныф укучылары ясаган рәсемнәр файдаланылды.

ҖЫРЛЫ-БИЮЛЕ УЕННАР

Юлчы бабай

Шобага салышып яки санашып, яки үз ризалыгы белән берәүне «юлчы бабай» итеп билгеләп дә уртага чыгаралар. Уйнаучыларга утырырга алдан урыннар әзерләнгән, тик бер урын гына ким була. Юлчы бабай уртага баскач, барысы да кулга-кул тотынып, аның тирәсендә нинди дә булса бер көйгә җырлап әйләнә башлыйлар. Юлчы бабай таяк шакылдатуга, һәммәсе җырны туктатып тиз генә берәр урын алып калырга тырышалар. Урынсыз калган уенчы, юлчы бабайга килеп:

– Юлчы бабай, йомыш белән килдек сиңа,
Берәр ансат чара гына өйрәт миңа:
Юлдашларым мине монда ташлап китте,
Котылдырсаң синең өчен җаным фида, –

ди һәм аның боерыгын көтә. Юлчы бабай аңа я җырларга, я биергә, я шигырь сөйләргә, яисә тыраклап түгәрәк тышыннан бер әйләнеп чыгарга куша. Боерыкны җиренә җиткергәч, юлчы бабай, үз урынын аңа биреп, түгәрәккә кушыла да уен күрсәтелгәнчә дәвам итә.

ДРАМА УЕННАРЫ

Бай белән ялчы

Иң элек уйнаучылар шобага тотышалар. Иң очка чыкканы «бай», иң аста калганы «ялчы» була. Шуннан уйнаучылар бер түгәрәк ясыйлар да кулларын тотышып торалар. Бай белән ялчының икесенең дә күзләрен бәйләп уртага кертәләр. Байның кулына җиңелчә генә ишкән сөлге бирәләр. Ялчыны бер читкәрәк куялар.

Бай: *Ялчы кайда, кил, ялчы,*
Миңа эшкә ялланчы.

Ялчы: *И бай абзый, бай абзый,*
Кесәңдә акча бар, абзый,
Бушый алмыйм мин монда,
Кирәк булсам, кил монда, –

диюенә тиз генә урыныннан китә. Бай аңа сугарга селтәнә. Әгәр дә ялчы оста кача белсә, бу уен бик кызык була. Кайвакыт бай белән ялчы каракаршы килеп бәреләләр. Бай ялчыга ун мәртәбә сукса, байлыктан төшеп түгәрәккә керә. Элекке ялчы бай булып, үзенә ялчыны түгәрәктән сайлап ала. Уен шулай дәвам итә.

Чыганак: Татар халык уеннары. Төзүчесе Рәшит Ягъфәров. – Казан: «Раннур» нәшр., 2002. – 24, 25, 73, 96-97, 130 битләр.

МАЙ-МАЙ УЕНЫ / БАРМАК УЕНЫ

Халык педагогикасында баланың теле ачылган чорда сүз уеннары – мавыктыргычлар кулланыла. Шулар арасында иң киң таралганы – бармак уеннары. Баланың бармакларына төрле рольләр биреп, алар арасында кечкенә бер вакыйга сөйләнелә. Болар аркылы балаларның игътибарын бер нәрсәгә туплый алулары һәм бармаклары белән санарга өйрәнүләре кебек максатлар күздә тотыла. Мавыктыргычлар шулай уйнап кына баланы тирә-як даирә, яңа дөнья белән таныштыра.



2015 елда Әлки районының Каргалы авылында Н.Т. Хәбибуллинадан Д.Н. Арсланова һәм Э.Ф. Камалова язып алды.
Нотага салучы – Д.Н. Арсланова.

Карлыган яфрагыннан шипучкалы куас ясау

Бер ярым кадак кара карлыган яфрагы, борчактан аз гына эрерәк итеп туралган ике данә лимон, биш кадак шикәр, ун мискаль кремотартар*. Боларны күрсәтелгән тәртиптә унбиш бутылка кайнар суга, таза агач кисмәккә салынып, таза агач калак илә бер-ике-өч тапкыр болгатып, аралаштырып суынырга куеладыр. Шул көенчә торып куас суының суынганын көтәргә кирәк. (25 градустан ким суынмасын). Мәгълүм вакыт үткәч куас суына ике аш кашыгы чамасында чүпрә салып, тагын да бер-ике тапкыр акрын гына болгатып куярга кирәк. Буның илә куас хәзерләнгәнгә хисап ителәдер. Буннан соңра өч сәгать микъдары вакыт үткәч, назик иләк аркылы сөзеп бутилкаларга тутырылып салкын кладовой вә боз базларында сакланадыр. Вә кирәк вакытны шуннан алынып истигъмаль ителә яки базарга да сата торган җирдә шипучканы салкында тотар өчен бозыңыз хәзер булсын.

Икътисад. — 1912. - № 6. — Б. 171.

Карлыганнан коры варенье ясау

Җителеп пешкән кара карлыганны бер савытка салып өстенә кайнар су сибәләр дә, плитә өстенә утырталар. Анда карлыган җимешләре ярыладыр. Буннан соңра карлыган җимешләре иләк аркылы изелеп үткәзеп, кирәк микъдарда шикәр салып, йомшак камыр хәленә килгәнче ут өстендә болгатып пешерәләр. Аннан соңра алып җайла вә йә табакка җәеп салып ваклап кисеп ком шикәрдә әвәлиләр. Буның илә коры варенье хәзер буладыр.

Икътисад. — 1912. - № 9. — Б. 274.

XX гасыр башында дөнья күргән вакытлы матбугатны өйрәнгәндә, еш кына газета-журнал битләрендәге аш-су сәхифәләре дә күзгә ташлана. Мин бу сәхифәләрне кызыксынып күзәтәм. Моннан 100 еллар элек халкыбызның ничек туклануы, нинди ризыклар әзерләве сезнең өчен дә кызыклы булыр дип уйлап, берничә рецептны сезгә дә тәкъдим итәргә булдым. Бәлки аларның үрнәгендә әлеге ризыкларны әзерләп тә карарсыз.

Казан (Идел буе) федераль университетының
Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк
китаплар һәм кулъязмалар бүлеге баш библиографы
Рәйсә Гомәр кызы ШӘРӘФИЕВА әзерләде.

* Кремотартар — виноград, йөзем җимешеннән кимияханәләрдә винный кислота эшләнәдер. Крем тартар шул винный кислотаның тазартылган җәүһәре. Русча кремотартар дип соралса һәрбер аптекада табыладыр. Тазартылганы винный камень дип тә аталадыр.

Менә безнең талкыш-кәләвә!

«Кияүгә чыкканчы ук, әни белән икәү, Юныс Әхмәтҗановның «Татар халык ашлары» китабыннан укып, талкыш-кәләвә пешереп карарга булдык. Нинди нәрсә икән соң бу, дип, кызыксынып тотындык. Әлбәттә, барып чыкмады инде. Ниндидер баллы масса иде ул, үзе кап-каты. Тагын берничә тапкыр тотынып карадык. Юк, булмый гына бит. Аңа карап күңелем сүрелмәде, кайчан да булса барыбер өйрәнермен дип уйладым. Инде кияүгә чыгып, аерым яши башлагач, йөрәксенеп, тагын тотындым. Ул вакытта перчатка кия белмәгән, пешеп, уч төпләрем суланып кабарып чыга иде. Берәр атнадан, төзәлә төшкәч, тагын ясап карыйм. Менә шулай азаплана торгач, ярыйсы гына килеп чыга башлады. Тора-тора остарасың икән. Шул вакытта ничек туеп ташламадым икән дип шаккатам. Хәзер җайлаштым, туганнарым да ярата талкыш-кәләвәмне, кучтәнәчкә дә нәрсә бирим икән дип аптырамыйм», – дип сөйли авылдашым Гөлфия Саттарова.

Гөлфиянең аш-суга осталыгы аның белән генә чикләнми. Ашын да беркайчан да кибет токмачы белән түгел, үзе нәп-нәзек кенә итеп кискән йорт токмачы белән пешерә ул. Башка ризыклары да телеңне йотарлык тәмле була. Аш-су остасы Рәмзия апа кызы бит ул! Алар йортыннан кунакларның өзелеп торганы да юк.

Онытыла башлаган милли ризыкларыбызның табыныбызга кайтуы бик куанычлы хәл. Талкыш-кәләвә күренә башлагач, күбебез аны яңа затлы ризык итеп кабул итте, чөнки тирәбездә аны пешерә белүче юк иде. Мин, мәсәлән, аны беренче тапкыр Гөлфиядә авыз иттем. Кара әле, мин әйтәм, «Татар халык ашлары» китабында рәсемен күргән бар иде бит!

Хәер, сәбәп, бәлки, талкыш-кәләвәнең онытылуында да түгелдер. Әзерләве бигрәкләр дә четерекле икән бит! Икешәр кеше пешерә торган кәләвәне безнең Гөлфиябез берүзе башкара. Һәм ничек итеп диген әле!

Соңгы вакытта бу затлы ризык зур табыннарда ешрак күренә башлады, «Бәхетле» кибетләрендә дә сатыла ул. Әмма Гөлфия пешергән талкыш-кәләвә бөтенләй икенче шул!

Эш тәртибе:

450 гр шикәр комы, 80 гр бал, 250 гр атланмай, якынча 350 гр он, 1 чокыр кайнаган су алабыз.

Чиста табаны, җәй булса, салкын суга, кышын исә карга утыртып куябыз, майлыйбыз. Ул үз вакытын көтә.

Икенче табада атланмай эретәбез, анда әлбә пешерәчәкбез.

Кечерәк кәстрүлгә бал, шикәр комы, суны салып, кайнатырга куябыз. Баштарак бернича тапкыр күбеген җыеп алабыз.

Атланмайга он өстәп, әлбә ясыйбыз. Аны гел болгатып торырга кирәк. Ике савытны да күз уңыннан ычкындырырга ярамый, болар берьюлы эшләнә.

Әлбәне төсе бераз үзгәргәнче, өстенә мае аерылыбрак чыга башлаганчы пешерәбез. Сүндергәч, бераз гына тотабыз да куна тактасына бушатып, таратып җәябез.

Кулга башта калынрак перчатка, өстеннән резин перчатка киеп куябыз.

Бу вакытта баллы катнашма кайный әле. Ул кызгылтрак төскә керергә тиеш. Әзерлеген белер өчен ике шырпы белән алып сузып карарга кирәк. Тоткач, җепсел сынып китәргә тиеш.

Әзер катнашманы кар өстендә утырган салкын табага бушатабыз. Пычак белән кырыеннан куптарып, кат-кат әйләндерәбез, ул ныгый, катып кына китмәсен. Кайнарлыгы кулга тотарлык булгач, массаны ике башыннан тотып тарта башлыйбыз. Ашыкмыйча һәм туктамыйча тартабыз. Шактый озынайгач, түгәрәк ясап, ике башын тоташтырабыз да, кунадагы әлбәне бераз җәеп җибәреп, әле суынып өлгермәгән әлбә өстенә салабыз. Әлбә өстендә дә тартуны туктатмыйбыз. Бик озынайгач, 8ле ясап өсте-өстенә куеп дәвам итәбез. Баллы «аркан» әлбәне җыеп алып бетерә. Тарткан вакытта җайлап эшләргә кирәк, «аркан» өзелмәсә яхшы. Тарта-тарта ул җепселләнә, җепселләр агара, нечкәрә. Аларны, токмач тараткан шикелле, селкеп-селкеп куна тактасына таратып салабыз (шулай итмәсәң, җылы килеш укмашып ябыша).

Җепселләрне формага (кечкенә стаканмы, рюмкамы) тыгызлабрак тутырып, тактага каплап барабыз. Гадәттә бер савытка 15-18 гр керә.

Сәвия ГАЛИЕВА,
Биектау районының
Чувашиле авылы китапханәчесе

Автор фотолары.

Сатуда бәя ирекле

ИНДЕКСЫБЫЗ– 16987

Н. Исмәгыйлев фотосы.

Кадерле укучыларыбыз!

Исегезгә төшерәбез: 2019 елның икенче яртыеллыгы өчен матбугатка язылу тәгәлләнеп килә. Язгы мәшәкатьләр белән онытылып, «Түгәрәк уен»сыз кала күрмәгез. Басмабызга республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә дә язылырга мөмкин. Безне МАП (Межрегиональное агентство подписки) каталогыннан таба аласыз.

Индексыбыз – 16987. Ярты елга язылу бәясе – 278 сум 53 тиен.

Бергә булыйк!